# HISTORICAL AND ARCHAEOLOGICAL PERIODIZATION OF EAST KAMA REGION IN THE 13$^{th}$ – 16$^{th}$ CENTURIES: ETHNIC SITUATION IN THE FRONTIER

***Izmaylov I.L.,***
*Doctor of Historical sciences,*
*Khalikov Institute of Archeology*
*of the Tatarstan Academy of sciences,*
*Kazan, Russia,*
*ismail@inbox.ru*

The natural and geographical specifics of East Kama area caused also its cultural and historical identity. This region in the medieval period was the periphery of a civilization and a contact zone between settled agricultural and nomadic pastoral tribes. During the different periods the frontier zone of these contacts changed, mostly due to transition of nomads to semi-settled and settled economy. The Golden Horde period of the 13th-15th centuries was crucial for the whole area due the Islamization and forming of ethno cultural bases of the Tatar ethnos.

***Keywords:*** East Kama area, Ulus Dzhuchi (Golden Horde), Kazan khanate, archeology, burial monuments, gravestones, Islam, Islamization, Tatar ethnos.

УДК 94(47)«1914/1918»

# УРОЖЕНЦЫ АКТАНЫШСКОГО КРАЯ НА ФРОНТАХ ПЕРВОЙ МИРОВОЙ ВОЙНЫ И ПОЛОЖЕНИЕ МЕНЗЕЛИНСКОГО УЕЗДА В 1914–1917 ГГ.

***Габдрафикова Лилия Рамилевна,***
*доктор исторических наук,*
*Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ,*
*Казань, Россия,*
*bahetem@mail.ru*

В статье представлен обзор возможностей для изучения истории Первой мировой войны, а также восстановления имен участников войны с помощью краеведческой литературы и современных баз данных. Приводятся сведения о солдатах, родившихся в населенных пунктах Актанышского района, в том числе список военных, награжденных Георгиевскими медалями и крестами. Кроме того, дается обзор тыловой жизни Мензелинского уезда Уфимской губернии в 1914–1917 гг. Автор приходит к выводу о необходимости организации местных мемориалов о солдатах Первой мировой войны.

***Ключевые слова:*** Первая мировая война, Уфимская губерния, Актанышский район, история деревень, историческая память, военный мемориал.

Изучение истории Первой мировой войны является актуальной задачей как регионоведения, так и исторической науки в целом. Для представления полноценной картины прошлого необходимо возрождение памяти об участниках данной войны. В этой связи, уместным будет развитие микроисторических исследований, что даст возможность для обработки большего массива специфических данных, в том числе привязанных к конкретным населенным пунктам.

В годы Первой мировой войны Мензелинский уезд оставался одним из самых густонаселенных уездов Уфимской губернии. По данным Всеобщей переписи населения 1897 г., в Мензелинском уезде проживало 379 981 человек, из них 7 552 приходилось на жителей уездного города [14, с. 11].

К началу XX в. в уезде насчитывалось 778 населенных пунктов [12, с. 5, 82]. Сегодня территория бывшего Мензелинского уезда включает Мензелинский, Заинский, Тукаевский, Сармановский, Муслюмовский, Нижнекамский, Актанышский районы, часть Альметьевского, Азнакаевского, Черемшанского районов Республики Татарстан.

В Актанышский район вошли населенные пункты Актанышевской, Байсаровской, Поисеевской, Семиостровской, Такталачукской волостей Мензелинского уезда.

В краеведческой литературе по Актанышскому району встречаются лишь фрагментарные сведения о местных уроженцах – участниках Первой мировой войны. Положение тыла – Мензелинского уезда в годы данной войны не становилось объектом отдельного исследования, за исключением публикаций В.В. Ермакова и нашей статьи [7; 6].

Сегодня идет активный сбор материалов о солдатах и офицерах Первой мировой войны. Многие документы Российского государственного военно-исторического архива доступны в электронном виде на сайте «Памяти героев Великой войны. 1914-1918» https://gwar.mil.ru/.

Кроме того, имеются опубликованные еще во время войны именные списки убитых, раненых, без вести пропавших нижних чинов. В этих сводах указывалось и место рождения солдата [9].

Мензелинский уезд, как и вся Уфимская губерния, в изучаемый период входил в Казанский военный округ. Территория уезда была разделена на 8 призывных участков. Июльская мобилизация 1914 г. не коснулась Мензелинского уезда. Основной призыв начался во время второй военной мобилизации – в сентябре 1914 г. Например, только 21 сентября 1914 г. в Казань прибыло 1900 призывников из Мензелинского уезда [3, с. 108, 110]. За сентябрь-ноябрь этого года на фронт проводили своих близких 9043 семьи. Из некоторых семей уходили на фронт сразу несколько человек. Поэтому, как совершенно справедливо полагал историк В.В. Ермаков, фактическое количество отправленных на фронт в этот период запасных солдат и призывников могло достигать 10-11 тысяч человек [7, с. 434].

Обратимся к краеведческим и другим данным по количеству солдат-участников Первой мировой войны из отдельных селений Актанышского края. Например, в очерке по истории деревни Барсуково (Бурсык) говорится, что около 50 призывников из этого населенного пункта погибли на фронтах Первой мировой войны [1, с. 237]. В истории деревни Чуракаево приводится цифра о 87 участниках войны. Из селения Татарские Суксы (Суыксу), по сведениям краеведов, было призвано 33 солдата, а также в ходе мобилизации у крестьян забрали 18 лошадей [1, с. 269]. Исследователи истории села Чалманарат указывают конкретные имена участников войны: Бакиров Шайхельмардан, Госманов Харис, Латыпов Васыйк, Латыпов Мухамметджан, Фатхетдинов Латып, Хамзин Лукман, Ханнанов Сальман, Шарафетдинов Хужабагаветдин. Последние два солдата погибли на войне [1, с. 336-337]. Эти сведения ценны тем, что в базе данных солдат Первой мировой войны, основанной на документах Российского государственного военно-исторического архива, многие имена, особенно татарские, представлены в искаженном виде и не всегда привязаны к конкретным населенным пунктам. Так, по деревне Чалманарат Семиостровской волости Мензелинского уезда в этой базе данных можно найти имена лишь 4 солдат: Гаптулхананов Симнархарси, Хуснутдинов Мадригин, Милашенов Даулет-Гирей, Ямалтдинов Вазетдин. Имена, как и названия населенных пунктов, записывали на слух, поэтому они порой очень приблизительные. Судя по всему, Гаптулхананов Симнархарси – это, может быть, указанный краеведами Ханнанов Сальман. Он был рядовым 199-пехотного Кронштадского полка. Участвовал в Брусиловском прорыве, 20 августа 1916 г. в ходе боев около польской деревни Хута-Нова получил сильное ранение и выбыл на перевязочном пункте. Дальнейшая его судьба по архивным документам не известна, но если свериться с краеведческими данными, то мы видим, что Сальман Ханнанов погиб на фронте.

По деревне Чуракаево в краеведческой литературе также есть имена некоторых участников Первой мировой войны. Это Гайсин Хиражетдин, Галиев Акрам, Гиззатуллин Шарифулла, Насыров

Гафур, Рахимджанов Габдулла, Фардиев Мирзасалих, Хайдаров Мустафа, Хафизов Нурлыгаян. Последние два солдата попали в плен и вернулись в родную деревню уже после войны. В базе данных по солдатам Первой мировой войны можно найти имена еще 10 солдат из деревни Чуракаево Семиостровской волости Мензелинского уезда Уфимской губернии. Их имена тоже фиксировались с ошибками. Это Ахметвалиев Мендал, Абдуллин Абдураз Исланович, Акмалетдинов Маулетдин, Галимов Абдул Хакимович, Гизатуллин Юнус, Мухамедьянов Мухамацидек, Кадаргулов Нургалей, Казаргулов Галиян-Махамет, Хусаинов Насаттин, Шагимарданов Анас. Таким образом, по совокупным сведениям из краеведческой литературы и архивных баз на сегодняшний день известны имена 18 солдат – уроженцев села Чуракаево.

Но сколько же все-таки солдат могло быть призвано из пяти волостей Мензелинского уезда (нынешний Актанышский район) и от каждой отдельной деревни. Для этого необходимо воспользоваться как общими статистическими данными, так и прибегнуть к некоторым математическим рассчетам.

По неполным данным за 1914-1916 гг. из Мензелинского уезда было отправлено на фронт 54 990 человек [7, с. 434]. В указанной выше базе данных имеются документы на 54 092 военнослужащих. Но в некоторых случаях имена повторяются, также могут быть ошибки, связанные с неверным указанием места рождения солдата. Тем не менее, мы можем констатировать, что около 14,5% от общего населения Мензелинского уезда приняли участие в Первой мировой войне.

Как уроженцы именно города Мензелинска в базе данных указаны 265 человек. При этом, судя по названиям волостей, иногда солдаты в качестве своей родной деревни указывали просто название уездного центра. Таким образом, настоящих уроженцев Мензелинска должно быть меньше. Но даже с заявленным количеством солдат-мензелинцев получается, что лишь чуть более 3,3% городского населения уезда были призваны на фронт, а основную военную силу составляли выходцы из сельской местности.

При дальнейших подсчетах, мы будем опираться на цифру – общее количество документов по солдатам Мензелинского уезда – 54 092. С помощью этой цифры попытаемся выяснить среднее количество призывников от каждого населенного пункта (села, деревни). Как уже было отмечено выше, 265 человек указаны как уроженцы Мензелинска, еще 91 солдат в качестве места рождения назвали пригород Заинск Мензелинского уезда. Значит, 356 призывников можно отнести к так называемому городскому населению [13]. Таким образом, общее количество призывников из сельских местностей Мензелинского уезда – 53 736 человек. В Мензелинском уезде в начале XX в. было 33 волости, в каждой волости в среднем насчитывалось по 12 сел и деревень. Простейшая математическая операция 53 736 /33 / 12 показывает, что в среднем от каждого населенного пункта уезда на фронты Первой мировой войны могли быть отправлены 135 солдат. Безусловно, это внушительные цифры и настоящая катастрофа для тылового населения. Лишение крестьянских хозяйств основных рабочих сил привело к заметному ухудшению материального положения многих семей.

Например, проживавший в соседнем Бугульминском уезде ученый Хади Атласи в 1915 г. отмечал, что через полгода военного времени большинство семей сократили количество или вовсе остались без лошадей и другой домашней скотины. По его мнению, война особенно сильно отразилась на татарских хозяйствах. Он писал, что «быт татар расстроился сильнее» [5, с. 270].

Если опираться на указанные выше цифры, то количество солдат Первой мировой войны, выходцев из пяти волостей Мензелинского уезда – Актанышевской, Байсаровской, Такталачукской, Поисеевской, Семиостровской – должно составить чуть более 8141 человек.

К сожалению, база данных по солдатам не дает возможности для сформирования списков солдат по всем волостям. Например, по Байсаровской волости было найдено 2288 солдатских документов, по Семиостровской – 2074, Поисеевской – 1554, а по Такталачукской – только 925, а по Актанышевской – лишь 72. В

совокупности – это 6913 солдат. Конечно, такие показатели не соответствуют действительности. Ошибка поисковой системы объясняется схожестью некоторых административно-территориальных обозначений. Например, Актанышевская и Акташская волости объединяются в одну группу. Поэтому по результатам системы поиска мы получаем меньшее количество солдат из Актанышского края, чем должно быть на самом деле. Для выявления всех солдат и их идентификации с отдельными населенными пунктами Мензелинского уезда небходима трудоемкая работа с базой данных.

Солдатские анкеты показывают, что выходцы из Мензелинского уезда воевали в самых разных войсках. Конечно, больше всего они служили в пехотных полках. Из 54 092 солдат погибли в боях 2 144 человека, еще 135 умерли от ран и болезней после. 6 731 человек пропали без вести, остается не выясненной судьба еще 2 818 человек. Есть в карточках солдат и такие обозначения как «оставлен на поле боя», таких военнослужащих насчитывается 905 человек. Очевидно, что выжившие из «оставленных на поле боя» или «пропавших без вести» попадали в плен. Но официально из уроженцев Мензелинского уезда попавшими в плен в этой документальной подборке считаются 87 человек. Всего были ранены, контужены больше половины солдат – 28 285 человек, 12 586 солдат были списаны из-за различных болезней.

Трагично сложилась судьба солдат из 220-го пехотного Скопинского полка. В этом полку служили рядовыми сразу 6 уроженцев Актанышского края: Тимергалиев Мухаметхалим (Байсаровская вол.), Хакимуллин Ялчугулла (Байсаровская вол.), Садретдинов Бадрутдин (Поисеевская вол.), Ахметжанов Мухаметдин (Поисеевская вол.), Сибгатуллин Камилир (Поисеевская вол.), Гизатулин Зинатулла (д. Н. Семиостров). Все они умерли примерно в одно время – 24-25 июня 1915 г., в районе польского фольварка (хутора) Доловатка. Причина смерти – отравление, они стали жертвами газовой атаки германской армии. Всего в ходе Первой мировой войны от газового отравления умерли 26 уроженцев Мензелинского уезда [13].

В тылу – в жизни жителей Мензелинского уезда в годы войны – тоже произошли существенные изменения. Семьи военнослужащих получали социальные пособия от государства, их распределением занимались муниципальные органы власти. Губернская пресса сообщала о том, что отдел Мензелинской земской управы, ведающий «раздачей пособия семействам, призванных на войну», работает по ненормированному графику, в невыносимых условиях, «день и ночь, будни и праздники» [17].

16 августа 1914 г. состоялось экстренное заседание Мензелинского уездного земского собрания, где были пересмотрены годовые расходы. Мензелинское городское попечительство Всероссийского земского союза помощи больным и раненым и их семьям начало свою работу с 1 декабря 1914 г. В это попечительство вошла и учрежденная ранее особая комиссия при Мензелинской городской управе. Всего в работе местного отделения Всероссийского земского союза приняли участие 180 человек, каждый из которых платил членские взносы [16].

Больница в селе Бережные Челны была выбрана в качестве основного пункта приема раненых и больных солдат, поскольку она была близка к пристани. В октябре 1914 г. прибыла первая партия раненых солдат. В остальных лечебницах уезда планировали разместить выздоравливающих военнослужащих. Например, в январе 1915 г. часть солдат из Челнинского лазарета направили в Мензелинскую больницу [7, с. 432, 436].

С началом войны в Мензелинский уезд прибывали беженцы, интернированные и военнопленные. Так, в конце 1915 г. в уезде было зафиксировано 5123 беженца. Больше всего эвакуированных разместили в Такталучукской волости (совр. Актанышский район), где проживало 750 беженцев [2, с. 303]. Среди них были белорусы и эстонцы. Многие из них сумели уехать в свои родные края лишь в начале 1920-х гг. Беженцам, как и семьям военнослужащих, оказывалась посильная материальная помощь. Были организованы рабочие места. Так, в 1916 г. в Мензелинске имелся специальный склад с одеждой и обувью для беженцев. Вещи под руководством мастериц изготавливали как сами беженки (они ра-

ботали на дому), так и местные монахини Пророко-Ильинского монастыря [2, с. 305-306].

Кроме беженцев из западных окраин страны, во время войны в Мензелинском уезде проживали интернированные. В сентябре 1915 г. число интернированных подданных Германии и Австро-Венгрии в уезде составляло 2 760 человек [2, с. 316].

Еще одной новой социальной группой в уезде стали военнопленные. Местное население с любопытством наблюдало за бывшими солдатами иностранных армий. Так, 29 марта 1915 г. в Бережных Челнах во время конвоя группы пленных австро-венгерских солдат (1 100 чел.) в Мензелинск собралась большая толпа из местных жителей. Военнопленных использовали, преимущественно, для сельскохозяйственных работ [7, с. 434]. Часть из них, до 200 человек, участвовала в строительстве Челнинского элеватора. Предприятие заработало 4 сентября 1917 г., это был один из крупнейших элеваторов в России, с емкостью 2 млн. пудов зерна [8, с. 242].

Несмотря на прибытие военнопленных, которые выступали в качестве дешевой рабочей силы, основная масса местных хозяйств в военный период испытывала большие трудности. Тем более мелкие хозяйства не спешили использовать труд военнопленных. В Мензелинском уезде неурожайным выдался 1915 год. Социальные пособия в условиях постоянного роста цен и дефицита тоже служили лишь небольшой материальной помощью. Увеличилось количество безлошадных хозяйств, некоторые не сами засеивали свои поля. Около трети крестьянских семей остались без мужчин, что отразилось на материальном положении жителей Мензелинского уезда [7, с. 437].

Февральские события 1917 г., трудности военного и революционного времени, в том числе рост цен, дефицит товаров и продовольствия не обошли стороной и Мензелинский уезд. Крестьяне были дезинформированы не правильной интерпретацией революционной свободы, манифестами различных партий. Иногда вести о революционных событиях в городах привозили солдаты Первой мировой войны. Так, в деревне Чалманарат Семиостровской во-

лости информацию об отречении царя и февральской революции распространил демобилизованный солдат Мухамметжан Латыпов [1, с. 336]. Реакции населения на изменения в стране были разными. Только в марте 1917 г. был отмечен целый ряд беспорядков в Мензелинском уезде. В волостном селе Поисеево разъяренная толпа удалила врача и учительницу, закрыла больницу [11, с. 7]. Руководил беспорядками местный агитатор Гисматов. Под его предводительством сельчане ворвались в волостное правление и больницу, главной целью агрессивной толпы было уничтожение портретов императора, которые висели в этих учреждениях. В этот же период толпа разграбила ближайшее имение [1, с. 242]. В селе Актаныш также были отмечены агрессивные реакции на новости об отречении императора, например, толпа разграбила лавки. Были и другие беспорядки в помещичьих хозяйствах [11, с. 7]. Обстановка оставалась накаленной и летом, и осенью того же года.

С другой стороны, в уезде устраивались различные общественные собрания, навеянные идеями революционной свободы и равноправия, и призванные многие острые вопросы решить мирным путем. Например, 15-16 апреля 1917 г. в деревне Тлянчитамак прошел съезд мусульман Мензелинского уезда, с участием 2500 делегатов. На съезде, наряду с вопросами о правах российских мусульман, обсуждался земельный вопрос. Многие участники выступали за отмену частной собственности на землю. На этом съезде были выдвинуты делегаты на предстоящий Всероссийский съезд. Представителями от Мензелинского уезда были избраны бывший преподаватель медресе Иж-Буби Губайдулла Буби, Г. Халфин, Гаяз-хазрат Якупов, Исмаил-хазрат Усманов, Б. Шамбазов, мулла Х. Насибуллин [10, с. 155].

В мае 1917 г. был организован уездный совет крестьянских и солдатских депутатов. Председателем Президиума был избран Д.Н. Тяжельников – известный в уезде ученый-агроном, бывший сельский учитель, высланный в Мензелинский край еще в 1880-е гг. Он принимал активное участие в митингах еще во время первой русской революции, а также весной 1917 г. 21 декабря того же года Мензелинский совет крестьянских и солдатских депутатов

телеграфировал Казанскому военно-окружному исполнительному комитету о переходе власти Советам [15, с. 103]. Д.Н. Тяжельников трагически погиб в июле 1918 г., в разгар Гражданской войны [4, с. 2].

В свете событий Октября и Гражданской войны страницы Первой мировой войны оставались в тени исторической памяти. В последние годы возрождается история этой забытой войны.

По сегодняшним данным, 210 уроженцев Мензелинского уезда были представлены к различным наградам. Из них 131 человек удостоен Георгиевского креста IV-й степени, 48 чел. – Георгиевской медали IV-й степени, 17 чел. – Георгиевского креста III-й степени, 1 чел. – Георгиевской медали III-й степени, 4 чел. – Георгиевского креста II-й степени, 5 чел. – Георгиевского креста I-й степени. Некоторые награждались уже посмертно, Георгиевские кресты и медали передавали родственникам героев. Из Актанышского края – 13 солдат удостоены Георгиевских медалей и крестов IV-й степени:

1. Сиразитдинов Гариф Фахрутдинов. Георгиевская медаль IV-й степени (За храбрость). Место рождения: Уфимская губ., Мензелинский уезд, Токталачукская вол. Место службы: 2-й Сибирский стрелковый полк, рядовой.

2. Муллашинеянов Фатхетдин. Георгиевская медаль IV-й степени. Место рождения: Уфимская губ., Мензелинский уезд, Токталачукская вол., д. Бульсак. Место службы: 407-й пехотный Сарайский полк, рядовой.

3. Авсянетинов Довкатча Минивсиевич. Георгиевская медаль IV-й степени. Место рождения: Уфимская губ., Мензелинский уезд, Семиостровская вол., д. Семиострово. Место службы: 210-й пехотный Бронницкий полк, рядовой.

4. Султанов Шагигардан Мухаметович. Георгиевская медаль IV-й степени. Место рождения: Уфимская губ., Мензелинский уезд, Байсаровская вол., д. Байсар. Место службы: 404-й пехотный Камышинский полк, рядовой.

5. Джамалтдинов Мигнохази. Георгиевский крест IV-й степени. Место рождения: Уфимская губ., Мензелинский уезд, Бай-

саровская вол. Место службы: 170-й пехотный Молодечненский полк, рядовой.

6. Баймахаметов Харис. Георгиевский крест IV-й степени. Место рождения: Уфимская губ., Мензелинский уезд, Поисевская вол. Место службы: 294-й пехотный Березинский полк, ефрейтор.

7. Валиахметов Шаймухамет Валиахметович. Георгиевский крест IV-й степени. Место рождения: Уфимская губ., Мензелинский уезд, Поисевская вол. Место службы: 330-й пехотный Златоустовский полк, мл. унтер-офицер. Дата события: 09.09.1915 – 10.09.1915.

8. Ямалетдинов Батретдин Ямалетдинович. Георгиевский крест IV-й степени. Место рождения: Уфимская губ., Мензелинский уезд, Поисеевская вол. Место службы: 330-й пехотный Златоустовский полк, рядовой.

9. Харматуллин Хайрулла Загайзуллин. Георгиевский крест IV-й степени. Место рождения: Уфимская губ., Мензелинский уезд, Байсаровская вол. Место службы: 60-я пехотная дивизия, рядовой. Дата события: 10.03.1916.

10. Сулбанов Худья Исламович. Георгиевский крест IV-й степени. Место рождения: Уфимская губ., Мензелинский уезд, Семиостровская вол., Атасева. Место службы: 93-й пехотный Иркутский полк, рядовой. Дата события: 05.03.1916 – 12.03.1916.

11. Галишин Гильмутдин. Георгиевский крест IV-й степени. Место рождения: Уфимская губ., Мензелинский уезд, Семиостровская вол., д. Нижняя-Уржада. Место службы: 63-й пехотный Углицкий полк, рядовой.

12. Маликов Ханан Хабирович. Георгиевский крест IV-й степени. Место рождения: Уфимская губ., Мензелинский уезд, Семиостровская вол., д. Татарская. Место службы: 26-й Сибирский стрелковый полк, рядовой.

13. Хайбатдинов Богаутдин. Георгиевский крест IV-й степени. Место рождения: Уфимская губ., Мензелинский уезд, Семиостровская вол., с. Бабкулово. Место службы: 241-й пехотный Седлецкий полк, рядовой [13].

Сегодня важно увековечить имена героев Первой мировой войны на местном уровне. В некоторых населенных пунктах Та-

тарстана уже есть такие примеры. Например, в небольшой деревне Марийское Текашево в Менделеевском районе РТ в последние годы был установлен скромный обелиск, где наряду с именами участников Великой Отечественной войны, приведены и имена солдат Первой мировой войны из Марийского Текашево. Безусловно, аналогичная работа по увековечиванию памяти земляков должна быть проведена в каждом населенном пункте.

## ЛИТЕРАТУРА И ИСТОЧНИКИ

1. Актаныш – ак илем: тарих, икътисад, мәдәният, шәхесләр / Төз. И. Хәлиуллин. – Казан: Идел-Пресс, 2010. – 539 б.

2. Башкирия в годы Первой мировой войны. 1914-1918: Сборник документов и материалов / Сост. Р.Н. Рахимов [и др.]. – Уфа: Китап, 2014. – 446 с.

3. Государственный архив Республики Татарстан (далее – ГА РТ). Ф. 199. Оп. 2. Д. 1493.

4. ГА РТ. Ф. П30. Оп. 3. Д. 2753.

5. *Габдрафикова Л.Р., Абдуллин Х.М.* Татары в годы Первой мировой войны (1914-1918). – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. – 396 с.

6. *Габдрафикова Л.Р.* Мензелинский уезд в годы Первой мировой войны // Гуманитарные науки в XXI веке: научный интернет-журнал. – 2019. – № 12. – С. 36-42.

7. *Ермаков В.В.* История Набережных Челнов и регионов Восточного Закамья. Ч. 1. Изд. 2-е, исп. и доп. – Казань: Казан. гос. ун-т, 2008. – 465 с.

8. *Ермаков В.В.* Торгово-промышленное предпринимательство в Нижнем Прикамье в условиях Первой мировой войны // Татарский народ и народы Поволжья в годы Первой мировой войны. Сборник материалов Всероссийской научной конференции / Под ред. Л.Р. Габдрафиковой. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2014. – С. 242.

9. Именной список убитым, раненым и без вести пропавших нижним чинам. – СПб.: Военная типография Екатерины Великой, 1915.

10. *Исхаков С.* Российские мусульмане и революция (весна 1917 – лето 1918 гг.). 2-е изд., доп. – М.: «Социально-политическая мысль», 2004. – 592 с.

11. Крестьянское движение в 1917 году. Сборник документов. – М.-Л.: Госиздательство, 1927. – 442 с.

12. Населенные пункты Башкортостана. Ч. 1. Уфимская губерния, 1877. – Уфа: Китап, 2002. – 430 с.

13. Памяти героев Великой войны. 1914-1918 [Электронный ресурс] https://gwar.mil.ru

14. Первая всеобщая перепись населения Российской империи. 1897 г. – Т. XLV. Уфимская губерния. Тетрадь 1. – СПб.: Центральный статистический комитет, 1901. – 186 с.

15. Упрочение советской власти в Татарии (октябрь 1917 – июль 1918 гг.). Сборник документов и материалов / Под ред. Н.А. Адрианова и др. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1964. – 708 с.

16. Уфимский вестник. – 1915. – 26 февраля. – № 45.

17. Уфимский вестник. – 1915. – 17 апреля. – № 84.

## SOLDIERS FROM AKTANYSH REGION IN WORLD WAR I AND MENZELINSK UEZD IN 1914-1917

***Gabdrafikova L.R.,***
*Doctor of Historical sciences,*
*Marjani Institute of History*
*of the Tatarstan Academy of sciences,*
*Kazan, Russia,*
*bahetem@mail.ru*

The article presents an overview of the possibilities for studying the history of the World War I, as well as reconstruction of the names of solders on the basis of reseaces of local history and modern databases. Here is some information about the soldiers, who were born in the settlements of the Aktanysh region. The list of local soldiers decorated with medals and crosses of St. George is given. In addition, the article has information about the civilian life of the Menzelinsky uezd of the Ufa province in 1914-1917. The author believes that the organization of local war memorials of World War I is necessary.

***Keywords:*** World War I, Ufa province, Aktanysh district, history of villages, historical memory, war memorials.

УДК 930.27:94(470.41)

# АКТАНЫШ РАЙОНЫНДА ЭПИГРАФИК ИСТӘЛЕКЛӘРНЕҢ ӨЙРӘНЕЛЕШЕ

***Гайнетдинов Айдар Марсил улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты,*
*Казан, Россия,*
*aydargm@yandex.ru*

Татарстан Республикасы Актаныш районы эпиграфик истәлекләре 1998 елга кадәр галимнәр тарафыннан тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәде. Соңгы елларда гына кайбер тарихчылар борынгы кабер ташларын ачыклау һәм системага салу өчен фәнни тикшеренүләр үткәрә башладылар. Нәтиҗәдә, М. Әхмәтҗанов, Р. Кадыйров, И. Васильев тарафыннан 95 эпиграфик истәлек өйрәнелгән һәм фәнни әйләнешкә кертелгән. Мәкалә авторы моңа кадәр беркем дә өйрәнмәгән 6 кабер ташы текстын китерә. Бүгенге көндә Актаныш районы торак пунктлары зиратларының дүрттән бере генә эпиграфик планда тикшерелгән. Бу төбәктә сакланган эпиграфик материалларны киләчәктә ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты тарафыннан тулысынча өйрәнү планлаштырыла, чөнки алар татар халкының тарихы һәм мәдәнияте өчен бик кыйммәтле чыганак.

***Төп төшенчәләр:*** Актаныш районы, эпиграфик истәлекләр, эпитафияләр, татарлар, кабер ташлары.

Халкыбыздан безгә мирас буларак гаять күп сандагы тарихи-мәдәни истәлекләр сакланып калган, шул исәптән гарәп графикасында язылган борынгы кабер ташлары да бихисап күп. Алар халкыбыз тарихын, мәдәниятен, телен өйрәнүдә, һичшиксез, әһәмиятле роль уйный. Шуңа күрә татарлар яшәгән һәр төбәк җентекләп өйрәнелергә тиеш, әби-бабаларыбыздан сакланып калган бер генә эпиграфик ядкәрне дә күз уңыннан ычкындырырга ярамый, аларның һәрберсен түкми-чәчми халыкка кайтаруда җиң сызганып эшләү таләп ителә. Бүгенге көндә Казан арты төбәгенең байтак районнары эпиграфик планда чагыштырмача яхшы өйрәнелгән, ә менә Казаннан бик ерак урнашкан төбәкләрдәге ташъязма истәлекләргә әле тиешле дәрәҗәдә игътибар бирел-

ми. Әлегә фәкать Актаныш районы борынгы эпитафияләренең байтак өлешен кайбер галимнәр өйрәнергә өлгергәннәр һәм аларның күбесен фәнни әйләнешкә кертеп җибәргәннәр. Бу эштә хәтта башка милләт вәкилләре дә читтә калмаган, кулларыннан килгәнчә өйрәнергә тырышканнар.

Районда иң борынгы эпиграфик истәлек Әҗәкүл авылында табылган. Беренче булып аны мәшһүр татар галиме Марсель Әхмәтҗанов 1998 елның 11 августында ачыклаган һәм өйрәнгән. Аның фикеренчә, әлеге кабер ташы 1682–1683 елларда вафат булган Килди би улы Ишкәйгә куелган [1, б. 105]. Әҗәкүл зиратында әле элегрәк тагын икенче таш та сакланган булган, тик анысы бер җирдә дә табылмаган, ни сәбәпледер югалган [1, б. 105].

2009 елда ТР ФАнең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган комплекслы экспедиция вакытында тарихчы Рәшит Кадыйров Актаныш районының 14 авылы зиратында 53 эпиграфик истәлек ачыклаган [3, б. 60]. Әмма ул җәмәгатьчелекне фәкать Мәчти саласы ташларының текстлары белән генә таныштыруны кирәк дип тапкан, башкалары хакында тиешле мәгълүмат бирмәгән.

2014–2015 елларда Актаныш төбәге эпиграфик истәлекләренең байтак өлешен Башкортстан тарихчысы Илья Васильев өйрәнгән. Ул, нигездә, районның көньяк-көнбатышында урнашкан авылларга гына игътибарын юнәлткән, шул рәвешле, районның 16 авылында 95 эпиграфик истәлек ачыклаган (шуларның өчесе кириллицада язылган мари ташлары). Васильевның биредә табылган барлык эпиграфик материаллар урын алган китап 2017 елда бик аз тираж белән басылып чыккан (Кара: [4]).

Башкортстан галимен Актаныш кешесе Е. Ирдуганова чакырган булган. Әлеге ханым сүзләренчә, ул Татарстан галимнәре арасында теләктәшлек таба алмаганга, чарасызлыктан тарихчы Васильевка мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булган [2, б. 3]. Казан шәһәренең берничә генә фәнни оешмасында эпиграфистлар бар, тик шунысы хак, Ирдуганова аларга мөрәҗәгать итмәгән, күрәсең. Һәрхәлдә, ул ТР ФАнең Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты белән элемтәгә кергән булса, үтенечен кире бормаслар иде.

Ирдуганова язганча, ул Васильев белән 2014-2016 елларның җәй айларында Актыныш районында сакланган кабер ташларын исәпкә алып йөргән [2, б. 3]. Башкортстан тарихчысы исә ни өчендер, югарыда әйтелгәнчә, әлеге районда 2014–2015 елларда гына фәнни эш алып баруын ассызыклаган [4, б. 4-5].

И. Васильев, Актаныш ташбилгеләрен Башкортстан Республикасы Илеш районының кайбер кабер ташлары белән бергә туплап, бер китап итеп чыгарган. Ләкин ни өчендер аның тарафыннан Актаныш районы да, Илеш районы да тулысынча өйрәнелмәгән. Нәтиҗәдә, «ике куянны тотарга теләп, берсе дә тотылмаган» булып чыга. Актаныш төбәгенең һәр авыл зираты тикшерелеп аерым бер басма, Илеш районының бөтен авыл зиратлары өйрәнелеп аерым китап итеп чыгарылса, фәнни яктан отышлырак һәм мәгънәлерәк булыр иде. Васильевның китабы фәнни дәрәҗәдә яхшы язылса да, анда кайбер кимчелекләр, субъектив һәм хаталы фикерләр бар. Мәсәлән, автор, татар кешеләренә куелган эпиграфик истәлекләрнең текстлары татар телендә түгел, ә «Урал-Идел буе төрки теле»ндә язылган, дип саный [4, б. 17]. Аның китабында 1964 елга кадәр куелган ташлар тасвирланган, димәк, аныңча, XX гасырның икенче яртысында да татарлар татар телендә түгел, ә нindider «Урал-Идел буе төрки теле»ндә язганнар булып чыга. Шулай ук, Башкортстан галиме фикеренчә, Әҗәкүл авылы мари яки удмурт авылы, чөнки, зираты яр буенда урнашкан һәм бу татар һәм башкорт зиратларына хас түгел, имеш [4, б. 109]. Татар авылларын җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнмичә, мондый нәтиҗә чыгару тарихчы галим исемен йөрткән кешегә бер дә килешми, әлбәттә. Чынлыкта, яр буенда урнашкан борынгы татар зиратлары аз түгел, бигрәк тә Казан арты төбәгендә.

Васильевның экспедиция сәфәрендәге юлдашы Е. Ирдуганова да үз мәкаләсендә шундый ук хаталы фикерләре белән уртаклашкан. Мәсәлән, аның уйлавынча, Әҗәкүл ташы мәҗүси стильдә эшләнгән, чөнки анда, янәсе, мәҗүси иләһ – кояш сурәтләнгән [2, б. 3]. Беренчедән, Әҗәкүл ташында кояш түгел, үсемлек орнаменты, төгәлрәк әйткәндә, чәчәк төшерелгән, икенчедән, кояшка охшаган орнаментлар, ягъни соляр билгеләр Алтын

Урда чорындагы бик күп татар кабер ташларында урын алган, өченчедән, Коръән аятьләре һәм хәдисләр язылган истәлекне мәҗүсиләргә бәйләү мантыйкка туры килми. Автор шул рәвешле Әҗәкүл ташбилгесенә охшаш татар ташъязмаларын да чирмеш халкының мирасына кертмәкче була, хәтта Татарстанның Кукмара һәм Әгерҗе районнарында сакланган Килмөхәммәд Ишмән улы эшләгән кабер ташларын фин-угор халкыныкы итеп карый [2, б. 3]. Чынлыкта, аларның барысы да мөселман һәм татар традицияләре нигезендә эшләнгән һәм татар телендә язылган.

Башкортстан тарихчысы Васильев Әҗәкүл авылында сакланган иң борынгы эпиграфик истәлекне өйрәнгән, ләкин, аның фикеренчә, ул Ишкәй Килди би улына түгел, ә ниндидер Әвәрүткә ыруыннан булган Ишкәй Килкәй улына куелган [4, б. 117]. Гадәттә, ул заманнарда татарлар озын исемнәрне кыскартып әйткәннәр. Ташта да кабер иясенең һәм аның атасының исемнәре кыскартып язылганлыгы күренә, чөнки Ишкәй Килкәй улының тулы исеме Ишмөхәммәд Килмөхәммәд улы булса кирәк.

Шунысын әйтергә кирәк, Васильев Татарстан тарихчысы Р. Кадыйровка караганда Мәчти ташларының текстларын дөресрәк, тулырак һәм төгәлрәк укый алган. Кадыйров әлеге салада 25 таш тапкан булса, ул бер ташка күбрәк, ягъни 26 эпиграфик истәлек ачыклаган. Васильев Кадыйровның күп кенә хаталарын төзәткән һәм үзенең сүзләрен дәлилләү өчен ташларның фотоларын китергән. Нигездә, ул ташларның текстларын төгәл, җиренә җиткереп укырга тырышкан, транскрипцияләрен китергән, параллель рәвештә рус теленә тәрҗемә иткән, әмма ташъязмаларның гарәп телендәге өлешләрен бераз хаталы биргән, мәсәлән, калын укылышлы хәрефләр белән нечкә укылышлы хәрефләрне бутаган (мисал өчен, «тәсыйру» сүзе «тәсире» дип бирелгән һ.б.). Бу шулай ук татар телендә язылган өлешләргә дә кагыла (мәсәлән, «ахыр» сүзендәге «х» хәрефе калын әйтелешле, ягъни нокталы гарәп хәрефе булса да, транскрипциядә «ахир» дип бирелгән [4, б. 412] һ.б.).

Без дә быел Актаныш районындагы дүрт авылның (Иске Кормаш, Кыр-Каентүбә, Шәбезбаш һәм Яңа Балтач) зиратларын читтән торып өйрәндек. Аларның фотоларын безгә атаклы жур-

налист, төбәк тарихын өйрәнүче Фидаил Мәҗитов тәкъдим иткән иде. Иске Кормаш һәм Шәбезбашның барлык ташларын И. Васильев өйрәнгән һәм алар аның китабында урын алган. Нигездә, безнең укылыш анықы белән туры килә. Шунысын гына искәртик, Шәбезбаш зиратында җирләнгән Гарифулла Гали улының кабер ташы 8 юлдан гыйбарәт, тик Васильев аны 7 юлдан тора дип күрсәткән. Ул "Әд-дүнйәә сәәгат" сүзләрен бер юлга керткән, чынлыкта, "әд-дүнйә" аерым рәвештә иң ахыргы юлда, "сәәгат" сүзе аерым гына беренче юлда язылган. Шуңа күрә бу ташның текстын укыганда, башта иң ахыргы юлны, аннары өстән аска таба укырга кирәк.

Түбәндә Кыр-Каентүбә һәм Яңа Балтач зиратларында сакланган эпиграфик истәлекләрнең текстлары белән таныштырып китәбез.

## Кыр-Каентүбә авылы зираты

**1. Билгесез кешегә куелган кабер ташы, XX гасыр башы.**
Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (уеп язылган):
"...
1) нче [йә]шдә дарe бәкайә рихләт кыйлды".
Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Алгы ягы:
"...
1) нче яшьтә мәңгелек дөньяга күчте".
**2. Билгесез кешегә куелган кабер ташы, XX гасыр башы.**
Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (уеп язылган):
1) "Кәфәә бил-мәүти вәәгыйзаа
2) таййәбәллааһү сәраaһү
3) вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһ
4) рабби-рхәм вә-гъфир би-фәдълиһи вә кәрамиһ
5) Әбүзәр кызы".
Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) “Үлем вәгазьче буларак җиткән.
2) Аллаһ аның туфрагын яхшы кылсын
3) һәм урынын җәннәт итсен.
4) Раббы, камиллегең һәм юмартлыгың белән рәхим кыл һәм гафу ит.
5) Әбүзәр кызы”.

**3. Зәнур Вәлиәхмәд кызына куелган кабер ташы, 1899 ел.**

Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (калкытып һәм уеп язылган):
1) “Ләһү мәләкүн
2) йәнәәдии күллә
3) йәүмин лидүү лил-мәүти
4) вә-бәнүү лил-харааб
5) Зәнур бинте
6) Вәлиәхмәд
7) 1899”.
Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Алгы ягы:
1) «Көн саен
2) фәрештә аңа [кешегә]
3) әйтә: «Туыгыз – барыбер үләчәксез,
4) биналар төзегез – барыбер җимереләчәк».
5) Зәнур бинте
6) Вәлиәхмәд
7) 1899 [ел]”.

**4. Билгесез кешегә куелган кабер ташы, 1910 ел.**

Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (уеп язылган):
“...
1) 1910 сәнә”.
Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Алгы ягы:
“...
1) 1910 ел”.

**5. Габделгалим Габделбасыйр улына куелган кабер ташы, XX гасыр башы.**

Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (калкытып һәм уеп язылган):
1) “Әд-дүнйәә сәәгатүн
2) фәҗгальһәә таагаһ
3) әл-кабру бәхрун
4) гамиикун вә күллүн-нәәси
5) фииһәә гарииқъ
6) Габделгалим Габделбасыйр
7) углы”.
Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Алгы ягы:
1) “Дөнья бер сәгатьлек,
2) аны [Аллаһка] итагать белән үткәр.
3) Кабер – тирән
4) диңгез һәм һәрбер кеше
5) анда бата.
6) Габделгалим Габделбасыйр
7) улы”.

## Яңа Балтач авылы зираты

**1. Билгесез кешегә куелган кабер ташы, XX гасыр башы.**

Таштагы текстның укылышы
Алгы ягы (калкытып һәм уеп язылган):
1) «Йәә вәәкыйфән би-кабрии
2) мүтәфәккиран би-әмрии
3) бил-әмси күнтү
4) мислүкә гадән тәсыыйру
5) мислии
6) Габдессадыйк
7) Мөхәммәдәмин углы”.
Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Алгы ягы:

1) “Әй, каберем янында басып торучы,
2) минем хәлем хакында фикерләүче,
3) кичә мин синең кебек
4) идем, иртәгә син минем шикелле
5) булырсың.
6) Габдессадыйк
7) Мөхәммәдәмин улы”.

Шулай итеп, Кыр-Каентүбәдә 5, Яңа Балтачта 1 борынгы кабер ташы ачыкланды. Киләчәктә, Актаныш районы ташъязма истәлекләрен тулысынча өйрәнеп бетерү зарур, чөнки 80 нән артык татар авылы булган районның фәкать чирегә генә диярлек эпиграфик планда өйрәнелгән. Өстәвенә, әле төбәктә 50 гә якын юкка чыккан сала исәпләнә. Бүгенге көндә Әҗәкүл, Аеш, Җизмуек, Илчебай, Иске Кормаш, Калмаш, Карт, Кәзкәй, Күҗәкә, Кыр-Каентүбә, Мари Суксуы, Мәчти, Такталачык, Түбән Карач, Түбән Үръяды, Чалманарат, Шәбезбаш, Яңа Балтачта сакланган кабер ташлары фәнни әйләнешкә кертелде. Аларның берсен татар галиме М. Әхмәтҗанов, 95 ен Башкортстан тарихчысы И. Васильев, 25 ен тарихчы Р. Кадыйров тикшергән, 6 сын без үзебез өйрәндек һәм бу өлкәдә эшебезне дәвам итәрбез дип уйлыйбыз.

## ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ЧЫГАНАКЛАР


1. *Әхмәтҗанов М.И.* XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре. – Казан, 2011. – 260 б.

2. *Ирдуганова Е.* Тереләрнең кадерен бел, үлеләрнең каберен бел: Актаныш районындагы борынгы кабер ташлары буенча материаллар // Актаныш таңнары. – 2017. – 28 июль. – Б. 3.

3. *Кадыйров Р.* Ташка уелган сәхифәләр: Актаныш районында эпиграфик һәм археографик эзләнүләр // Милли мәдәни мирасыбыз: Актаныш. – Казан: ТӘҺСИ, 2010. – Б. 60-81.

4. Материалы по эпиграфике Урало-Поволжья. Вып. 1. Арабографичные эпитафии Илишевского района РБ и Актанышского района РТ. 1882–1964 / Сост. И.М. Васильев. – Уфа: Мир печати, 2017. – 488 с.

# ИЗУЧЕНИЕ ЭПИГРАФИЧЕСКИХ ПАМЯТНИКОВ АКТАНЫШСКОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

***Гайнутдинов Айдар Марсилевич,***
*кандидат филологических наук,*
*Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ,*
*Казань, Россия,*
*aydargm@yandex.ru*

Эпиграфические памятники Актанышского района Республики Татарстан вплоть до 1998 г. практически не становились предметом изучения ученых. Лишь в последние годы некоторые историки начали вести научные изыскания по выявлению и систематизации древних намогильных камней. В результате, были изучены и введены в научный оборот 95 эпиграфический источник М. Ахметзяновым, Р. Кадыйровым, И. Васильевым. Автор статьи приводит тексты 6 намогильных плит, которые ранее не были никем изучены. На сегодняшний день выявлены и исследованы кладбища только четверти населенных пунктов Актанышского района. В дальнейшем, Институтом истории им. Ш. Марджани АН РТ планируется полное изучение эпиграфических материалов в данном регионе, т.к. они представляют большую ценность для истории и культуры татарского народа.

***Ключевые слова:*** Актанышский район, эпиграфические памятники, эпитафии, татары, намогильные плиты.

# THE STADY OF EPIGRAPHIC MONUMENTS OF THE AKTANYSH DISTRICT

***Gainutdinov A.M.,***
*Candidate of Philological sciences,*
*Marjani Institute of History of the*
*Tatarstan Academy of sciences,*
*Kazan, Russia,*
*aydargm@yandex.ru*

The epigraphic monuments of the Aktanysh region of the Republic of Tatarstan is practically did not become the subject of study by scientists until

1998. Only in recent years, some historians began to conduct scientific research to identify and systematize ancient gravestones. As a result, 95 epigraphic sources were studied and published by M. Akhmetzyanov, R. Kadyrov, I. Vasiliev. The author of the article cites the texts of 6 gravestones that have not been previously studied by anyone. Up to now, only one quarter of the whole settlements of the Aktanysh region have been investigated. In near future the Mardzhani Institute of History is planning a complete study of epigraphic materials in this region, which have a great value for the history and culture of the Tatar people.

***Keywords:*** Aktanysh district, epigraphic monuments, epitaphs, Tatars, gravestones.

УДК 908

# МЕТРИКА ЯЗМАЛАРЫНДА АКТАНЫШ ТӨБӘГЕ

***Сәлахова Эльмира Кадыйм кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты,*
*Казан, Россия,*
*ilsalah@mail.ru*

Метрика кенәгәләре дип аталган язма тарихи чыганак бай мәгълүмати эчтәлеккә ия. Бу төр документлар һәр төбәкнең үзенчәлеген, халыкның яшәү рәвешен, аның тормышындагы үзгәрешләрне күрсәтә торган чыганак. Татар халкының аерым төбәк тарихларын бу чыганаклар аша өйрәнү соңгы берничә елда гына башланды, гомумән, метрика кенәгәләренең тарихи чыганак буларак фәнни әйләнешкә керүе дә күптән түгел генә. Тәкъдим ителәсе мәкаләдә Татарстан республикасының үзенчәлекле бер төбәге – Актаныш ягы авылларының тарихы, халкының тормышы шушы төр чыганаклар аша яктыртыла. Актаныш төбәге тарихының метрика язмаларында чагылуын өйрәнү мәкаләнең максаты булып тора. Төбәкне әлеге документлар аша өйрәнү, аның тарихын әлеге ракурста карау беренче тапкыр башкарыла. Байсар, Актанышбаш, Иске Кормаш, Иске Гәрәй, Такталачык, Мәчти авыллары халкының үсеш динамикасы, вафат булу сәбәпләре, никахлашу географиясе карала. Аерым игътибар үзенчәлекле Мәчти авылы тарихына бирелде. Мәкаләдә бу авылның халкы, аларның яшәү рәвешләре күрсәтелә. Мәкаләдә чыгышы Мәчти авылыннан булган Россия мөселманнарының бишенче мөфтие М. Солтанов турында да язылды.

***Төп төшенчәләр:*** Актаныш, Мәчти, Байсар, метрика язмалары, төбәк тарихы, М. Солтанов, татар морзалары.

1829 елдан башлап алып барылган метрика язмалары татар тарихи чыганаклар базасының кабатланмас алтын фондын тәшкил итә. Имамнар, мөәзиннәр үз мәхәлләсендәге кешеләрнең гражданлык хәлен теркәгән әлеге документлар татар халкы тормышының билгеле бер тарихи этаптагы халәтен, үзгәрешен, үсешен күзәтергә, өйрәнергә зур мөмкинлек бирә. Бу документлар фактик материаллар җыелмасы гына булуга карамастан, аларда та-

тар җәмгыятендәге һәр кешенең эзе калган, алар аша һәр кешенең тарихтагы урынын, аның гомер этапларын күзәтергә була. Һәр төбәкнең метрика язмалары шул төбәкнең үзенчәлеген, аның уникальлеген күрсәтә торган документ. Шуның өстенә әле метрика язмалары шул як сөйләшенең тарихи истәлеге, татар теленең бар төсмерләрен дә үзендә саклап калган язма чыганак.

Актаныш – тарихы белән бай, үзенең асылы булган төбәк. Ул Татарстан районнарының башкаларыннан аерылып тора. Хәзерге көндә 32 750 кеше гомер иткән районның 96,4% ын татарлар, 2% марийлар, 0,69% урыслар, 0,9% башкортлар тәшкил итә. Актаныш – татар рухын саклаган, аның традицияләренә тугрыклы булган районнарның берсе. Инкыйлабка кадәрге чорда Уфа губернасының Минзәлә өязенә кергән бу төбәк 1920 елда Минзәлә кантоны буларак ТАССРның бер өлешен тәшкил итә башлый [10, б. 29-35]. Бу төбәк тарихи яктан катлаулы төбәк, авылларының нигезләнү тарихлары да, халкының социаль катламы да төрле. Төрле төбәктән, төрле вакыйгалар нәтиҗәсендә күчеп килгән халыкларны кабул иткән төбәк. Аның төрлелеге, катлаулылыгы метрика язмалары аша да күренә. Бу районга караган төрле авылларның метрика язмаларының информацион эчтәлеге дә берберсеннән аерыла.

Әлеге мәкалә элеккеге Байсар, Шәрип волостьларына караган Байсар, Мәчти, Актанышбаш, Иске Кормаш, Иске Гәрәй, Такталачык авылларының XIX йөзнең 70-80 нче еллар метрика язмалары мәгълүматларына таяна. Байсар авылы Минзәлә өязенең Байсар волостеның үзәге булган авыл. Бу – Минзәлә өязендә иң зур волость. XIX йөз ахырында аның составына 26 татар-мөселман авылы кергән, аларның күбесе берничә мәчетле зур авыллар, бары тик 2 авылның гына җәмигъ мәчет булмый, әмма аларның да гыйбадәт йортлары булган, әлбәттә [4, б. 93]. Тарихы 1754 елдан башлап билгеле булган Байсар авылында XIX йөз ахырында 298 йортта 1817 кеше гомер кичергән, 2 мәчет, мәдрәсә эшләп торган [10, б. 33]. Бу авылда почта станциясе булган, шимбә көннәре тирә-як халкын җыя торган базар эшләгән, эшкуарлар Байсар авылында 13 сату-алу лавкасы тоткан [4, б. 93]. XIX йөзнең 80 нче елларында

Байсарда ике мәхәлләдә туучылар 90-130 кеше була. Әлбәттә, вафат булучыларның саны да туучылар белән чагыштырганда азга гына калыша. Мисал өчен, 1883 елда вафат булучыларның саны туучыларның 64% тәшкил итә. Авылның зурлыгын билгели торган тагын бер факт ул – авылдагы никахлар саны. Байсар авылында елына 30-35 никах укылган. Авылы зур булгач, башка авылларга караганда талак саны да күбрәк, ул 7 гә кадәр җиткән [14; 16]. Никах вакытында бирелә торган мәһәр күләме дә авылның башка авылларга караганда хәллерәк яшәгәненә ишарә ясый. Әлбәттә, мәһәр күләме төрле факторларга бәйле, ул бары тик гаиләнең материаль байлыгыннан гына тормый. Мәсәлән, олырак кешеләр өчен, икенче, я өченче никахка керүчеләр өчен мәһәр күләме яшь кызга бирелә торганнан күпкә кимрәк булган. Байсар авылында XIX йөзнең 80 нче елларында күп кенә очракта никахка 500-600 сумлык мәһәр бирелгән. Бу заманы өчен кечкенә сумма түгел.

Актаныш ягы авылларында яшәүче кешеләрнең социаль катламы, сословиесе аерым сөйләшүне сорый. Бу бик катлаулы, четерекле сорау. Бу авыллар А.З. Әсфәндияровның «Аулы мензелинских башкир» дигән хезмәткә башкорт авыллары буларак кертелгән [2]. Мәсьәләнең асылына карарга теләмичә язу принцибы белән эш итү зур хата, тарихи мәсьәләгә сәясәт катнашса, икеләтә фаҗига. Дөрес, официаль исәп документларында, шул исәптән, метрика язмаларында да «башкорт» дип язган язулар бар. Әмма «башкорт» дигән сүз астында ни ята, аны анализлап торуны кирәк тапмыйлар, чөнки моңа күз йому аларга файдалырак, тарихчы булмаган гади халык, әлбәттә, ничек бар шулай кабул итә.

Актаныш төбәгенең тарихы катлаулы. Монда башка төбәкләрдән күчеп килүчеләр, хезмәте өчен җир кишәрлекләре алучылар яши. Гомумән, бик күп төрле катлау вәкилләре булган. 1937 елда Мәскәүдә басылган «История Татарии в материалах и документах» исемле җыентыкка кертелгән бер документта 1730 елда Казан губернаторы А.П. Волынский «Россия империясендә башкорт мәсьәләсенең торышы һәм аны чишү юлындагы алымнар» дигән язмасында «башкортлар» яшәгән җирләрдә халык

санының бик тиз темплар белән үсүен, аларның бу якларга җир салымының югарылыгыннан, төрле изүләрдән качып килүен әйтә. «Моннан 20 ел элек кенә 35-40 меңнән артмаган башкорт саны бертуктаусыз үзгәрә тора, һәм хәзер качкыннар хисабына 100 меңнән артып китте. Казан, Себер, Темников һәм башка өязләрдә яшәүче ясаклы татарларның яртысыннан артыгы башкортка күчте, башка христиан булмаган халыклар да, мордва, чуаш, вотяклар, бөтен авыллары белән, ясактан качып, шунда ук күчтеләр», – дип яза. Оренбург губернаторы И.И. Неплюев та XVIII йөздә үк башкортлар составы рус булмаган халыклар белән тулылануын язып тора. «Башкорт» атамасының социаль катлам булуы хакында хәзерге заман тарихчыларының да хезмәтләре бар [8, б. 71-112].

XVIII-XIX йөз документларында кулланылган «башкорт» атамасы этноним мәгънәсен аңлатмый. Мондый атамалар еш кулланыла торган ревизия документларында, метрика язмаларында халыкның социаль катламы күрсәтелгән, мондый документларга милләт исеме беркайчан да язылмаган. Мондый төр документлар өчен кешеләрнең нинди халыктан булуы мөһим дә түгел, алар салым түләүчеләрнең, армиягә алынучыларның төгәл исәбен, яшен белүне максат иткән. Диния нәзарәтенең метрика тутыру кагыйдәләре буенча метрикага сословиене язу таләп ителмәгән, бары тик атасы мещан, дворян, яисә мактаулы граждан булган очракта гына аларны күрсәтү кирәк диелгән [6, б. 16-21]. Әмма муллалар үз инициативалары белән авылның барлык башка катламнарын да язганнар. Мисал өчен, крестьян, зирагатьче, мулла, имам, мөәзин, типтәр, башкорт, хәтта падишаһ коллары дигән катлам да күрсәтелгән [11, кгз. 396 б.-397]. Соңгысын без бары тик бер авыл мулласының метрика язмаларында гына очраттык. Безнең фикеребезчә, дәүләт крестьяннарын шулай күрсәткән булуы ихтимал. Авылда берничә төрле катлам кешеләре яшәгән очракта, бер үк мәхәлләдә аерып ике исемлеккә язу очраклары бар. Мәсәлән, шул ук Минзәлә өязенә кергән Рангазар авылында (хәзерге Сарман районы) кайбер елларны шулай эшләнгән: «башкорт» сословиесе аерым, «типтәр» аерым бирелгән. Бу да метрика язмаларында бары тик социаль катлам гына язылуга бер мисал.

Байсарның беренче мәхәлләсендә катлам күрсәтелмәгән, анда «башкорт» сүзе юк, ә икенче мәчеткә караган мәхәлләдә яшәүчеләр барысы да «башкорт» катламы исеме белән бирелгән [14]. Иске Кормаш авылы метрика язмаларында да сословие бөтенләй күрсәтелмәгән [13]. Актанышбашның зур күпчелеге «башкорт» сословиесе белән язылган, әмма тулысы белән түгел [15; 17], Иске Гәрәй авылы кешеләре тулысы белән «башкорт» сословиесендә күрсәтелгән [18; 19]. Такталачык авылында да шул ук катлам кешеләре яшәгән [19]. Бу авыллар тарихына күз салсак, аларның нигезләнү вакыты XVII-XIX йөз аралыгында: Такталачык, Гәрәй авыллары тарихларын XVII йөздән башласа, Байсар (1754 ел), Иске Кормаш авыллары XVIII йөздә нигезләнә, Актанышбаш бераз соңрак – XIX йөздә барлыкка килә [10, б. 33]. Аларның тарихлары чагыштырмача яшь булулары да бу төбәккә җир кишәрлекләре алып, монда күчеп килгән кешеләр тарафыннан нигезләнгәнен күрсәтә.

Мәчти авылы да үзенчәлекле авыл. Бу авыл хәзерге Татарстан картасында юк, 1970 нче елларда бу авыл бетерелгән. Кайбер чыганакларда ул Наратлы исеме белән дә йөртелгән [7, б. 145]. Бу авыл хакында билгесез авторның кулъязма этнографик очеркы бар, аның төп нөсхәсе Казан университеты китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә саклана. Әлеге чыганак 2017 елда Х.З. Баһаветдинова тарафыннан өйрәнелеп фәнни әйләнешкә кертелде [3].

Кулъязма авторының язуына караганда, авылның нигезләнүе хакында берничә фикер бар. Мөфти булып торган Мөхәммәдъяр Солтановның ерак бабасы җир сатып алып шунда үз утарын булдыра, соңрак шул урында авыл үсеп китә. Икенче караш буенча, аның бабасы тугрылыклы хезмәте өчен әби патша – Екатерина II тарафыннан җир белән бүләкләнә. Ничек кенә булса да, авыл бүлеп бирелгән җирдә үсеп китә, авыл зур булмый, бу да аерым бай катламның утары булганлыкка ишарә. 1816 елгы ревизия вакытында бу авылда Солтановлар нәселеннән булган 26 ир-ат, 1834 елда – 43, 1850 елда – 37, 1859 елда – 39 кеше исәпләнә. Авылда «башкорт» сословиесендәге дворяннар һәм дворян бул-

маганнар да яшәгән, җирсез, ялланып эшләүче крестьяннар да булган. Солтанов фамилиясе астында да дворян титулы белән булучылар да, дворян булмаучылар да бар [3]. Бу авылның XIX йөзнең 70-90 нчы еллар метрика язмаларында, мисал өчен, обер офицерский чин, дворянин, сотник, есаул, поручик, урядник, башкорт дигән катламнар очрый. Аларның барысы да диярлек Солтанов фамилиясендә. Бу авылның метрика язмаларында тагын бер үзенчәлекле нәрсә – хәрби чинны, яисә дворянлыкны урысчалатып язу бар, ягъни «из дворян» дип күрсәтелә. Шулай ук мисал өчен шул чорда яшәгән дворян титулындагы кайбер кешеләрне китереп үтик: Шаһсолтан Шаһхәйдәр улы Солтанов, Шаһмөхәммәд Солтанов, Әхмәдшаһ Солтанов, отставкадагы ясавыл Шаһиморад Солтанов, Шаһимәрдан Дәүләтшаһ улы Солтанов, Шәехрамазан Солтанов һ.б. Шул ук Солтанов нәселеннән булган Мөхәммәдгали Габделгалләм улы Солтанов, Хөснетдин Габделмәннан улы Солтанов, Солтангәрәй Габдерәкыйб улы Солтанов һ.б. бары тик «башкорт» сословиесендә генә күрсәтелә [12].

Ни өчен кайбер Солтановлар дворян титулында булып, кайберләре дворян титулын йөртмәүләре хакында югарыда әйтелгән билгесез авторның кульъязма хезмәтендә җавап бирелә. Ул бу хакта ике төрле караш булуын күрсәтә. Беренчесе, Солтановның полковник чинын алганчыга кадәр туган балаларыннан киткән нәсел тармаклары балалары дворян титулын йөртмәгән, ә чинны алганнан соң туган балаларның нәсел дәвамчылары «потомственный дворянин» дип язылган. Әмма автор бу версия белән ризалашмыйча, үз фикерен түбәндәгечә аңлата: Солтанов поручик чинында булган, ул нәселдән килә торган дворянлык чинына ия булмаган, шул сәбәпле ул балаларына бу титулны тапшыра алмаган. Балалары исә моңа үз хезмәтләре белән ирешкәннәр, кайберләре дворян булып киткән, кайберләре исә бу дәрәҗәгә күтәрелә алмаган [3].

Бу авылның тормыш рәвеше метрика язмаларында да чагыла. Авыл утар буларак оешкан булганлыктан, әлләни зур булмый, әйткәнебезчә, авылда яшәүчеләрнең зур күпчелеген Солтановлар фамилиясе кешеләре тәшкил иткән, шулай ук аларда хезмәттә

булган башка фамилияләр дә бар. XIX йөзнең 90 нчы елларында 46 хуҗалыкта 280 кеше гомер иткән, аларның мәчете һәм 2 мәктәпләре булган [4, б. 93]. Метрика язмаларыннан күренгәнчә, мәхәллә зур булмаган. XIX йөзнең 70-90 нчы еллар аралыгында туучылар саны елына якынча 9-25 кеше. Башка авылларга да хас булганча, вафат булучылар саны да югары. Мисал өчен 1892 елда вафат булучылар саны туучылар саныннан 13 кешегә артык. Авыл халкы санының артуы түгел, ә бу чорда кимүе хакында сүз алып барырга кирәк. Бу елны вафат булучыларның зур күпчелеге кече яшьтәге балалар. Вафат булучылар 3 көнлек баладан башлап 12 яшькә кадәргеләр. Ул елны олы кешеләрдән бары тик 78 яшьлек кеше картаеп вафат булган. Бу авылда балалар үлеменең югары булуы күренеп тора, гомумән, вафат булучыларның күпчелеген, хәтта 90% тан артыгын яшь балалар тәшкил иткән. Вафат булу сәбәпләре, әлбәттә, шул заманда балалар арасында киң таралган йогышлы авырулар: чәчәк, кызамык, күкрәк зәхмәте, бума, баш, эч авырулары һ.б. Бу үзе дә югары катлам яшәгән авылда да медицинаның бик түбән дәрәҗәдә булуын күрсәтә.

Материаль яктан да бу авыл кешеләре тирә-яктагы башка авыллардан әлләни аерылып тормаган. Җир эшкәртү белән көн күргән мәчтилеләрнең табышлары зур булмый. Бу метриканың никахларны теркәгән сәхифәсендә дә күренә. Никах вакытында бирелә торган мәһәр күләменең суммасы төрле: нигездә, 100-500 сум аралыгында булган, әмма 100 сумнан кимерәк мәһәр бирү очраклары да бар. Бу – шул чорның татар авылларында бирелә торган уртача мәһәр күләме. Базарлы Байсар авылы бу яктан байрак, анда мәһәр күләме тирә-як авылларына караганда бераз гына зуррак: 600 сум, яисә аннан да артык мәһәр бирүчеләр бар.

Мәчти авылы мәхәлләсенең шул елларда метрикасын тутырып баручы, туучыларны, вафат булучыларны, никахларны, талакларны теркәүче – авылның указлы имам-хатыйбы, мөдәррис һәм мелласы Мәүләви Җәләлетдин мелла Әхмәдҗан улы Кутлин. Авылда ике уку йорты эшләгән: берсе мәчет каршында эшли торган башлангыч мәктәп, икенчесе – мәдрәсә. Соңгысында укучылар үзләре дә мулла булып киткәннәр. Метрикалардан

аңлашылганча, авылның укытучысы да Солтанов нәселеннән – Мөхәммәдзариф Солтанов булган, шулай ук укытучы буларак Низаметдин Мөхәммәдҗан улы да күрсәтелгән.

Мәчти авылы Солтановлар фамилиясе белән данлыклы. Бу нәселнең бер вәкиле – Мөхәммәдьяр Солтанов (1837-1915) бишенче мөфти буларак билгеле. М. Әхмәтҗанов Мөхәммәдъяр Солтановның тулы бер шәҗәрәсен түбәндәгечә күрсәтә: Туксаба – Шаһвәли – Тәвкил – Тәңребирде – Йулбирде – Акйул – Котлыш – Күзәй – Тотар – Чупан – Мәмәт – Солтан – Габделҗәлил – Баязит – Мөхәммәдшәриф – Мөхәммәдьяр [9, б. 32]. Солтановлар нәсел шәҗәрәсенең ике төрле күчермәсе бар: берсе – Р. Фәхретдинев фондында сакланса, икенчесе – Мөхәммәдъяр Солтанов үзе җибәргән варианты Ш. Мәрҗани хезмәтенә керә [9, б. 217]. Ш. Мәрҗани үз хезмәтендә аның турында бик кыска гына мәгълүмат биреп, бары шәҗәрәсен генә китерә. Бәлки шундый кыскалык, Мәрҗанинең бу шәхескә карата булган сагаюлы карашын да белдергәндер. М. Солтанов 1886 елда мөфтилеккә билгеләнгәндә, ул инде тәҗрибәле, дәүләт хезмәтләрендә эшләгән кеше була. 1857-1869 елларда башкорт-мишәр гаскәре башлыгында, 1861-1866 елларда Минзәлә кантонында, 1866-1875 елларда Минзәлә, Бәләбәй өязләренең суд системасында хезмәт итә. Ул гарәп, төрек телләрен белмәгән, шәригать кануннарын бары тәрҗемәдә генә укый алган. Ә урыс телендә исә иркен аралашкан. Моның өстенә М. Солтановны мөфтилеккә сайлауда Н.И. Ильминский зур роль уйнаган. Солтанов хөкүмәтнең бар кануннарын төгәл үтәүче мөфти буларак таныла. Р. Фәхретдинев аның Диния нәзарәте эшләрен тәртипкә салуын, архивын рәтләвен, китапханәсен тулыландыруын, гражданнарның сорауларына җавап бирүне тәртипкә китерүен, гади муллаларга хөрмәтле мөнәсәбәтен югары бәяли [1, б. 65-70].

С. Тәфкилев һәм М. Солтанов мөфтилек иткән чорларда Диния нәзарәте дини оешма булудан бигрәк, административ оешма буларак күз алдына килә.

Актаныш төбәге авылларының аралашу даирәсе, никахлашу географиясе үзе кызыклы бер тикшерү объекты. Кыз алу-бирүнең

үз традициясе генә түгел, ә аның тарихи нигезе бар. Бу гасырлар буе формалашып килгән нигезгә таянып эшләнгән. Хәзерге чордан аермалы буларак, кыз алу төрле җирдән булмаган, аның географиясенең үз закончалыгы булган. Кайбер авыл кешеләре үзләре аерылып китеп башка җирдә авыл нигезләсәләр, үзләренең тарихи ватаннарыннан, яисә нәсел тармаклары булган авыллардан кыз алганнар. Югары һәм бай катлам арасында барган никах тәртибе башкачарак. Бай катлам, бигрәк тә дворян титулындагы кешеләр, яисә имамнар еракка булса да, кызларын үз дәрәҗәсендәге кешеләргә бирергә тырышканнар. Мәчти авылында яшәгән дворян Солтановларның да кызлары кияүгә чыгып еракка киткән. Мисал өчен, дворянка Шәйхелзаман Солтановның кызы Бибирәхимә Бәләбәй өязе морзалар Каргалысының (хәзерге Оренбург өлкәсе) дворянин титулындагы Сәлимгәрәй Мөхәммәдгәрәй улы Чанышев никахында була. Бу авыл кешеләре үз авылдашлары белән дә никахка кергәннәр, Минзәлә өязендәге башка бик күп авыллар белән никах җепләре булу күренә. Мәсәлән, Чурпакай, Яхшы, Яңа Байсар, Апач, Кармыш, Аккүз, Такталачык, Пучы, Шәмәк һ.б. Актанышбаш, Иске Гәрәй авылларында, үз өязләрендәге авыллардан кала, Бөре өязе авыллары белән никахлар күзәтелә. Байсар авылы зур булганлыктан, авыл эчендәге, шулай ук өязнең башка авыл кешеләре белән теркәлгән никахларның саны күп, хәтта Казан өязенең Мәңгәр авылы белән бәйләнешләр булу да никахлардан күренә.

Метрика язмалары башка рәсми документлар бирә алмаган материалны җанлы итеп бирү көченә ия, чөнки алар шул чорда һәм шул урында яшәгән кешеләрнең рухын саклый, язучысы да шушы вакыйгалар эчендә яшәгән кеше булуы бу документларның мәгълүмәти куәтен арттыра. Метрика язмаларыннан күренгәнчә, Актаныш төбәгенең авыллар тарихы төрле, аларның һәрберсенең үз үзенчәлеге бар. Метрика язмалары аша бу төбәктә яшәгән халыкның социаль катламнарын өйрәнү тарих фәнендә шактый бәхәсле булган «башкорт» катламының эчтәлеген күз алдына китерергә дә ярдәм итә. Шулай ук метрика язмалары ярдәмендә авылларның аралашу даирәсен күзәтү тарихта барган халыкларның күчеш процессын өйрәнүгә дә материал бирә ала.

ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ЧЫГАНАКЛАР

1. *Азаматов Д.Д.* Оренбургское магометанское духовное собрание в конце XVIII–XIX вв. – Уфа: АН РБ, Уфимский научный центр, Институт истории, языка и литературы, 1996. – 193 с.

2. *Асфандияров А.З.* Аулы мензелинских башкир. – Уфа: Китап, 2009. – 600 с.

3. *Багаутдинова Х.З.* Историко-этнографический очерк «Описание села Мастеево Мензелинского уезда Уфимской губернии (1870-1880-е гг.)» // Исчезнувшие и исторические села: изучение, сохранение и возрождение. – Казань-Азнакаево, 2017. – С. 174-179.

4. Волости и важнейшие селения Европейской России. Вып. 6. – СПб., 1885. – 375 с.

5. *Әхмәтҗанов М.И.* Татар шәҗәрәләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 127 б.

6. Имамлык вә метрика язу эше // Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыя-и Оренбургия. – 1916. – № 11. – Б. 16-21.

7. Исчезнувшие населенные пункты РТ. Справочник. – Казань: Институт татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ, 2016. – 307 с.

8. *Махмутова А.Х.* Колыбель моя, Бизяки. – Казань: Яз, 2017. – 528 с.

9. *Мәрҗани Ш.* Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 415 б.

10. Населенные пункты РТ. Краткий справочник. – Казань, 1997. – 390 с.

11. Татарстан Республикасының Дәүләт архивы. 204 ф. 7 өст. тасв. 91 эш.

12. 204 ф. 8 өст. тасв. 62 а эш.

13. 204 ф. 177 тасв. 284 эш.

14. 204 ф. 177 тасв. 288 эш.

15. 204 ф. 177 тасв. 290 эш.

16. 204 ф. 177 тасв. 291 эш.

17. 204 ф. 177 тасв. 314 эш.

18. 204 ф. 177 тасв. 427 эш.

19. 204 ф. 177 тасв. 439 эш.

# АКТАНЫШСКИЙ КРАЙ В МЕТРИЧЕСКИХ КНИГАХ

***Салахова Эльмира Кадимовна,***
*кандидат исторических наук,*
*Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ,*
*Казань, Россия,*
*ilsalah@mail.ru*

Метрические книги являются уникальным документом с большим источниковедческим потенциалом. Метрические книги разных регионов отражают особенности этой местности, содержат ценную информацию о жизни народов, показывают их в развитии. Изучение метрических книг разных регионов как исторический источник началось лишь в последние годы, долгое время эти документы, к сожалению, незаслуженно были забыты. В представленной статье показаны динамика рождаемости, причины смерти, география бракосочетания жителей этого края. Результаты исследования опираются на метрические книги деревень Байсарово, Актанышбаш, Старое Курмашево, Старое Гареево, Такталачук, Мастеево. Целью статьи является изучение истории деревень и жизни жителей Актанышского края через призму метрических книг. Исследование в таком ракурсе проводится впервые. Основное внимание уделено истории деревни Мастеево, которая отличается своим основанием и составом жителей от других деревень этого края, а также уроженцу этой деревни М. Султанову – пятому муфтию мусульман России.

***Ключевые слова:*** Актанышево, Мастеево, метрические книги, краеведение, М. Султанов, татарские мурзы.

# AKTANYSH REGION IN PARISH REGISTERS

***Salakhova E.K.,***
*Candidate of Historical sciences,*
*Marjani Institute of History of the*
*Tatarstan Academy of sciences,*
*Kazan, Russia,*
*ilsalah@mail.ru*

Mahallah (Parish) registers are unique documents with a great source research potential. Registers of different regions reflect the features of this

area, contain valuable information about the life of peoples, and show them in development. The study of the Mahallah registers of different regions as a historical source began only in the last few years. This article shows the birth rate dynamics, causes of death, and the geography of marriage of the inhabitants of this region. The results of the study based on registers of the Baysarovo, Aktanyshbash, Old Kurmashevo, Old Gareevo, Taktalychk and Masteevo villages. The purpose of this article is to study the history of these villages and the life of their residents through the prism of registers. For Aktanysh region that research has been done for first time from this perspective. The main attention was paid to the history of the village of Masteevo as a village that differs from other villages in this region in its foundation process and mix of residents, as well as its famous as the native village of M. Sultanov – the fifth mufti of Russia.

***Keywords:*** Aktanysh, Masteevo, Parish registers, local history, M. Sultanov, Tatar noblemans.

УДК 908

# МӘЧТИ (НАРАТЛЫ) АВЫЛЫ ТАРИХЫН ҺӘМ МӘДӘНИЯТЕН ӨЙРӘНҮГӘ ЯҢА ЧЫГАНАК

***Баһаветдинова Халидә Зиннәт кызы,***
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты,*
*Казан, Россия,*
*halida12_61@mail.ru*

Мәкаләдә Актаныш районы Мәчти (Наратлы) авылы тарихы һәм мәдәниятенә багышланган кульязма чыганакка анализ ясала. Авылга нигез салучы Солтановлар белән бәйле риваятьләр, җирле халыкның тормыш-көнкүреше, бәйрәм һәм дини йолалары күрсәтелә. Мәчти авылында өстен катлау вәкилләре – дворяннардан булган Солтановлар нәселе яшәгән. Күренекле дин эшлеклесе, мөфти Мөхәммәдъяр Солтанов (1837–1915) шул нәселдән. Чагыштыру өчен башка чыганаклардан да мисаллар китерелде. Татар авылының икътисадый торышын да күрсәтергә тырыштык: кымыз белән дәвалау, токымлы атлар үрчетү заводлары һ.б. Кульязма чыганак 1870 нче елларда язылган. Бүгенге көндә Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге китапханәнең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана.

***Төп төшенчәләр**:* Мәчти авылы, Көнчыгыш Кама аръягы, Минзәлә өязе, Уфа губернасы, татар авыллары тарихы, Солтановлар нәселе, татарларның гореф-гадәтләре, бәйрәм йолалары, татар шәҗәрәләре, кымыз белән дәвалау, токымлы атлар үрчетү.

Археографик эзләнүләр вакытында, Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге китапханәнең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә Уфа губернасы Минзәлә өязе Байсар волостенә кергән Мәчти (Наратлы) авылы тарихына багышланган кульязмага тап булдык. (Сүз 1920 нче еллардан соң Актаныш районына кергән, 1976 нчы елларда юкка чыккан авыл турында бара).

Кульязма чыганакта Мәчти авылына нигез салучы Солтановларга караган риваятьләр, авыл халкының тормыш-көнкүреше,

бәйрәм һәм дини йолалары тасвирланган. Тарихи-этнографик чыганакның авторы билгесез. Әмма төбәк тарихы, этнография белән кызыксынучы, урыс милләтеннән булган земство хезмәткәре язган дип уйларга җирлек бар. Мәгълүматларны күрше авылдагы земство мәктәбе укытучысы сөйләгәнлеге аңлашыла. Язылу вакыты 1870 нче елларга туры килә. Кульязма чыганак рус телендә, 11 битне тәшкил итә. Үлчәмнәре: 175х220 мм, кара төсле кара белән пөхтә итеп язылган. Саклану берәмлеге 1766 [7, с. 1-11 об.; 3, с. 174-179].

Язма чыганак берничә бүлекчәдән тора: авылга нигез салучылар турында риваятьләр, авыл халкы, аларның шөгыльләре, торак җирләре, кием-салым һәм гореф-гадәтләре, бала-туу һәм мәет озату йолалары, бәйрәмнәр.

Кульязманың эчтәлегенә күз салыйк.

***Авылга нигез салучылар турында риваятьләр.***

Берничә версия китерелә: 1) Солтановларның бабаларының бабалары XVII гасыр ахырында яки XVIII гасыр башларында бу урыннан җир сатып алып утар төзегәннәр; 2) икенче риваять – Екатерина патшабикәгә тугрылыклы хезмәт иткән өчен ул Солтановларның өлкән бабасына морза титулы биргән һәм бу җирләрне бүләк иткән.

Авылда Солтанов-морзалар, Солтанов-морза булмаган нәселләр һәм күчеп килгән типтәрләр яшәгәннәр. Бер фамилиядә йөргән Солтановларның ике катлам булуын ничек аңларга соң? Бу мәсьәләне автор болайрак аңлата: 1) хәрби хезмәттә поручик дәрәҗәсенә генә ирешү (түбән чин) морза титулын алуга киртә булып торган, ә инде аларның балалары полковник дәрәҗәсенә ирешкәч, морза катламына (сословиесенә) кертkәннәр. (Бу урында искәртеп узарга кирәк: поручик Габделҗәлил Солтанов 1791 елда ук морза титулын ала. Шулай булгач, бу фикер дөрескә туры килми); 2) «Солтанов үзе морза булган булса да, бәлки аннан законсыз туган балалар Солтанов-морза була алмаганнар, күрәсең», – ди автор. Беренчеләре морза катламына язылса, икенчеләре Солтанов фамилиясенә генә ия булганнар. Әлбәттә,

бу фикер белән килешергә була, чөнки Солтановларның 2 дән алып 4 кә кадәр хатын белән яшәүләре мәгълүм.

Мәчти авылы тарихына багышланган хезмәтләрдә авылның барлыкка килүе турында башка фикерләр дә бар. Мәсәлән, язучы Вахит Имамов Байсар авылыннан Мәчти (Мәсәгут) Абызаев (1730-1797) аерылып чыгып, биш чакрым ераклыктагы Сикия елгасы ярында яңа утарга нигез салган һәм авыл аның исеме белән аталган дип фаразлый. Язучы фикеренчә, утар соңрак Солтановлар кулына күчкән [4, б. 125-139].

Башкортстан галиме, профессор А.З. Әсфәндияровның «Аулы Мензелинских башкир» дигән хезмәтен дә искә төшереп узарга кирәк [1]. Мәчти авылы тарихына багышланган хезмәтләрнең күбесе А.З. Әсфәндияров хезмәтенә нигезләнеп язылган дигән фикер туа.

Күренекле археограф, филология фәннәре докторы М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан төзелгән Солтановларның шәҗәрәсен искә төшереп узу урынлы булыр [2, б. 32].

Шәҗәрәнең 2 варианты бар. Икенче вариант – Санкт-Петербург шәһәрендәге Көнчыгышны өйрәнү институты архивындагы Р. Фәхретдинов фондыннан алынган шәҗәрә дөресрәк, тулырак дип уйлыйбыз. Беренче вариантта китерелгән Мөхәммәтрәхим белән Баязит бертуганнар, ягъни Габделҗәлил балалары. Димәк шәҗәрәнең соңгы буыннары түбәндәгечә: Солтан Габделҗәлил (1750) Баязит (1774) Мөхәммәтшәриф (1810) Мөхәммәдъяр (1837). Белгәнебезчә, бу нәселдән чыккан Мөхәммәдъяр – күренекле дин эшлеклесе, мөфти.

***Халкы***. Авылда «башкортлар» яшәгән. Аларның саны 10 ревизия материаллары (1858 ел) буенча 95 җан булса, 1870 нче елларда барлык гаилә әгъзаларын исәпкә алып 300 кеше дип исәпләнгән. Биләмә иясе Солтановларның йортлары туры урамда, ә күчеп утырган типтәрләр – тыкрыкларга урнашканнар.

Бу контексттa «башкорт» атамасы татарларда катлам (сословие) билгеләмәсе буларак кулланылган. «Башкорт» катламы чыганакларда 5 ревизиядән (1795) башлап кына барлыкка

килә. Алдагы ревизияләрдә бу авыл халкы «татар» дип күрсәтелгән.

***Халыкның шөгыле.*** Крестьяннарның җирләре аз булмаган. Төп кәсепләре – җир эшкәртеп икмәк үстерү. Җирле халык имана җирләрен үзләре ат җигеп сабан белән эшкәрткәннәр. Хәллерәк гаиләләрнең хезмәтче яллап эшләтүләре дә билгеле.

Иген игүдән тыш, елның 2-3 аенда, берничә гаилә кымыз ясау белән шөгыльләнә. Кулъязма авторы бабаларыннан килгән әлеге һөнәрнең юкка чыгу куркынычы барлыгын да искәртеп уза. Авыл халкының күпчелеге ялкау булуын, ашарына беткәч, көнгә 5 тиенгә ялланып эшләвен дә әйтергә онытмый.

Авылның 2-3 кешесе сәүдәгәрлек һөнәрен сайлый. Алар үз авылларында һәм якын тирәдәге базарларда сату итәләр. Сәүдәгәрләр, нигездә, типтәрләр катламыннан. Чыганактан күренгәнчә, авыл кешеләренең йорт тирәләрендә бакчалары булса да, бакчачылык киң таралмаган дигән фикер кала.

Бу урында чагыштырып карау өчен башка чыганакларны да күрсәтеп узасы килә. Такталачык хастаханәсе җитәкчесе, врач А. Цареградскийның 1888 елның октябрь аенда земство җыелышында ясаган чыгышыннан (татарчага тәрҗемә – *Б.Х.*): «Такталачык бүлекчәсендә эшләгәндә вазифам буенча һәм кайсыбер аерым кешеләрнең чакыруы белән, быел миңа кымыз белән дәвалау өлкәсендә билгеле булган Мәчтидә (Мастеево) булырга һәм бу эшнең торышы белән якыннан танышырга туры килде.

Мәчтидә дәвалanучыларның саны, шул сезонның иң кызган вакытында, уртача 80-120 кеше була; авыручылар арасында ялыктыргыч канцелярия эше белән хәлдән тайган шәһәр хезмәткәрләре һәм чиновниклар, имтиханнардан арып талган һәм аз канлылыктан җәфаланган укучылар. Мәчтигә нервлары авыручылар да килә, шулай да үпкә авырулылар процент ягыннан күбрәк, монда плеврит (үпкә ярысы) белән башлап һәм авыр туберкулез процессына кадәр, барысы да бар. Бу авыруларны аерым урнаштыру да, бернинди изоляция дә юк, киресенчә, әле генә чахоткалы авырудан бушаган бүлмәгә үпкә яисә аз канлы авырулар урнаша.

Дезинфекция дигән төшенчә бөтенләй юк. Гигиена тормыш тудырган шартлар белән бара инде. Кайбер хуҗалар 8 шешә кымыз эчертү шарты белән бүлмәләргә кертәләр. Теләсә теләмәсә дә, зарарлымы – файдалымы икәне белән дә исәпләшмичә, 8 шешә кымызны бер көн эчендә кеше эчәргә тиеш, башкача хуҗага акча керми. Минем үземә дә кымызны шулай күп эчкәннән ашказаны бозылып авыручыларны күрергә туры килде. Кайберәүләр биредә хәлдән тая, тирли һәм салкын тидерә.

Еш кына Мәчтигә авырулар белгечләр белән сөйләшмичә, бәлки килгәч киңәш табуларына өметләнеп киләләр, ә таба алмагач, нинди кымыз, ничек һәм күпме эчәргә икәнен белмиләр һ.б. Нәтиҗәдә биредәге «мәрхәмәтле» күрше, яисә кымыз хуҗасы киңәше белән файдалану авыруга берничек тә ярдәм итми.

Менә шундый шартларда Мәчти кымыз белән дәвалау үзәге табиблар тикшерүеннән башка, гигиена һәм дезинфекция таләпләрен үтәмичә 2 елдан артык эшләп килә. Бу чорда күпме йогышлы авырулар таралганын, күпме аз канлылар, нерв авырулары, плеврит белән җәфаланучылар биредән чахотка алып киткәнен күз алдына китерергә мөмкин.

Шушы хәлләрнең барысын да искә алып, Мәчти кымыз белән дәвалау үзәгенең файдасына караганда зарары күбрәк булганга, аны бөтен медицина таләпләренә туры килерлек итеп үзгәртергә кирәк саныйм; минем фикеремчә, аның киләчәктә гамәлдә булуы бары шушы шартлар белән бәйләнә дә» [6, с. 325-326].

Бу чыгыштан аңлашылганча, кымыз ясау шөгыле киң таралганы, санитар кагыйдәләрнең җитәрлек дәрәҗәдә үтәлмәве күз алдына килеп баса.

Шулай ук Мәчти авылында бу елларда, Мөхәммәтшәриф, Шайхелислам һәм Ишморат Солтановларның ат заводлары булуы турында мәгълүматлар бар. Алар токымлы атларны Минзәлә ярминкәсендә яисә үзләренең заводларыннан 100 сумнан 300 сумга кадәр бәһа белән сатканнар [9, с. 112-113].

Дәлия Ханнанова һәм Фәнүзә Сәяповалар «Туган авылым урамын соңгы кабат урадым» исемле хезмәтендә «Революциягә

кадәр, дворяннар Солтанова Әминә, Зөһрәләр кымыз санаторие тоталар. Кымыз ясау өчен махсус атлар да тоталар. Кымыз үләннәре булдыралар. Санаториягә дәваланырга килүчеләр өчен бөтен шартлар тудырылган була. Дәвалану биналары, торак биналары, ял итү өчен парк (наратлы олы бакча), су коену өчен Сикия елгасы тирәнәйтелгән», – дип искә алалар [5, б. 8].

Түбәндәге чыганаклардан, язмалардан, революциягә кадәр кымыз белән дәвалау очраклары Мәчти авылында киң таралыш алган дигән нәтиҗә ясарга була.

***Торак, кием-салым һәм гореф-гадәтләр.***

Авылда йортлар төрле: борынгы байлар йортлары, салам яки каеры белән капланган яңа йортлар, түбәләре бөтенләй ябылмаган йортлар да бар. Йортның эчке бизәлеше хуҗаның мөмкинлегеннән торган. Хәерчеләрнең өстәл белән урындыклары да юк. Шулай ук кайбер хуҗаларның шәһәр тормышына иярергә тырышуы да сизелә.

Киемнәре татарларга хас. Ирләр күлмәк, штан, читек яки итек, бишмәт, халат һәм түбәтәйдән, урамга чыкканда бүрек кияләр. Эшчеләр – күлмәк, шаровар, түбәтәй һәм кайвакытта чабатадан йөриләр. Ирләр сакал-мыек үстерәләр. Хатын-кызлары күлмәк, шаровар кияләр, һәрвакыт башларында яулык яки калфак. Чәчләрен толымлап үреп, көмеш тәңкәләр асалар, күкрәкләрендә күкрәкчәләр. Яшь кызлар тешләрен, кашларын, тырнакларын буйыйлар.

Калошлары булганнары читек өстеннән калош та кияләр.

Хатын-кызлар иртәдән кичкә кадәр хуҗалыкларында эшли. Ирләр мәчеткә йөри. Халыкны урамда күрмәссең. Кунакка, туйларга һәм җеназаларга баралар. Шулай, берәр хуҗага кунак килсә, бер-берсенә кунакка чакыралар. Хатыннар аерым, ирләр аерым йөри. Кайвакытларда кунак итү иртәнге сәгать 7 дән кичке 8 гә кадәр бара. Шушы 13 сәгать вакыт эчендә алар 5 йортта кунакта булалар, – дип яза автор.

Икенчесе – туй йоласы. Туйлар белән авылда барлык кешеләр кызыксына. Кайвакытта кияү һәм кәләшнең үзләреннән башка да

ярәштерү очраклары була. Шулай да кияү ягыннан кызга яучы җибәрәләр. Кызның әти-әнисе җавапны яучыга шул ук көнне бирми, кияүнең кем икәнлеген яхшылап тикшергәннән соң гына, кызның ризалыгын алгач, кияү йортына вәкил җибәрә.

Соңыннан мулла никах укый. Мәһәр күләме 50 сумнан башлана. Гадәттә мәһәрнең яртысы түләнә, ә икенче яртысы яшьләр аерылган очракта кайтарыла. Никахтан соң туй көне билгеләнә. Гадәттә дүшәмбе яки җомга көннәрендә уза. Никах белән туй арасында туйга хәзерлек башлана, бирнә һәм башка бүләкләр әзерләнә. Кияү кәләшкә күлмәк, читек һәм йөзек, ә кәләш, һичшиксез, түбәтәй һәм эчке кием бүләк итә. Туйга 1-2 көн кала кәләш туй ашлары хәзерләргә булышчылар чакыра. Әлбәттә, чәкчәк ясыйлар. Туй көнне, иртәнге сәгать 10 да, кәләш йортында туганнары һәм танышлары җыела, кияү ягыннан да вәкил килә. Мулла тагын бер кат никахны раслый. Бәйрәм итү 3-4 көнгә дә сузылырга мөмкин.

Кияү килгәнче, кызның апалары кәләшне киендерәләр дә, аерым бер бүлмәгә кертәләр. Кияү ишек алдына килеп керү белән ирләр аны каршы алалар һәм йокы бүлмәсендә аны сыйлыйлар. Аннан соң бүлмәгә кәләшне алып керәләр һәм алар иртәнгә кадәр бергә калалар. Иртән бер-берсенә бүләкләр бирү башлана. Хәтта яңа өйләнүчеләргә – ат, сыер, кәҗә бүләк итәргә мөмкиннәр. Кияү икенче авылдан булса, кызның әти-әнисе ризалык биргән очракта, кәләшне шул ук көнне алып китә ала. Кыз, гадәттә, әти-әнисе йортында калып тора, бу хәл ярты елга да сузылырга мөмкин.

***Бала-туу йолалары.*** Авырлы хатыннар балаларын үз йортларында тудыралар, ә кайбер очракларда кендек әбисен чакыралар. Убыр алып китмәсен өчен 40 көнгә кадәр баланы үзен генә калдырмаска тырышалар. Баланы һәм аның анасын өшкерәләр, баш астына Корьән аятьләре язып куялар. Туу белән баланы бишеккә салалар. Аның беренче азыгы – әнисенең күкрәк сөте. Бер атнадан чәчен кырып алалар, исем кушалар. Ир балаларны сөннәткә утырталар. Якын-тирәдә сөннәтче бабайлар юк, шуңа күрә казан

татарларын чакыралар. 3-4 яшькә җиткәч, балалар урамга уйнарга чыга башлыйлар. Кечкенәдән өлкәннәргә, бигрәк тә әнисенә карата зур хөрмәт тәрбияләнә. Бала 8 яшькә җиткәч, мәктәпкә йөри башлый. Авылда 2 мәктәп бар: берсе – малайларны рус теле һәм арифметикага өйрәтә, икенчесе – авыл муллалары әзерли. Кыз балаларны әниләре өйдә укыта. Яхшы укыган малайлар укуларын Казанда яки Оренбургта дәвам итәләр. Әлбәттә, бу очракта хәлле кешеләр генә үз балаларын укырга җибәрә ала. Күп очракта малайлар әтиләренә ярдәм итәргә хуҗалыкта калалар. Солдатка барып кайткач, үзләренең гаиләләрен коралар.

***Җеназа – мәет озату***. Үлгән кешене озату йолалары да, туу йолалары кебек киң таралган. Мәсәлән, хәлләре мөшкел булган авырулар, башка аракы эчмәс идем, тәмәке тартмас идем дип нәзер әйтә башлыйлар. Авыруның хәле тагын да начарланып китсә, мулла чакыртып ясин догасы укыталар. Авыру үлгәч, ирләрне ирләр, хатын-кызларны хатын-кызлар юалар. Суны комган белән чишмәдән алып кайталар. Юганнан соң кәфенлеккә төрәләр, хуш ис чыгып торсын өчен берничә бөртек индиго[9] салып калдыралар. Йортка да хуш ис тараталар. Мәетнең җаны күктәге Аллага барып җитсен өчен эшләнә. Ерактан кайтасы туганнары булмаса, мәетне шул ук көнне җирлиләр. Махсус кабыкка салып ирләр зиратка күтәреп алып баралар. Мәрхүмнең гәүдәсен алып чыгып китәр алдыннан мулла укый. Зиратка ирләр генә бара. Ислам дине кануннары нигезендә кабердә ләхет алу урыны әзерләнә. Мәетнең 3, 7, 40 көнлек, еллык ашлары уздырыла. Мулла дога укый. Чардуганнар бурадан яки таштан эшләнә. Борынгы каберләрдә чукып язылган ташлар да очрый.

Мәчти авылы зиратында Габделҗәлил Солтан улы Солтанов кабере чуеннан коелган булуын искәртеп узыйк. Кабер ташының алгы һәм арткы якларына, кырыйларына дини һәм дөньяви мәгълүматлар ташка уеп язылган. Шулай ук берничә җимерек төрбә калдыгы сакланган [8, б. 62].

---

[9] Казан татарлары камфара кулланалар.

***Бәйрәмнәр.*** Бәйрәмнәр яз һәм җәй көннәрендә була. Яз көне – Сабантуй, җәен – Җыен. Җыенны ярминкә яки базар көннәренә туры китереп атналар буе бәйрәм итәләр. Төрле уеннар: ат чабышлары, кул көрәшләре була. Бу көннәрдә эчкечелек һәм сугышу очраклары күпкә арта.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: Көнчыгыш Кама аръягында урнашкан татар авылларының гореф-гадәтләре, йолалары казан татарлары йолаларыннан аерылмый диярлек. Казан арты Вятка яклары татарларының да ул якларга килеп утырганнарын исәпкә алсак, бу авылларда татарлар яши дип әйтеп була.

Кулъязма төбәк тарихын өйрәнүче краеведларга, Мәчти (Наратлы) авылы тарихы белән кызыксынучы авыл халкына, шулай ук авыл тарихын өйрәнүче тарихчы, этнограф, фольклорчы галимнәрдә кызыксыну уятыр дип ышанабыз.

## ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ЧЫГАНАКЛАР

1. *Асфандияров А.З.* Аулы мензелинских башкир. – Уфа: Китап, 2009. – 600 с.

2. *Әхмәтҗанов М.И.* Татар шәҗәрәләре. – Казан, 1995. – 128 б.

3. *Багаутдинова Х.З.* Историко-этнографический очерк «Описание села Мастеева Мензелинского уезда Уфимской губернии (1870–1880-е гг.) // Исчезнувшие и исторические села: изучение, сохранение и возрождение. – Казань-Азнакаево, 2017. – С. 174-179.

4. *Имамов В*. Мәчти авылы // Мәйдан. – 2013. – № 8. – Б. 125-139.

5. Ханнанова Д., Сәяпова Ф. Туган авылым урамын соңгы кабат урадым. – Актаныш, 2010. – 106 б.

6. Из журнала XIV очередного Мензелинского уездного земского собрания с 11 по 18 окт. 1888 г. и доклады управы с приложениями к ним. – Казань, 1889. – С. 325-326.

7. КФУ НБЛ ОРРК. Ед. хр. 1766. С. 1–11 об.

8. Милли-мәдәни мирасыбыз. Актаныш. – Казан, 2010. – 415 б.

9. Памятная книжка Уфимской губернии с статистическою картой губернии. Ч. 1. – Уфа, 1873. – С. 112-113.

# НОВЫЙ ИСТОЧНИК ПО ИСТОРИИ И КУЛЬТУРЕ ДЕРЕВНИ МАСТЕЕВО (НАРАТЛЫ)

***Багаутдинова Халида Зиннатовна,***
*Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ,*
*Казань, Россия,*
*halida12_61@mail.ru*

В публикации дается анализ рукописи, посвященной истории и культуре деревни Мастеево (Наратлы) Актанышского района Республики Татарстан. В источнике приводится легенда об основателях деревни из рода Султановых, имеется информация о быте и жизни татар-хлебопашцев, их религиозной и праздничной обрядности. В этой деревне проживал род татарских мурз Султановых. Из него происходил видный мусульманский деятель, муфтий Мухамедьяр Султанов (1837–1915). Для примера представлена информация из других источников, в которых показано социально-экономическое положение местных жителей: кумысолечение, разведение племенных пород лошадей. Рукопись написана в 1870-х гг. В данное время она хранится в Отделе рукописей и редких книг Научной библиотеки им. Н.И. Лобачевского Казанского федерального университета.

***Ключевые слова****:* деревня Мастеево, Восточное Закамье, Мензелинский уезд Уфимской губернии, история татарских селений, род Султановых, обычаи у татар, праздничная обрядность, татарские родословные, кумысолечение, племенное коневодство.

# A NEW SOURCE ON THE HISTORY AND CULTURE OF THE MASTEEVO (NARATHLY) VILLAGE

***Bagautdinova Kh.Z.,***
*Marjani Institute of History*
*of the Tatarstan Academy of sciences,*
*Kazan, Russia,*
*halida12_61@mail.ru*

The publication analyzes the manuscript on the history and culture of the Masteevo (Narathly) village of the Aktanyshsky district of the Republic of

Tatarstan. The source contains a legend about the founders of the village from the Sultanov family, there is information about the life of the Tatar peasants, their festivals and religious rituals. The Tatar nobleman family of Sultanovs lived in this village. Famous by figure of prominent Mufti Mukhamedyar Sultanov (1837–1915). There are also the evidence from other sources provided which show the socio-economic situation of local residents: kumiss cure, horse breeding. The 1870s manuscript currently stored in the Scientific Library of Kazan Federal University.

***Keywords:*** Mastyevo Village, East Kama area, Menzelinsk district of Ufa province, history of Tatar villages, Sultanov family, Tatar traditions, kumiss cure, horse breeding.

# ПО СЛЕДАМ НАУЧНЫХ ЭКСПЕДИЦИЙ

* * *

# ФӘННИ ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЛӘРЕННӘН

УДК 398

# ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ТАРИХ ИНСТИТУТЫНЫҢ 1948 ЕЛДА АКТАНЫШ РАЙОНЫНДА УЗГАН ЭКСПЕДИЦИЯСЕ

***Закирова Илсөяр Гамил кызы,***
*филология фәннәре докторы,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты,*
*Казан, Россия,*
*ilzakirova@mail.ru*

Мәкаләдә Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Актаныш районында узган фольклор экспедициясе яктыртыла. Экспедиция вакытында фольклорчылар тарафыннан халык иҗатының төрле жанрларына караган бай материал туплана. Шулай ук Бөек Ватан сугышы турында истәлекләр, җыеннар турында мәгълүмат теркәлгән. Экспедиция барышында тупланган материал Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгенең фольклор фондында саклана.

***Төп төшенчәләр*: Татарстанның Актаныш районы, экспедиция, халык иҗаты, фольклорчы, әкият, истәлек.

Тел, әдәбият һәм тарих институтының Хәмит Ярми җитәкчелегендәге фольклор экспедициясе Татарстан АССРның Актаныш, Калинин[10] һәм Мөслим районнарында 1948 елның июнь-июль айларында эшли. Фольклорчылар Актаныш районында 19 авылда – Актаныш, Шәрип, Теләкәй, Иске Кормаш, Татар Суксу, Мари Суксу, Татар Әҗби, Куян, Илчебай, Такталачык, Әҗмәт, Югары Гәрәй, Түбән Гәрәй, Бурсык, Мәсәде, Чалманарат, Шәбез, Татар Әҗби, Дербёшка һәм Калинин районында 10 авылда – Пучы, Әнәк, Исәнсеф, Татар Бүләр, Уразмәт, Сикия, Түбән Яхшый, Мәчти, Иске Байсар, Иске Сәфәрдә эшлиләр.

[10] Калинин 1935–1959 елларда хәзерге Актаныш һәм Мөслим районнарыннан аерылып чыгып формалашкан, соңыннан шушы районнарга бүленгән район. Бу мәкаләгә Калинин районында тупланган материаллар да кертелде.

Экспедициядә Институтның ике галиме – экспедициянең җитәкчесе Хәмит Ярми белән Халидә Гатина, Казан дәүләт университетының өченче курс студенты, киләчәктә тарихи романнар авторы булып танылачак Нурихан Фәттах һәм икенче курс студенты Шаһидә Максудова, ул танылган язучы Гариф Ахуновның тормыш иптәше булачак, катнаша. Экспедициягә, киләчәктә фольклор секторына эшкә алуны күздә тотып, фәнни экспедицияләрдә эшләргә өйрәтү максаты белән, иң тырыш, белемле студентларны алалар. Бу студентлар, киләчәктә фольклорчылар булып китмәсәләр дә, экспедиция эше барышында халык авыз иҗаты буенча бай материал туплыйлар. Ай ярымга якын вакыт эчендә халык иҗатының күп төрле жанрларына караган материал туплана. Алар соңрак күп санлы җыентыкларда, 12 томлык «Татар халык иҗаты» академик басмасында урын алачак. Барлык җыелган материаллар Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгенең фольклор фондында 34 номерлы коллекциядә саклана. Коллекциядә татар фольклорының күп төрле жанрларына караган текстлар урын алган. Галимнәр Актаныш һәм Калинин районнарында 41 әкият, күп санлы кыска һәм сюжетлы җырлар, мәкальәйтемнәр, такмаклар һәм такмазалар, балалар һәм яшьләр уеннарына караган материал туплыйлар, хәзерге вакытта онытылып барган җыеннар турында мәгълүмат язып алалар.



Актаныш районы Иске Кормаш авылы информанты
белән Хәмит Ярми. 1948 ел



Экспедициядә юлда: Халидә Гатина, Шәһидә Максудова,
Нурихан Фәттах. 1948 ел

Экспедиция вакытында авылларда шактый гына әкиятчеләр булуы, әкият сөйләү традициясенең дәвам итүе ачыклана. Тупланган текстлар арасында тылсымлы әкиятләр дә, тормыш-көнкүреш әкиятләре дә, хайваннар турындагы әкиятләр дә бар. Аерым бер жанр буларак карала ала торган алдавыч әкиятләр дә шактый очраган. Алдавыч әкиятләр, исемнәреннән үк күренгәнчә, кешеләрне, кагыйдә буларак, вакытлы-вакытсыз әкият сораган балаларны, шаяртып сөйләнелә. Шактый гына алдавыч әкиятләрне Иске Байсар авылының ТБУМ (Тулы булмаган урта мәктәп) директоры, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Сәфәргалин Әхәт (1948 елда 44 яшендә) үзенең укучыларыннан язып алган, ул үзе туплаган такмаза һәм алдавыч әкият текстларын һәм экспедициягә килгән фольклорчыларга тапшыра.

Әкиятче информантларның иң яшенә 14 яшь була. Әнәк авылында яшәүче Рәхмәтулла Хисмәтуллин, киләчәктә Рахмай Хисматуллин дигән исем белән билгеле әдип булачак, Нурихан Фәттахка үз кулы белән язып 4 әкият тексты тапшыра. Татар Әҗбие авылында яшәүче 22 яшьлек Шәриф Закиров та Халидә Гатинага дүрт әкият яздыра. Шәриф Закиров бу әкиятләрне авыл картларыннан ишетүен сөйли. Нурихан Фәттахов Илчебай авылында Кәрам Афзаловтан, информантка 51 яшь була, 3 әкият,

Такталачык авылында Бәхтегәрәева Мәчтүрәдән (73 яшь) 2 әкият, Иске Байсар авылында Шәйхрази Фәхразиевтан (70 яшь) 2 әкият, Мәчтей авылында Госманов Габделганидән (73 яшь) 2 әкият, Бурсык авылында Мансур Шәйхетдиновтан (54 яшь) 2 әкият язып ала. Хәмит Ярми белән Халидә Гатина Иске Кормаш авылында Насыйри Фәррәховтан (40 яшь) ике тылсымлы әкият язып алалар. Сүз уңаеннан, шул ук авылда яшәүче Насыйр Фәттаховтан (40 яшь) «Урман каравылчысы» дигән әкият теркәлә.



Актаныш районы Иске Кормаш авылы яшьләре
Халидә Гатина белән. 1948 ел

Актаныш районында тылсымлы әкиятләргә караган «Алтын чүлмәк», «Каракош», «Яшьлек суы», «Урман каравылчысы», «Кыз патша», «Батыр егет» дигән әкиятләр язып алына. Бу әкиятләр «Татар халык иҗаты»ның «Әкиятләр» томнарында урын алган. Аеруча кызык тоелган берничә әкияткә тукталып үтик. «Алтын чүлмәк» әкиятен Татар Әҗбие авылында яшәүче 22 яшьлек Шәриф Закировтан Хәмит Ярми язып ала. Әлеге әкият татар халкына гарәп фольклорыннан кереп, аның сюжеты халыкка яхшы таныш, ул «Хоттабыч карт» әкиятенең бер варианты. Икенче өлеше гарәп халкының «Мең дә бер кичә» исеме белән мәгълүм әкият җыентыгыннан кергән сюжет. «Алтын чүлмәк» әкияте татар халкының гарәп әкиятләре тупланган «Мең дә бер кичә» ки-

табын яхшы белүен, бу текстларның халыклашуын күрсәтә. Иске Кормаш авылында Хәлисә Зиязовадан Х. Гатина язып алган «Каракош» әкиятенең сюжеты «Алсу чәчәк» әкиятенә якын. Әкият әлеге мәгълүм сюжеттагы кебек кече кызның төшендә бер чәчәк күреп, әтисеннән шуны алып кайтып бирүен үтенүе белән башланып китә. Атасы, күп кенә киртәләрне үтеп, чәчәкне эзләп тапкач, кызын әлеге чәчәкнең иясенә – Каракошка бирергә вәгъдә бирә. Әкият гаилә тормышы, ир белән хатын, кыз белән егет мөнәсәбәтләре турында шактый четерекле мәсьәлә күтәрә. Гаилә бәхетенең нигезе үзара хөрмәт, бер-берсенә ышану, юл куя белү кебек сыйфатлардан башлана, шул вакытта гына яныңдагы кеше, әкияттәге Каракош кебек, сиңа кирәк һәм кадерле кешегә әйләнә. Иске Кормаш авылында Насыйр Фәттәховтан Х. Ярми язып алган «Урман каравылчысы» әкиятенең герое ике диюнең сугышканын күреп, аларның берсенә ярдәмгә килә. Татар фольклорында бу мотив еш очрый. Диюләр, егеткә рәхмәт белдереп, тылсымлы көзге бүләк итәләр. Егет, шушы көзге ярдәмендә киртәләрне җиңеп чыгып, патша кызына өйләнә.

Актаныш районында тормыш-көнкүреш әкиятләре дә, эчтәлекләре белән тормыш-көнкүреш әкиятләренә якын торган Хуҗа Насретдин мәзәкләре дә язып алынган. «Кулсыз кыз» дигән әкиятне Илчебай авылында 51 яшьлек Кәрам Афзаловтан Н. Фәттах язып алган. Гаепсезгә рәнҗетелеп, куллары чабылып ире тарафыннан куып җибәрелгән кыз турындагы сюжет күп халыкларга таныш. Кызны, яла ягып, өеннән куып чыгаралар, биләүдәге баласын да иңенә асалар. Иелеп су эчкән вакытта кулсыз кызның биләүдәге баласы суга төшеп китә. Шул вакытта Аллаһының кодрәте белән кызга куллар үсеп, ул баласын тотып кала. Әкият кануннары буенча, барлык гаеплеләр җәзага тартыла, кызның гаепсез булуы ачыклана. Бу әкият явызлыкның, әшәкелекнең җиңелүен бәян итә.

Зирәк кызлар турындагы әкиятнең вариантларын Татар Әҗбие авылында Шәрип Закировтан Х. Ярми, Куян авылында Мингали Абзаевтан Н. Фәттах язып алалар. Бу әкиятләр халык арасында бик популяр булып, төрле вариантлары билгеле.

Актаныш районында 1948 елда әкият яздырган информантларның иң яшенә 14, иң өлкәне 70 не узган була. Алар арасында фронттан кайткан фронтовиклар да, мәктәп укучылары да, өлкән яшьтәгеләр дә бар.

Экспедиция вакытында аеруча кыска, дүртьюллык җырлар күп теркәлгән. Аларның төгәл саны – 7518 дүртьюллык. Һәр фольклорчы меңләп җыр тексты язып алган. Мәсәлән, Ш. Максудова дәфтәрләрендә генә 3000 тирәсе дүртьюллык җыр тексты теркәлгән. Әлбәттә, иң популяр җырларның һәр авылда һәм һәр информант тарафыннан кабатлануын искә алсак, бу сан күпмедер кими. Шулай да меңләгән текст язылу, кыска җырларның гаять популяр булуы турында сөйли. Һәр сүзе урынлы кулланылган, эчтәлегенең һәм строфа төзелешенең камиллеге сокландырган бу җырларда кешенең эчке кичерешләре бәян ителә, кеше үзенең сагыш-моңы белән уртаклаша. Телдән әйтеп бирә алмаган хисләрен җыр белән белдерә.

Әлеге җырларның тематик төркемнәре дә шактый. Алар арасында туган илне ярату, туган илне сагыну яки туган җирдән аерылу турындагы җырлар әһәмиятле урынны алып тора. Сан ягыннан иң күп әсәрләр – мәхәббәт җырлары. Аларны яшьләр уеннары вакытында да, мәҗлес-бәйрәмнәрдә дә башкарганнар, халык үзенең уй-кичерешләрен хатлар язганда җыр белән белдергән. Әлбәттә, экспедиция вакытында язып алынган җырларның иң зур күпчелеге мәхәббәт турында. Кыска җырларның тагын бер тематик төркеме – сугышка яки хәрби хезмәткә китүчеләр җырлары. Бу төргә кергән җырлар арасында борынгы, 25 еллык солдат хезмәтенә каралган рекрутлар җырлары да очрый, Бөек Ватан сугышы вакытында гына туган җырлар шактый. Экспедиция вакытында хат җырлары һәм истәлек дәфтәрләре җырлары да язып алынган. «Һәр чорның – үз җыры» ди халык, бу экспедиция вакытында тупланган җырларда да ачык күренә. Мәңгелек темалар һәм борынгы җыр үрнәкләре янәшәсендә партия, Ленин, Сталин турындагы җырлар да күп очрый. Галимнәр уку яшендәге балалар, үсмерләр белән дә эшли, уку алдынгылары, комсомол һәм

пионерлар турындагы җырлар нигездә алардан язып алынган. Халык җырлары калыбына салынган бу текстлар чорны, шул чордагы вәзгыятьне яхшырак күзалларга ярдәм итә.

Сугыштан соңгы экспедицияләр вакытында информантларның күбесе Бөек Ватан сугышында катнашкан кешеләр, шуңа күрә Бөек Ватан сугышы турында шактый гына истәлекләр дә теркәлгән. Сүз уңаеннан, фронтовиклар халык иҗатына караган шактый материал да яздырганнар. Истәлекләрдә сугыш ветераннары үзләре катнашкан яулар, сугышчан дуслары турында сөйлиләр. Шушы районда туып үскән геройлар турында истәлекләр дә очрый. Мәсәлән, Халидә Гатина Татар Әҗбие авылында 1892 елда туган Ханнан Маликовтан үз авылларында туып үскән Баян Дәүләтов турында истәлекләр язып ала. Белоруссия җирендә барган каты сугышлар вакытында 19 яшендә һәлак булган Баян Дәүләтовка Советлар Союзы герое исеме һәм Ленин ордены һәлак булганнан соң бирелә. Ханнан Маликов аның 2-3 яшендә әнисез, 10 яшьтән тулы ятим калган авыр балачагын, хәрби хезмәт турында балачактан хыяллануын сөйли, аның белән бәйле вакыйгаларны искә төшерә.

Сугыш турындагы истәлекләре белән уртаклашкан Такталачык авылында авыл советы рәисе Салих Шакиров (1911 елгы, 37 яшь) Бөек Ватан сугышын гвардия капитаны дәрәҗәсендә тәмамлый, сугышта «Кызыл байрак» ордены һәм «За отвагу» медале белән бүләкләнә. Шакиров Салих разведка бүлеге командиры була, истәлекләрендә дә немец тылына тел алырга барган вакытта булган вакыйгаларны искә төшерә. Гаярь татар егете тиз генә кирәкле карар кабул итә, үзен дә, сугышчыларын да саклый белә, беркайчан да кирәкле документларны яки телне кулга төшермичә кайтмый.

Калинин районының Уразмәт авылында яшәгән Мөхәммәтзия Вәлиев Ленинград һәм Сталинград фронтларында өч ел разведчик булган, истәлекләрендә Сталинград сугышы вакытында тел алырга барган бер көнне искә төшерә. Бу истәлекләр шулкадәр самими, аларда арттыру да, бизәп күрсәтү дә юк. Вәлиев Мөхәммәтзия (1948 елда 36 яшендә), 1941 елның августыннан башлап фронтта

булган разведчик-ефрейтор, сугыш вакытында дүрт мәртәбә яраланган.

Тел буенча беренче экспедицияләр оештыру сугыш алды елларында ук башланып китә. 1929 елда профессор Н.И. Воробьев җитәкчелегендә нократ татарларының тормышын өйрәнү өчен комплекслы экспедиция уздырыла. 1934-1935 елларда Ш.А. Рамазанов җитәкчелегендә татар әдәби теле гади халыкка ничек үтеп кергәнлеген өйрәнү максатыннан берничә экспедиция оештырыла, әлеге фәнни сәфәрләрнең маршрутлары Татарстанның Көнчыгыш районнарын да үз эченә ала. 1940 елда С.Х. Әмиров тарафыннан экспедицияләр өчен «Татар теленең диалектларын өйрәнү өчен сораулык» төзелә. 1939 елдан башлап Казанның Көнчыгыш педагогия институтында татар диалектларын системалы рәвештә оештырылган экспедицияләр ярдәмендә өйрәнәләр, әлеге эшчәнлекне М.А. Фазлуллин башлап йөри. 1938-1939 уку елында КДПИда татар диалектологиясе буенча махсус курс укытыла башлый. 1948 елдан Казан дәүләт университетында Рабига Хәкимова җитәкчәлегендә студентлар диалектология буенча кыр практикасы үтәләр. 1939-1952 елларда Татарстан җирлегендә тел буенча барлыгы 9 экспедиция үткәрелә – 26 алты төркем катнаша, 550 торак пункт өйрәнелә (бу вакытта Татарстанда 2100 торак пункт исәпләнә). Шулай ук читтән торып укучыларны җирле сөйләшләргә караган фактик материалны җыюга җәлеп итәләр, студентлар шулай диалектологиягә караган һәм фольклор материалларын җәйге практика хисабы рәвешендә тапшырырга тиеш булалар [12].

1948-1958 елларда өч кисәктән торган татар теленең беренче «Диалектологик сүзлеге» басылып чыга. Бу сүзлек махсус экспедицияләрнең сораулык-анкеталар ярдәмендә тупланган материалларына, шулай ук аерым урыннарның үзләрендә торып эшләүче җирле белгечләр җыеп, язып җибәргән фактик материалга нигезләнеп төзелгән. Мәсәлән, Актаныш төбәгенә караган *бикәч* – ана сарык, *мантару* – эшнең очына чыгу, булдыру, *силә* – арба сүрәсе, *тозыраю* – акаю һ.б. сүзләр урын алган [9].

Латыйф Җәләй Актаныш якларында берничә тапкыр була. Ул татар диалектологиясен мөстәкыйль фән дәрәҗәсенә күтәрүчеләрнең берсе. Аның җитәкчелегендә уздырылган гыйльми тикшеренүләр нәтиҗәсендә минзәлә сөйләшенең фонетик, грамматик һәм лексик үзенчәлекләре ачыклана, соңыннан әлеге экспедицияләрдә тупланган һәм анализланган материал аның татар теленең урта диалекты буенча язылган диссертациясендә дә урын ала. «Халык телендәге диалекталь фактлар тиешенчә өйрәнелмәгәнлектән, әдәби телнең үзенә яраклы материаллары таркау яталар, хәлбуки. Халыкның җанлы телен өйрәнү һәм андагы байлыкны туплау шушы телнең фәнни эшләнешен тиешле югарылыкка күтәрергә ярдәм итә. Шулай булгач, гомумән культура фронтында эшләүче кешеләр халкыбызның җанлы телен өйрәнүгә әһәмият бирергә тиеш», – дип яза диалектолог [10, б. 127].

1948 елда Актаныш төбәгендә фольклор экспедициясе үткәрелә. Х. Ярми җитәкчелегендә фольклористлар Актаныш районының төрле авылларында халык авыз иҗаты җәүһәрләрен җыюда катнашалар. Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә фольклор фондында әлеге экспедиция материаллары 4 папкада саклана. Төрле әкият, җыр-бәетләр галимнәр тарафыннан әдәби телгә күчерелеп, адаптацияләнеп барылган. Әмма шулай да сакланып калган папкаларда диалектологиягә караган берничә сораулык дәфтәр бар. Аларда Актаныш районының Иске Кормаш, Татар Суыксуы, Татар Әҗби, Актаныш авылы, Теләкәй, Такталачык, Шәрип һ.б. авылларында яшәүче җирле кешеләрдән язылып алынган кайбер диалекталь үзенчәлекләр теркәлгән. Мәсәлән, Актаныш районы Такталачык авылында Н. Фәттахов белән Ш. Максудоваларның «Анкета №1. Татарстанның диалектологик картасын төзүдә кирәкле материалларны аныклау өчен тутырыла. 1948 ел» дип күрсәтелгән дәфтәрләрендә минзәлә сөйләшенә караган фонетик, морфологик, синтаксик үзенчәлекләр, лексик берәмлекләр аерып күрсәтелгән [17].

Институтта 50 нче елларда диалекталь экспедицияләр уздыру план рәвешендә алып барыла. 1967-1969 елларда институт

хезмәткәрләре Ф.С. Баязитова җитәкчелегендә Татарстанның Көнчыгыш районнарына: Алабуга, Яр Чаллы, Минзәлә, Сарман, Мөслим, Актаныш, Башкортстанның Бакалы районына фәнни сәфәргә чыгалар. Актаныш районының берничә торак пунктын өйрәнәләр. 1973 елда бу якларда тагын бер экспедиция үткәрелә: Яңа Әлем, Иске Богады, Иске Байсар, Иске Кормаш, Татар Суыксуы, Мари Суыксуы, Уразай, Актаныш, Күҗәкә, Такталачык авылларында яшәүче халыкның сөйләм үзенчәлекләре тикшерелә. Диалектологиягә караган материаллар тагын да баетыла, ачыклык кертеләсе моментлар тәгаенләнә. Актаныш ягында җыелган материаллар әлеге фәнни тикшеренүләрдә катнашкан галимнәрнең аерым мәкаләләрендә, шулай ук «Урта Идел һәм Урал буе татар халык сөйләшләре атласы»нда теркәлгән. Атласның төзүчеләре: Н.Б. Борһанова, Л.Т. Мәхмүтова, Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова.

Л.Ш. Арсланов туган авылы Мари Ямалыда гомер итүче мари халкына татар сөйләме ни дәрәҗәдә йогынты ясаганлыгын тикшерә. Шулай ук Актаныш районының топонимиясендә килеп чыгышы ягыннан фин-угор элементларын өйрәнә.

Татар ономастикасы өлкәсендә күп көч куйган галимәбез Фирдәвес Гариф кызы Гарипова күп еллар дәвамында топонимик тикшеренүләр үткәрә, урыннарга чыгып, гади халык белән аралашып, торак пунктларда яшәп килгән микротопонимнарны, гидронимнарны теркәп бара. Мәсәлән, 1979, 1982 елларда Өшәр, Иске Кормаш, Кәзкәй, Еланлы, Яңа Әлем, Аккүз, Чалманарат, Иске Богады, Татар Суыксуы авылларына махсус топонимик сәфәр-экспедицияләр оештыра. Шулай ук Актаныш авылы буенча тикшеренүләр уздырып, торак пункты исеменең килеп чыгышын, микротопонимнарын җентекле өйрәнеп анализлый.

2009 елда ТР ФАнең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Актаныш районына комплекслы фәнни экспедиция оештыра. Абруйлы диалектологыбыз Д.Б. Рамазанова актанышлыларның тел үзенчәлекләрен лексик, фонетик, грамматик яссылыкта өйрәнә, Ф.С. Баязитова бай этнолингвистик

материал туплый, ономатолог Ф.Г. Гарипова авыл тарихларын тикшерә. Әлеге материаллар аерым китап-җыентыкта урын алган.

Күргәнебезчә, ТР ФАнең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Актаныш төбәгенә оештырылган фәнни лингвистик экспедицияләрдә тупланган этнографик, диалектологик, топонимик характердагы фактик материаллар тел буенча алынып барыла торган тикшеренү-эзләнүләрнең бай чыганагы, алар җентекле анализланып төрле китап, җыентык, мәкаләләрдә чагылыш таба.

## ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ЧЫГАНАКЛАР


1. *Арсланов Л.Ш.* Исследования по финно-угристике. – Елабуга, 2001. – 224 с.
2. Атлас татарских народных говоров / Отв. ред. Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хайрутдинова. – Казань: ИЯЛИ, 2015. – 632 с.
3. *Баязитова Ф.С.* Древний пласт лексики мензелинского говора // Исследования по исторической диалектологии татарского языка. – Казань, 1982. – С. 3-19.
4. *Баязитова Ф.С.* Мензелинский говор татарского языка // Материалы по татарской диалектологии. Вып 7. – Казань, 1989. – С. 67-83.
5. *Гарипова Ф.Г.* Татарстан микротопонимнары сүзлеге. Беренче китап. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 139 б.
6. *Гарипова Ф.Г.* Татарстан микротопонимнары сүзлеге. Икенче китап. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 139 б.
7. *Гарипова Ф.* Исемнәрдә ил тарихы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. – 264 б.
8. *Гарипова Ф.Г.* Актаныш, Атабай // Проблема функционирования, диалектологии и истории языка. – Казань, 1998. – С. 143-150.
9. Диалекталь сүзлек. – Казан, I. – 1948; II. – 1953; III. – 1958.
10. *Җәләй Л.* Татар диалектологиясе. – Казан: Татгосиздат, 1947. – 137 б.
11. *Залялетдинов Л.З.* Средний диалект татарского языка: автореф. дис. ... докт. филол. наук. – Казань, 1954.
12. Материалы по диалектологии татарского языка. Вып. 1. – Казань: Татгосиздат, 1955.
13. Милли-мәдәни мирасыбыз. Актаныш. – Казан, 2010. – 415 б.

14. Минзәлә сөйләше // Татар халык сөйләшләре. Ике китапта: Беренче китап / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 212-241.

15. *Рамазанова Д.Б.* Вопросы татарской диалектологии. – Казань, 2008. – 272 с.

16. *Рамазанова Д.Б.* Татар диалектларыннан сөйләү үрнәкләре: хрестоматия. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 556 б.

17. Центр письменного и музыкального наследия Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ. Фонд 34, ед. х. 47-48.

# ЛИНГВИСТИЧЕСКИЕ ЭКСПЕДИЦИИ, ОРГАНИЗОВАННЫЕ ИНСТИТУТОМ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА ИМ. Г. ИБРАГИМОВА АН РТ В АКТАНЫШСКИЙ РАЙОН РТ

***Булатова Альфия Каримовна,***
*кандидат филологических наук,*
*Институт языка, литературы и*
*искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ,*
*Казань, Россия,*
*alf_0082.82@mail.ru*

Маршрут многих лингвистических экспедиций Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ пролегал через Актанышский район Республики Татарстан. Такие научные полевые выезды способствовали обогащению и пополнению материалов этнографического, диалектологического и топонимического характера, которые имеют особое значение для лингвистических исследований.

***Ключевые слова:*** диалектологическая экспедиция, топонимическая экспедиция, мензелинский говор татарского языка, Актанышский район Республики Татарстан.

# LINGUISTIC EXPEDITIONS ORGANIZED BY IBRAGIMOV INSTITUTE OF LANGUAGE, LITERATURE AND ART OF THE TATARSTAN ACADEMY OF SCIENCES TO THE AKTANYSH REGION OF THE REPUBLIC OF TATARSTAN

***Bulatova A.K.,***
*Candidate of Philological sciences,*
*Ibragimov Institute of Language, Literature and Art*
*of the Tatarstan Academy of sciences,*
*Kazan, Russia,*
*alf_0082.82@mail.ru*

The route of many linguistic expeditions of the Ibragimov Institute of Language, Literature and Art of the Tatarstan Academy of Sciences ran through the Aktanysh region of the Republic of Tatarstan. Such scientific field reseasch give a lot of important ethnographic, dialectological and toponymic materials.

***Keywords:*** dialectological expedition, toponymic expedition, Menzelinsk dialect of the Tatar language, Aktanysh region of the Republic of Tatarstan.

# РОДИНА ПОЭТОВ, ПИСАТЕЛЕЙ, АКТЕРОВ

* * *

# ЯЗУЧЫЛАР, ШАГЫЙРЬЛӘР, АРТИСТЛАР ВАТАНЫ

УДК 792

# АКТЕР ВЕЛИКИХ СТРАСТЕЙ: МУХТАР МУТИН

***Салихова Айгуль Рустэмовна,***
*кандидат филологических наук,*
*Институт языка, литературы и*
*искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ,*
*Казань, Россия,*
*aygul.salikhova@gmail.com*

В статье дается общая оценка творчества актера, режиссера, общественного деятеля Мухтара Мутина. Его яркая и самобытная личность сыграла важную роль в обогащении национального театра новыми идеями, темами, выразительными средствами. Мухтар Мутин придавал большое значение произведениям русской и мировой классики. В статье анализируются его наиболее яркие актерские и режиссерские работы. Подчеркивается весомый вклад Мухтара Мутина в развитие татарского искусства.

***Ключевые слова***: Мухтар Мутин, актер, режиссер, татарский театр, спектакль, романтизм.

Мухтар Исхакович Мутин (1885–1941) – выдающийся театральный деятель, актер и режиссер, чье яркое и самобытное творчество сыграло важную роль в становлении национального театра.

Мухтар Мутин был подлинно романтическим актером, его называли Мочаловым татарской сцены. В формировании его актерского мастерства значительную роль сыграли его индивидуальные психологические особенности, склад мышления – способность мыслить размашисто, объемно, быстро вникать в суть явлений и делать философские обобщения, тяга к ярким поэтическим контрастам. Высокая патетика и пафос, пламенная страстность в манере исполнения соответствовали также и духу времени. Таланту М. Мутина были близки образы шекспировского масштаба, он укрупнял характеры, отбрасывал излишние с его точки зрения бытовые детали, романтически приподнимал все чувства. Будучи начальником культурно-просветительского отделения Централь-

ной мусульманской Военной коллегии в Москве, в 1919-1921 гг. М. Мутин стал основным лицом, определяющим художественное направление театра. При этом он считал, что пламенный пафос трагедии и героической драмы является школой высоких мыслей и чувств. Он с упоением ставил на татарской сцене произведения западноевропейских классиков: Шекспира, Шиллера, Гейне и других, выступая не только как режиссер, но и как исполнитель главных ролей: Отелло, Гамлета, Карла Моора, Альманзора и т.д. Особенности его темперамента, художественного видения и трактовки образов, характер исполненных им ролей дают возможность отнести М. Мутина к числу актеров-романтиков классического характера, тяготеющих к искусству монументальному и героическому [4, с. 198].

Один из видных исследователей театра А. Алперс в своей работе, посвященной актрисе В. Комиссаржевской, пишет: «... среди этих двуликих обитателей театрального королевства появляются в том же мире кулис и искусственного солнца реальные существа, которые принадлежат больше жизни, чем театру. Они приносят с собой на сцену свой собственный духовный опыт, свои человеческие чувства и выстраданные мысли о жизни. И все это они отдают без остатка своим сценическим созданиям. Для них не существует разделения актера на художника и человека. Они не умеют жить в двух планах, в двух измерениях. У них одно лицо, которое освещается улыбкой или кажется гримасой страдания, когда эти существа испытывают подлинную радость или душевную боль, где бы они ни действовали, в пьесах ли, сочиненных для сцены, или в реальных, невыдуманных драмах, которые разыгрывает с ними сама действительность. Таких актеров можно назвать заложниками жизни в сценическом искусстве. Они побеждают на сцене только тогда, когда остаются верными себе, своей человеческой природе, и терпят поражения в тех случаях, когда пытаются уйти от себя в мир воображаемых, а не пережитых ими чувств и мыслей. Их искусство близко к человеческой исповеди... Это – больше чем актеры, больше чем талантливые исполнители театральных ролей. Они обычно приходят в театр вестниками

глубоких изменений, которые совершаются в недрах современного им общества» [1, с. 386]. Мухтар Мутин был именно такой выдающейся личностью в татарском театральном искусстве.

Родился Мухтар Мутин в деревне Такталачык Актанышского района в 1885 году в семье крестьянина. Вскоре семья переехала в маленький городок Башкирии Белебей, где он окончил русскую гимназию. Там он впервые участвует в любительских спектаклях. Затем, окончив в Уфе бухгалтерские курсы, он поступает работать в Оренбургское магометанское духовное собрание. Однако вскоре Мухтар Мутин посвящает себя сценической деятельности, хотя и не состоит в какой-либо труппе. Женился он на русской девушке Елизавете Шляхтиной (которая впоследствии становится одной из известных актрис татарского и башкирского театров) и сделал ее своей соратницей на сцене и в жизни. Вместе они готовят программу и устраивают литературно-декламационные вечера. Во время гастролей труппы «Сайяр» в Уфе они участвуют в ее спектаклях. Кариев приглашает их в труппу, но Мутин отказывается. С постановками «Медведь» А.П. Чехова, «Благочестивое медресе» и «Живи, Зубайда, живу я» супруги гастролируют по Уралу и Сибири вместе с поэтом Сагитом Рамиевым. Мухтар Мутин выступает и перед русской аудиторией. В его репертуаре театрализованное произведение Алексея Апухтина «Сумасшедший», а также монологи героев произведений Шиллера, Шекспира, Ибсена, Гаупмана, овеянные романтическим настроением. В программах татарского концерта большое место занимают стихи Габдуллы Тукая, Сагита Рамиева. В произведениях, проникнутых свободолюбивыми мыслями и реальными предчувствиями социального и духовного обновления, выражались подлинные чувства Мухтара Мутина.

В 1912 году в Уфе была создана труппа «Нур» под руководством С. Гиззатуллиной-Волжской. Мухтар Мутин активно сотрудничает с этим коллективом. С 1915 года получает известность как талантливый актер и режиссер оренбургской труппы «Ширкат» («Товарищество»). Газета «Вакыт» довольно подробно освещает в то время работу трупп «Нур» и «Ширкат», в которых

играл М. Мутин. В их репертуаре помимо произведений татарских писателей были также классические пьесы: «Женитьба», «Ревизор» Гоголя, «Скупой» Мольера, «Разбойники» Шиллера. Последняя пьеса была поставлена с учетом особенностей таланта М. Мутина. Он сыграл в ней Карла Моора (1916 год). Уже после революции эта роль стала одной из самых ярких и впечатляющих в репертуаре актера.

Октябрьская революция, затем гражданская война явились почвой для развития героического искусства М. Мутина. В годы гражданской войны он играл во фронтовых труппах 1-й, 2-й, 5-й армий Восточного фронта. Мухтар Мутин был автором и исполнителем литературно-музыкальных программ по произведениям Мажита Гафури, Мухамедзакира Рамеева, Сагита Рамиева, Габдуллы Тукая, которые всегда вызывали интерес зрителей.

Во второй половине декабря 1918 года Мухтар Мутин приехал в Казань и поступил в Труппу татарских драматических артистов. В 1919-1922 гг. руководил театральным отделом Наркомпроса, принимал активное участие в перепрофилировании бывшего купеческого клуба (ныне здание русского ТЮЗа) в первое стационарное помещение Татарского театра. Одновременно с этим М. Мутин выполнял обязанности главного режиссера и художественного руководителя Первого Государственного показательного драматического татарского театра.

Первой постановкой М. Мутина в Труппе татарских драматических артистов стала романтическая драма Ф. Шиллера «Разбойники». Мухтар Мутин выразительными средствами режиссуры, своим исполнением центрального образа Карла Моора «укрупнил» свободолюбивые, бунтарские, героические мотивы произведения. Не случайно в объявлении о спектакле на страницах газеты «Эш» о «Разбойниках» говорилось как о «трагедии из жизни революционеров Германии». В объявлении выразилось стремление режиссера к «укрупнению» произведения через изменения его жанровой структуры, а также его поиски созвучия времени.

Как отмечает М.Г. Арсланов, М. Мутин выстроил свой спектакль по принципу «солиста и хора». На сцене главенствовал

«царь и бог» – Карл Моор – М. Мутин. А все остальные вокруг него были лишь более или менее необходимыми частицами целого, помогающими раскрыть мятежный, бунтарский дух главаря разбойников. Психологически насыщенный, в то же время романтически приподнятый образ Карла, являющийся центром, скрепляющим ядром постановки, потрясал зрителей бурным, взрывным темпераментом, страстностью, силой чувств, буйством характера. В своеобразной стилистике спектакля сливались воедино реализм и романтика, интеллект создателя спектакля и его эмоциональная мощь [2, с. 85].

Важнейшей вехой в решении героико-революционного спектакля и образов героев-современников стал спектакль по пьесе Г. Ибрагимова «Новые люди», поставленный к третьей годовщине Октября М. Мутиным. Режиссера-постановщика М. Мутина интересовал процесс утверждения идей революционного гуманизма в сознании людей. Сам М. Мутин в реалистичной, проникновенной манере сыграл в спектакле главную роль. «Батырхан в исполнении Мутина – много переживший, много испытавший человек средних лет. Однако, как было видно, испытания, трудности не сломили, не согнули его. Наоборот, закалили волю, сделали более сильным характер... Что интересно, с первых же минут сценического существования Мутин – герой-романтик, широко известный публике такими ролями, как Карл Моор, Фердинанд («Разбойники», «Коварство и любовь» Ф. Шиллера), пошел совершенно новым для него, неиспытанным путем. Он не романтизировал, не поднимал своего героя на пьедестал исключительности, как было прежде не раз, а стремился показать его обыкновенным человеком, простым смертным, ослабленным от ранения, уставшим с дороги, соскучившимся по родным и близким людям» [2, с. 94-95].

Среди постановок по русской классике особым успехом у зрителя пользовался «Ревизор» с участием и в постановке Мухтара Мутина. Театральная критика восторженно встретила спектакль. Она отметила необходимость и своевременность постановки «Ревизора» и, в первую очередь, правильное толкование образа Го-

родничего М. Мутиным. «Он с самого начала взял органичный и верный тон, – писал Г. Карам, – и довел его до конца. Четкая, свободная дикция, движения, позы заранее продуманы. Чувствуется, что М. Мутин много думал, много работал над ролью... Городничего могли считать одной из основных ролей репертуара актера» [3].

Одним из ярких творческих достижений М. Мутина стала роль Даута в спектакле, поставленном по пьесе Г. Кулахметова «Две мысли». Произведение, написанное еще в 1905 году в совершенно новом для татарской драматургии стилистическом ключе, в художественной структуре которого причудливо сочетаются, сливаются и составляют своеобразное единство, определяемое методом реализма, бытово-психологическое изображение действительности и символико-аллегорическое решение отдельных образов. Законы жизненного правдоподобия и приемы монтажа, наплывов только что зарождавшегося кинематографа, ставили перед создателями спектакля необычные задачи.

Событием сезона 1921 года стал «Гамлет» В. Шекспира в постановке режиссера Большого русского драматического театра Ю.В. Соболева. Режиссер прочел трагедию великого драматурга как страстную, захватывающую историю борьбы необычайно сильной и цельной личности за справедливость. Строя спектакль на резких романтических контрастах, сгущая и концентрируя драматизм действия, доведя до предела трагизм положения героя, его надежд и отчаяний, он через весь спектакль смог провести мысль о неизбежности торжества разума, справедливости. Постановка «Гамлета» на татарской сцене утвердила принципиально новый подход к произведениям классики. «Решительный», близкий больше Карлу Моору из «Разбойников» Ф. Шиллера, чем традиционному «страдающему» принцу, Гамлет – М. Мутин был плодом активной интерпретации пьесы Шекспира и новаторского понимания трагического как активного, созидательного и жизнеутверждающего начала. Бунтарский, протестующий, мятущийся Гамлет был подсказан актеру и режиссеру кризисным, поворотным моментом в истории страны, являлся отзвуком своего времени [2, с. 106].

С большим успехом в сезоне прошел также спектакль по другой бессмертной трагедии В. Шекспира «Отелло» с участием Мухтара Мутина в главной роли. Отелло М. Мутина – одаренный, чистый, доверчивый, способный на великие дела и большие чувства, обладающий мощным умом и широким полетом фантазии человек.

Таким образом, в начале двадцатых годов М. Мутин занимает в татарском театре особое место: он не только работает на руководящих постах, но и выдвигается в ряды самых ярких и самобытных актеров, заняв свою собственную нишу – романтического героя в трагических обстоятельствах.

Не удивительно, что в 1926 году, в связи с празднованием 20-летнего юбилея татарского театра, М. Мутин в числе первых, вместе с С. Гиззатуллиной-Волжской, З. Султановым, Б. Тархановым, К. Шамилем, К. Тинчуриным, получает почетное звание «Заслуженный артист Татарской АССР». Стоит отметить, что М. Мутин принял активное участие в подготовке этого юбилея и выступил одним из авторов-составителей книги «Татарский театр» (1926).

В двадцатые годы культурная жизнь Казани была бурной и нестабильной. И Мухтара Мутина судьба также забрасывала в различные сферы деятельности. Он ставит и играет в разных театральных коллективах (в Москве, Уфе, Буинске), работает диктором и режиссером в радиокомитете Татарстана, участвует в создании первой татарской кинокартины «Булат батыр».

В 1932 году Мухтар Мутин возвращается на сцену Татарского государственного академического театра и занимает в нем прочное положение. Помимо героико-романтических ролей в его репертуаре появилось множество психологически глубоких, реалистичных образов.

В годы сталинских репрессий Мухтар Исхакович стал жертвой режима. 24 апреля 1937 года был арестован. Военной Коллегией Верховного Суда СССР от 19 сентября 1937 года был обвинен «как участник троцкистской организации», приговорен к лишению свободы на 10 лет. Вернуться домой ему больше не довелось.

3 июня 1941 года он скончался в Магаданской области, где отбывал срок в лагере. Мухтара Мутина реабилитировали посмертно 1 августа 1963 года.

ЛИТЕРАТУРА И ИСТОЧНИКИ

1. *Алперс Б.* Театральные очерки. Т. I. – М.: Искусство, 1977. – 567 с.
2. *Арсланов М.Г.* Татарское режиссерское искусство (1906-1941). – Казань, 1992. – 333 с.
3. *Кәрам Г.* Татар сәхнәсендә «Ревизор» // Татарстан хәбәрләре. – 1921. – 14 февраль.
4. *Салихова А.Р.* Романтические тенденции в татарском театре // Научный Татарстан. – 2012. – № 1. – С. 195-201.

## ACTOR OF GREAT PASSIONS: MUKHTAR MUTIN

***Salikhova A.R.,***
*Candidate of Philological sciences,*
*Ibragimov Institute of Language, Literature and Art*
*of the Tatarstan Academy of sciences,*
*Kazan, Russia,*
*aygul.salikhova@gmail.com*

The article gives a general overview of the activities of the actor, stage director, public figure Mukhtar Mutin. His bright personality played an important role in enriching the national theater with new ideas, themes, expressive means. Mukhtar Mutin attached great importance to the works of Russian and world classics. The article analyzes his most prominent acting and director's work. The significant contribution of Mukhtar Mutin to the development of Tatar art is emphasized.

***Keywords:*** Mukhtar Mutin, actor, stage director, Tatar theater, performance, romanticism.

УДК 82:801.6

# МӨХӘММӘТ МИРЗА ИҖАТЫНДА ТУГАН ЯК МОТИВЫ

***Йосыпова Нурфия Марс кызы,***
*филология фәннәре докторы,*
*Казан федераль университеты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты,*
*Казан, Россия,*
*faikovich@mail.ru*

Әлеге мәкалә чикләрендә М. Мирза иҗатының идея-сәнгати үзенчәлекләре тикшерелә, туган як мотивының чагылышы өйрәнелә. Тикшеренү барышында шагыйрь иҗатында яшәеш кануннарын билгеләргә омтылган, гомумкешелек кыйммәтләрен аерып куйган, лирик геройның туган җиренә, халкына булган чиксез мәхәббәтен гәүдәләндергән әдәби модельнең алга куелуы хакында нәтиҗә ясала. Әлеге модель «мин» исеменнән сөйләүче үзенчәлекле лирик герой концепциясенең формалашуына йогынты ясый.

***Төп төшенчәләр:*** текст, мотив, татар поэзиясе, образ, традицияләр, М. Мирза.

Мөхәммәт Мирза – XX–XXI гасыр чиге татар поэзиясе үсешенә, аның яңарышына зур өлеш керткән шагыйрьләрнең берсе. Аның шигырь-поэмаларында укучы хөкеменә кешене олы кыйммәт итеп күтәргән, кешелекнең яшәеш кануннарын аерып чыгарган яисә тормыш закончалыкларын тәнкыйть утына алган үзгә бер әдәби модель тәкъдим ителә [1, б. 1-2]. М. Мирза иҗаты мотивлар төрлелеге ягыннан да үзенчәлекле кабул ителә. Бер яктан, яшәеш мәгънәсен эзләү мотивы калку чагылыш таба һәм шагыйрь иҗатын фәлсәфи яктан баета; икенче яктан, җәмгыятькә бәя мотивы калкулана, шуңа бәйле милләт язмышы хакында уйлар тирәнәя, бу исә ирония, сарказм белән баетылган тәнкыйди башлангычка юл бирә; өченчедән, авыр кичерешләрдән юануны балачактан, авылда үткән яшьлек сукмакларыннан, мәхәббәттән, Ана җылысыннан эзләгән эмоциональ лирик герой туган як моти-

вын калкуландыра һәм шагыйрь иҗатын лирик-эмоциональ, вакыты белән сентименталь дулкынга көйли.

«Ил нидән башлана: / кавем, ыруданмы? / ... гаилә коруданмы» кебек сорауларга җавап эзләгән М. Мирзаның аерым шигырь-поэмаларында ил, халык язмышы хакындагы фикерләр туган нигез кадере, туган якка мөнәсәбәт, татар авылы язмышы, гореф-гадәтләр, йолалар сакланышы турында уйланулар белән кушылып китә, яшь буынның мәдәни кыйммәтләргә мөнәсәбәте мәсьәләләренә ялгана.

«Ил-мәйданда төш түгел», «Сабантуй», «Агыйделдә ак пароход», «Нишләр идем» һ.б. күпләгән шигырь-поэмалар да шул хакта сөйләп мәйданга чыга. Әйтик, «Сабантуй» поэмасында Сабантуй гади бер гомумбәйрәм, җыен гына түгел, милләтне берләштерүче, традицияләрне сакларга мөмкинлек бирүче, татарга гайрәтен, холкын, бердәмлеген, дөньяга карашын җиткерергә ярдәм итүче КӨЧ югарылыгына күтәреп тасвирлана. «Ил-мәйданда төш түгел» әсәрендә нәкъ менә Сабантуйның сугыштан соң халыкны тыныч тормыш шартларына кайтара алуы бәяләнә. Һәр ике әсәрдә Сабантуйның совет чорында – милли кыйммәтләр кире кагылган дәвердә – милли хис-тойгыларны, йола-гадәт, традицияләрне саклап калырга ярдәм итүе ассызыклана.

Туган як мотивы берләштергән аерым шигырь-поэмалар структурасында сафлык, матурлык, мәхәббәт, югарыга-биеккә омтылыш, кадерле кешеләр сурәте калка. Мондый шигырь-поэмаларда милләт, халык язмышы, иҗтимагый гаделсезлек хакындагы авыр кичерешләрдән юануны, рухи камиллекне, матурлыкны, гармонияне балачак хатирәләреннән, авылда үткән яшьлек сукмакларыннан, Әнкәсе катыннан эзләгән эмоциональ лирик герой алга чыга, әсәрләр лирик-эмоциональ, вакыты белән сентименталь дулкында кабул ителә. Мисал өчен, «Йолдызлы басу», «Әнкәй», «Авылым чишмәсе» һ.б. шигырь-поэмаларында М. Мирза асыл ышанычны, рухи кыйбланы балачагы калган үткәннәрдә, өлкән буынның яшәү рәвешендә таба, авыл мохитен, яшәешен югары күтәрә, туган туфракны ярату, җирсү хисен үзәккә ала. Мондый шигырь-поэмалар, кагыйдә буларак, катгый, анык, эзлекле сюжетка корылмыйча,

тормыш-яшәешкә хас бер идея-төшенчә яисә күренешкә, лирик геройның аерым хатирәсенә бәйле туган фәлсәфи-лирик уйланулар формасында языла. Алар мәңгелек идеяләр, кыйммәтләр һәм төшенчәләр хакында тирәнтен уйланулар булып аваз сала.

Бу яктан «Йолдызлы басу» поэмасы аерым бер җылылык белән сугарыла, балачак хатирәләре аша тергезелгән якты моң (хис) үзәккә куела. Йолдызлы күк, йолдызлар атылуы, икмәк исе, әни җылысы, чикерткәләр җыры кебек образ-детальләр, сурәтләр, туган авылы Чалманарат күренеше ярдәмендә балачак хатирәләре күз алдына бастырыла, туганнарның, туган якның кадерле һәм газиз җир булуы төгәлләштерелә. Лирик герой өчен йолдыз атылган төн бөтен гомерен, иҗат юлын яктыртып торучы, яшәешнең төп миссиясен, асылын, кыйммәтен аңларга мөмкинлек бирүче изге хатирәгә әверелә.

«Куян күчтәнәче» поэмасында шагыйрь әнкәсен яратып, аерым бер җылылык белән сурәтли, унлы чалгы, куларба тарткан иңнәр, ак төс, арба тартып йөзеп килү кебек образ-детальләр, гыйбарәләр барысы да аның эчке дөньясын, яшәешенең асылын ачуда файдаланыла:

Зәңгәр борчаклы ак күлмәгенә
Ак алъяпкыч япкан, ап-актан,
Ап-ак җилкән кебек йөзеп килә
Куларбасын тартып ерактан [3, б. 308-309].

Икенче яктан, «куян күчтәнәче» белән әтисен шатландырган, әнисен авыр газаплардан коткара алган малай батырлыгы укучы күңелендә якты моң хасил итә. «Әнкәй» поэмасында Ана изгелек, игелеклелек, батырлык, яшәү кыйммәтләренең идеалы, илаһи югарылык итеп күтәрелә. Поэманың буеннан-буена шагыйрь шушы кыйммәтләрнең чыганагын эзли һәм таба – ул Ана булуда икән! Ана булу бәхетен тойган хатын-кыз дөнья-яшәешне башка үлчәүләргә салып, үзгә кыйммәтләр белән үлчи, тормышяшәешкә башка күзләр белән карый! Бу фикерен автор төп идея төсендә укучыга тәкъдим итә. «Кош теле» шигырендә кош теле образы шундый уйланулар белән өретелә:

Кош теле җибәргән әнкәй,
Күчтәнәчкә авылдан.
Каптым, тик йота алмадым,
Куркып телсез калудан [3, б. 227].

Шигырь кысаларында кош теле образы, әнкәй пешергән татлы ризык булудан тыш, бала белән ана арасындагы илаһи мөнәсәбәтләрне, җылылыкны, кош теледәй хатларны да гәүдәләндерә. Нәни кош теленә әнкәйнең кул һәм йөрәк җылысы сеңә алган кебек, кечкенә генә шигырьләр дә зур фәлсәфи фикерләрне җиткерергә, олы хисләр турында җырларга сәләтле!

Шуның белән янәшәдә М. Мирзаның аерым шигырьләрендә татар авылы язмышы, аның киләчәге турындагы уйланулар лейтмотив төсен ала. Мисал өчен, «Кара каен» шигырендә кара каен образы ак каеннар турында шигырь укып күнеккән укучыны сискәндереп куя, алга таба строфадан-строфага аның каралыгының сәбәпләре ачыкланып бара, шуңа бәйле төстә ул берничә мәгънәне үзенә сыйдырган символ дәрәҗәсенә күтәрелә. Бер яктан, мәңге табылмаслык бәхетне эзләп, авыллардан, әнкәләре катыннан киткәннәрне хәтерләткән кылганнар һәм карга оялары образлары белән янәшәлектә ул ташландык нигез кебек укыла. Икенче яктан, шушы ук образлар белән янәшәлектә ул юкка чыккан авыллар белән ассоциация тудыра. Өченче яктан, лирик геройга гомеренең үтүенә бәйле туган сызлануны җиткерергә ярдәм итә:

Япа-ялан кырда
Шадра кара каен...
Охшап барам аңар,
Гомер үткән саен.
Буразнасын ярып,
Кара ятты йөзгә...
Янып бетеп гомер,
Кереп барам көзгә [2, б. 32].

Шуның аша М. Мирза табигатьтә генә түгел, яшәештә дә һәр кеше ялгыз, фани, вакытлы, үтә-югала, дип кабатлый. Шушы ук фи-

керне «Киек каз юлында» шигырендә киек каз образы аша җиткерә (Калулар юк, калулар юк / Дөньяда – кыйгак, кыйгак... кыйгак). Әнә шулай М. Мирза шигърияте татар поэзиясе киңлекләрендә киң яңгыраш тапкан туган як мотивын үзенчә яктырта, үзенчәлекле сурәт тудыру юлларын, чалымнарын табуга ирешә.

ӘДӘБИЯТҺӘМ ЧЫГАНАКЛАР

1. *Йосыпова Н.М.* Татар шигъриятендә шәркый традицияләр яңарышы: М. Мирза иҗаты // Мирза М. Сайланма әсәрләр: биш томда. Т. 1. – Казан: Мәгариф – Вакыт нәшр., 2018. – Б. 1-35.

2. *Мирза М.* Берүземә бер диңгез. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 222 б.

3. *Мирза М.* Сайланма әсәрләр: биш томда. Т. 1. – Казан: Мәгариф – Вакыт нәшр., 2018. – 529 б.

## МОТИВ РОДНОГО КРАЯ В ТВОРЧЕСТВЕ МУХАММАДА МИРЗЫ

***Юсупова Нурфия Марсовна,***
*доктор филологических наук,*
*Казанский федеральный университет,*
*Институт языка, литературы и*
*искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ,*
*Казань, Россия,*
*faikovich@mail.ru*

В статье раскрываются мотив родного края и идейно-художественные особенности лирики М. Мирзы. В ходе исследования утверждается, что в его лирических произведениях порождается своеобразная литературная модель, которая намечает общечеловеческие каноны бытия, воспевает общечеловеческие, вневременные ценности, выражает любовь лирического героя к родному краю. Выстраивание в творчестве такой модели структурирует особый тип лирического героя, который выступает от имени «я» как представитель «малой родины» или своего поколения.

***Ключевые слова:*** лирика, мотив, татарская поэзия, образ, традиции, М. Мирза.

# THE NATIVE LAND’S MOTIF IN THE WORKS OF M. MIRZA

***Yusupova N.M.,***
*Doctor of Philological sciences,*
*Kazan Federal University,*
*Ibragimov Institute of Language, Literature and Art*
*of the Tatarstan Academy of sciences,*
*Kazan, Russia,*
*faikovich@mail.ru*

The article reveals the native land’s motif and the ideological and artistic features of M. Mirza's lyrics. In the course of the research, it is argued that his lyrical works generate a kind of literary model that outlines the universal canons of being, praises universal, timeless values, and expresses the lyrical protagonist’s sense of love for his native land. Building such a model in creativity create a special type of lyrical protagonist who acts on behalf of the his own “Self” as a representative of the “small homeland” or his generation.
***Keywords:*** lyrics, motive, Tatar poetry, imagery, traditions, M. Mirza.

УДК 821.512.145

# МӘХӘББӘТЛЕ ШИГЪРИЯТ (ЛЕНАР ШӘЕХ ШИГЪРИЯТЕНӘ БЕР КАРАШ)

***Абдуллина Диләрия Марат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты,*
*Казан, Россия,*
*gibadullina_13@mail.ru*

Мәкаләдә Татарстан Республикасының Актаныш районында туыпүскән, бүгенге татар шигърияten үстерүгә саллы өлеш керткән шагыйрь Ленар Шәех иҗаты яктыртыла. Аерым алганда, шагыйрьнең мәхәббәт, гражданлык лирикасы тикшерелә, иҗатының кайбер үзенчәлекләре анализлана.

***Төп төшенчәләр:*** Ленар Шәех, Татарстанның Актаныш районы, татар әдәбияты, иҗат, лирика, тематика.

Күңел халәтеңнең һәр мизгеленә аваздаш, рухыңа якын булырлык шигъри юллар табу өчен һич тә авырлык тудырмаслык бай, нәзакатьле татар шигърияте. Аның гасырлар белән исәпләнгән олы тарихында халык күңеленә җуелмаслык булып уелган затлы талант ияләре дә бихисап. Аларның һәркайсы күңелебездә кабатланмас үзенчәлеге, бары үзенә генә хас булган бер ягы белән кереп урнаша. Әдәбиятта үзен ныклап тапкан Ленар Шәех шигъриятен дә «мәхәббәтле шигърият» дип атыйсым килә. Әйе, мәхәббәт хисләре шигъриятнең юлдашы, илһам чыганагы. Ул һәр шагыйрьгә хас, нәкъ Такташ әйткәнчә: «Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә, ләкин һәрбер йөрәк аны яңарта...» [2, б. 126]. Бу шагыйрь мәхәббәт турында матур шигырьләр яза дип кенә шагыйрьнең үзенчәлеген күрсәтеп булмавы бәхәссез. Әмма бу мәкаләдә мәхәббәт сүзен киң мәгънәдә алып, кешеләргә һәм тормышка булган мәхәббәт буларак карадык.

Ленар Шәех иҗатына җәмәгатьчелек, иҗатташлары һич кенә дә битараф булмады. Бу үзе үк аның иҗатының бер үзенчәлеге булып тора. Үз вакытында олпат шагыйребез Роберт абый Миңнуллин аның сәбәбен дә гади һәм аңлаешлы гына итеп әйтеп биргән иде: «Безнең татар шигъриятенә күптән инде Ленар Шәех кебек бер егет кирәк иде. Менә ул килде. Яшенә карата шактый зур багаж белән. Әдәбиятка җитди караучы, өлгергән шагыйрь булып, чын әдәбият кешесе булып. Аның соңгы еллардагы һәм әдәби, һәм иҗтимагый эшчәнлеге мине бик тә куандыра һәм олы өметләр уята» [1, б. 222].

Чыннан да, бу елларда Ленар Шәехнең нәкъ күтелгән вакытта килүе хак. Һәр чорда әдәби мәйданны җанландыручы, аңа яшьләрчә рух өрүче шәхесләр булырга тиеш. Равил Фәйзуллин, Роберт Миңнуллин, Зөлфәт, Газинур Морат, Ркаил Зәйдуллалардан соң үз артыннан ияртеп әдәбиятыбызны, шигъриятебезне алга әйдәүче дәвамчылар кирәк иде. Ленар Шәех шул вакытта дилбегәне үз кулына алды. Казан университетына Минзәлә педагогик көллиятен тәмамлап, инде мөстәкыйль эш итәргә, олыларча фикерләргә өйрәнеп килгән егет татар яшьләренең рухына нәрсә кирәклеген күңеле белән бик тиз тоя. Университет тарихында аерым урын алган, халкыбызның бик күп танылган талант ияләренә, язучыларыбызга беренче иҗат мәктәбе булган «Әллүки» әдәби иҗат берләшмәсен кабат тергезергә алына. Язучы Галимҗан Гыйльманов абыйсы белән бергәләп ул эшне башкарып та чыга. «Әллүки» тиз арада алтмышка якын яшь каләм иясен үз янында туплый. Берләшмәнең айлык басмасы буларак «Тәрәзә» газетасы дөнья күрә башлый. Монда да Ленар Шәех җаваплылыкны үз өстенә ала: баш мөхәррир вазифаларын башкара.

2007 елда Татарстан китап нәшриятында «Әллүки»челәрнең иҗат җимешләрен берләштергән «Әллүки» җыентыгын төзеп бастыра. Башка югары уку йортларында укучы, Башкортстанда яшәүче иҗатка битараф булмаган яшьләр белән элемтәләр урнаштыра. Университетта укыган елларында ук «Татарстан яшьләре» газетасында журналист булып эшли, иҗат итә. Бер-бер артлы яңа китаплары дөнья күрә. Башкалар иҗаты белән дә хәбәрдар булып,

дөнья күргән китаплар турында үз фикерен белдереп тора. Нәкъ шул елларда яшьлек дәрте, белеме, заман сулышын тирәнтен тоя алуы, ихласлыгы, оештыру сәләте, үз арттыннан ияртә алырлык үрнәк бирә алуы белән ул әдәбият мәйданында буыннар бәйләнешен тудыра алган, яңалыкка этәргеч биргән, замандашлары иҗатына юл ачкан шәхес булып өлгерә. Тормыш тузаннары белән керләнмәгән, күңеле үпкә-рәнҗешләр белән каралмаган, яшь, талантлы, күңеле һәрнәрсәдә шагыйрәнә матурлык күрә, һәрнәрсәгә мәхәббәт күзе белән карый, тормышны ихлас ярата торган нечкә күңелле, әмма яшәешебездәге кимчелекләргә күз йоммыйча ир-егетләрчә үз сүзен өздереп әйтә дә белгән Ленар Шәех ныклы адымнар белән шигъриятебезгә килә дә, тормышка булган олы мәхәббәтен ихластан укучысы белән уртаклаша башлый.

Әйе, нәкъ шулай. Аның һәр шигыреннән ихлас ярату, аның кадерен белү һәм шул мәхәббәттә тормыш мәгънәсе, бәхет тоюы сизелеп тора. Бу мәхәббәттә якыннарыңны, сөйгәнеңне – үз ярыңны, сабыеңны, үз халкыңны, туган җирне һәм гомумән кешелекне ярату да гәүдәләнә. Аларның һәркайсының үз кылы, үз моңы бар.

«Зәңгәр күзле эти» поэмасы сугыштан соңгы авыр чорда язмышларына ятимлек ачысы да кушылган сабыйларга этиләре кебек кайгыртучанлык күрсәткән, Яңа Әлем һәм Такталачык ятимнәр йорты директоры булган дәү этисенә багышлана. Ак биләүсәдә тын гына агылган иманлы моң тыңлап яткан сабый язмышы дөньяның гаять катлаулы чорына туры килә. Бик иртә этисез калу да, инкыйлаблар тудырган тормыш катлаулылыгы, сугыш еллары афәтен дә кичеп чыгарга язган икән. Әмма күңеленә сеңгән иманлы моң аның бөтен гомере буе маяк булып юл күрсәтә. Яклаучысыз калган сабыйлар язмышына үзен җаваплы санап, аларны олы тормыш юлына бастыруга, киләчәктә ятимлек ярасыннан кан саркыганнар булмасын өчен бөтен көчен куя ул. Кешелеккә XX гасыр китергән бар афәтләрне үз иңнәре белән күтәргән дәү эти булып сөйли шагыйрь:

Синең балаң үссен
Синең янда гына.
Калмасын ул ялгыз
Дөнья мәйданында.
Кеше киләчәккә
Сугышларсыз барсын.
Үткәннәргә карап,
Сабак, гыйбрәт алсын! [3, б. 247].

Егерме биш яше генә тулган шагыйрь олпат аксакалларча уйланырга чакыра. Поэмада дәү әтисенә булган олы ихтирам да, аның белән чиксез горурлану да, кешелекне хаталардан сакларга омтылыш та ачык чагыла. Шунда ук гаилә учагының җылысын, тормышның бар авырлыгыннан да өстен булган, кешегә яшәү көче биргән мәхәббәт хисен олылау да сизелеп тора. Иманлы моң сеңгән ак йортта туган сабый да еллар узуга мәхәббәтен таба: йөрәген моңлы сөю җыры биләп ала. Бу моң тормышны бизи, авырлыкларны җиңеп чыгарга булыша. Мәхәббәт тулы йөрәге белән ул башкаларга да ярату бүләк итә ала.

Гаилә учагының җылысы, аның бәһаләп бетермәслек кыйммәте, иң кадерле кешеләренә булган чиксез ярату да, аларны югалтудан туган сагыш ачысы да еш килеп керә шигырь юлларына. «Дәү әниемне уйлап» шигырендә дәү әнисе узган озын гомер юлын ап-ак йомгак белән чагыштыра. Тормышта ул калдырган сукмак та ап-ак, хатирәләр дә ак икән:

Йомгагың тәгәри-тәгәри,
Сүтелә-сүтелә барды да...
Шул калын, шул ак йомгактан
Бер чемтем нечкә җеп калды да...
..................
Буранлый-буранлый көн сүнде,
Ак карны җебетеп яшь сеңде.
Урамдагы сукмак – ак йомгак...
Төн иңә күгенә ак чорнап... [4, б. 120].

Ана мәхәббәте, ана кулларының назы кешене бөтен гомере буена озата килә, саклый, иң авыр вакытларда ярдәм итә дигән фикердә тора шагыйрь:

Борылам да карыйм үткәннәргә, –
Нәрсә калган, дисең, нәрсә калган?
Кемдер анда мине талбишектән
Җылы, назлы кулларына алган. [4, б. 130].

Гомумән, Ленар Шәех шигырьләрендә гаилә тормышын олылау, аңа ихтирам белән карау, андагы һәркемне ихлас ярату, хөрмәт итү чагыла. Гаиләдә салынган тормышка мәхәббәт, кешеләрне ярату аның иҗатында матур бизәк булып үрелеп бара. Ул лирик геройның кешеләргә хөрмәт тулы карашы булып гәүдәләнә.

Яшьлек юлдашы булып күңелендә кабынган сөю хисе дә шашкын, йөгәнсез хисләр өере, баш югалту түгел, ә бик ихлас, гади. Ул мизгеллек кенә түгел – гомерлек, юлында очраган бөтен каршылыкларны үтеп чыгып, аны саф килеш саклауга ышаныч белән сугарылган. Шагыйрьнең гашыйк утында янган лирик герое күңелдә соклану уята, аның белән теләктәшлек туа. Бу хисләрендәге садәлек, шашкын хисләргә дә матур бер тыенкылык хас булу мәхәббәтне илаһи югарылыкка күтәрә. Мәхәббәтнең сәбәпчесе булган затның гади, оялчан, үз дәрәҗәсен яхшы белгән горур сылу икәнлеге турында сөйләнсә дә, ул дөньяда тиңе булмаган гүзәллек, сафлык алиһәсе буларак күз алдына килә башлый. Гашыйк булган лирик герой сөйгәнен мәхәббәт нурына коендыра, аның гадилегендә илаһилык күрә. Аның өчен ул шул кадәр кадерле, аңа үзе дә кагылырга кыймый. Бу мәхәббәтнең чынлыгына ышанып та җитә алмый:

Сөйгәнем,
Яратам дигәнем!..
Күзеңнән үбәргә
Кыймадым, тимәдем...
...

Мәхәббәт
Үзе дә төн кебек...
Әкият тә кебек...
Барысы да чын кебек... [4, б. 96].

Мәхәббәт хисләренә исергән лирик герой ярата, сагына, сабырлыгын җуймый сәгатьләрне, көннәрне санап сөйгәненнән җавап көтә. Ул аңа йолдызларны, язны, умырзаяларны, ак карларны һәм йөрәген бүләк итә. Күңелен биләп алган бу хисләрдән ул бәхетле, бу бәхетне ул һич тә югалтырга теләми:

Син генә, син генә
уемда.
Син миннән китәргә
Җыенма. [4, б. 22].

Шул ук вакытта ул язмышы каядыр хәл ителгәнне көтеп утыручы да түгел. Ир-егетләрчә кистереп хәл итеп тә куя:

Сөюдән тилергән
җүләр мин.
Беркая, беркая
җибәрмим! [4, б. 22].

Иң газизе – баласына булган мәхәббәттә дә ул буыннар бөтенлеген күрә. Нәни улы аңа үзенең сабый чагын хәтерләтә, сабый күзләрендә дәү әнисенең елмаюлы, әнисенең уйчан, дәү әтисенең һәм әтисенең сынаулы карашы чагылыш таба:

Улым булып әби, бабасы да,
Әнисе дә миңа күз сала.
Буыннарны, нәселләрне бәйли,
Якынайта икән ул бала.

Күземнең гөле – бала, диләр,
Күзнең нуры, бәгырь җимеше.
Ике җанны киләчәккә илткән
Йөз аклыгы, йөрәк тибеше! [4, б. 122].

«Бәгырь җимеше» булган баланы нәсел дәвамчысы һәм «йөз аклыгы» дип саный шагыйрь. Бу ата-ана өчен дә, бала өчен дә зур бурыч. Ата-ана бөтен барлыгы белән баласын йөзенә кызыллык китермәслек итеп тәрбияләргә тырышканда, бала ата-анасының ышанычын аклап яшәргә тиешлеген онытмаганда гына җәмгыятебез әдәп-хәя чикләрен үтмичә, яшәешен дәвам итә ала бит.

Гаилә эчендәге мәхәббәт, буыннар бәйләнешенең өзлексезлеге, үзара аңлашуга корылган матур мөнәсәбәтләр – һәммәсе образлы шигъри сөйләм эченә кереп урнаша алган. Алар аерым бер цикл да түгел. Әмма шагыйрь иҗаты белән танышканда шул бәйләнешләрне укучы бөтен барлыгы белән тоя, лирик герой күңелендәге шул олы мәхәббәт аны җылыта, сокландыра. Җанында олы мәхәббәт яшәгән лирик герой тормышка да гашыйк, үз кавеме язмышына да битараф түгел. Халык күңелендәге төзәлмәс яралар, алар өстенә яңа килеп кушылганнары шагыйрь күңелен дә әрнетә. «Сөйгәннәрен сугыш кырында югалткан, сабыйларын тимер табутта җиргә иңдереп, киләчәкне утка яккан, күпне күргән татар аналары, кан-яшь түккән татар әбиләре» аны борчуга сала.

Тарихыбыз, бүгенге яшәешебез, туган тел язмышы турында бик еш уйлана шагыйрь. Татар моңы, мөһаҗирләр язмышы, татар халкының талантлы шәхесләре, остазлары турында, бүгенге тормышта барган вакыйгалар аша милләтебезнең үткәне, киләчәге хакында фикер йөртә. Үткәннәрдән сабак алырга, бүген киләчәгебезгә битараф булмаска чакыра. Халкыбызга төрле афәтләр аша үтәргә туры килгән, әмма ул табигате белән җиңелмәс горур милләт дип раслый шагыйрь:

Татар – җитди, курку белмәс,
Башын имәс һәм баш бирмәс! [3, б. 222].

Заман тудырган шартлар милләт язмышына, телебезгә янаса да, татарның киләчәгенә өмет баглый:

Җидегән чишмә ага тамчылап,
Ал шәфәкълән яңа таң сорап [4, б. 274],

дип, татар җанындагы яшәү көченең җидегән чишмә кебек җиде тармаклы, мәңге тынмас икәнлеген, аның һәр тамчысы яңа таң, яшәү хакына үз көчен биргәнлеген күрсәтә.

Әйе, «мәхәббәтле шигърият» турында сүз башлаган идек. Алда сөйләгәннәрем белән шуны дәлиллисем килә: Ленар Шәех шигырьләрендә кешеләр күңеленә нур өсти, икеләнгәннәргә туры юл күрсәтә, тынычлыгын җуйганнарга сабырлык бирә, мәхәббәттән янганнарга аның бәхет икәнлеген таныта, өмете өзелгәннәргә күңел җылысы бирә. Ана сөте белән җанга иңгән мәхәббәт кешенең үзе белән үсә, байый. Башкаларны үзенең назы белән иркәли, бәхетле итә. Шагыйрьнең максаты да шул бит: «җылытасы килә дөньяны». Болай да бик кыска гына булган кеше гомеренең бу тормышта җан җылысы таба алмый, газап белән бушка янып юкка чыгуын теләми ул. Аларның җанын үз сөюе белән җылытырга тели:

Мин үзем дә җылы бирә алам,
Бирми икән дөнья, бирмәсен!
Мин үзем дә сөю бирә алам,
Күпме кирәк, мәгез алыгыз!
Кесәгезгә акча итеп түгел,
Җанга ялкын итеп салыгыз!.. [4, б. 152].

Шагыйрьнең ихлас теләге тормышка ашкан дия алам. Аның шигырьләре җанга җылы бирә, саф сөюнең барлыгына ышандыра, яшәү мәгънәсен тирәнрәк тоярга өйрәтә. Һәр юлыннан тормышны ярату һәм шуның бәхет икәнлеген тою сирпеп торган мәхәббәтле шигърият тудыра алган шагыйрь ул Ленар Шәех. Озын гомерле иҗат булсын!

## ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ЧЫГАНАКЛАР

1. *Миңнуллин Р.* Әсәрләр: 7 томда. Т. 5. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 431 б.

2. *Табташ Һ.* Мәхәббәт тәүбәсе. Шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 205 б.

3. *Шәех Л.* Җылытасы килә дөньяны. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 255 б.

4. *Шәех Л.* Гасырларда фасыллар буталган. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 335 б.

## ТВОРЧЕСТВО ПОЭТА ЛЕНАРА ШАЕХА

***Абдуллина Дилария Маратовна,***
*кандидат филологических наук,*
*Институт языка, литературы и искусства*
*им. Г. Ибрагимова АН РТ,*
*Казань, Россия,*
*gibadullina_13@mail.ru*

В статье освещается творчество поэта Ленара Шаеха, уроженца Актанышского района Республики Татарстан, внесшего весомый вклад в развитие современной татарской поэзии. В частности, рассматриваются интимная, гражданская лирика поэта, анализируются характерные особенности его творчества.

***Ключевые слова:*** Ленар Шаех, Актанышский район РТ, татарская литература, творчество, лирика, тематика.

## WORKS OF POET LENAR SHAEKH

***Abdullina D.M.,***
*Candidate of Philological sciences,*
*Ibragimov Institute of Language, Literature and Art*
*of the Tatarstan Academy of sciences,*
*Kazan, Russia,*
*gibadullina_13@mail.ru*

The article highlights the works of Lenar Shaekh, a native of the Aktanysh district of the Republic of Tatarstan, who made a significant contribution to the development of modern Tatar poetry. In particular, the author considers his lyrics and patriotic poetry and typical features of the poet's works.

***Keywords:*** Lenar Shaeh, Aktanysh district of the Republic of Tatarstan, Tatar literature, poet, lyrics, themes.

УДК 821.512.145

# ФОАТ САДРИЕВ ПРОЗАСЫНДА ТУГАН ЯК ҺӘМ ЯШӘҮ ФӘЛСӘФӘСЕ

***Ганиева Айгөл Фирдинат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты,*
*Казан, Россия,*
*aygulgani@mail.ru*

Татарстанның Кама аръягы – татар мәдәниятенә күпсанлы талантлы шәхесләр биргән данлы төбәк. Мөслимдә туып-үсеп, хәзерге вакытта да анда яшәүче танылган язучы Фоат Садриев татар сүз сәнгатен баетуга зур өлеш кертте. Традицион реализм мөмкинлекләреннән иркен файдаланып, ул үз әсәрләрендә туган як табигатен идеаллаштыру дәрәҗәсендә тасвирлый, кешелекнең асылын саклый торган урын буларак, аның иң яхшы сыйфатларын югары күтәрә. Фоат Садриев прозасы лирик-фәлсәфи тирәнлеге, эмоциональлеге, тел-сурәт чараларының халыкчанлыгы белән аерылып тора.

***Төп төшенчәләр:*** Татарстанның Кама аръягы, Фоат Садриев, татар прозасы, роман, хикәя, образ, герой, реализм.

Ф. Садриев геройлары – заман кешеләре. Язучы кеше холкын, психологик халәтләрне иҗтимагый тормыш белән бәйләп сурәтли, җәмгыятьтәге шәхес азатлыгына һәм бәхетенә каршы төшкән тәртипләрне кискен тәнкыйть утына ала. Әсәрләрендә персонажларны чолгаган мохит төрле яклап яктыртыла. Бу геройның шәхси бәхете (мәхәббәте, гаилә мөнәсәбәтләре), иҗтимагый тормышы (кеше һәм җәмгыять), табигый асылы (кеше һәм табигать, туган җир, татар авылы) яссылыкларында карала.

1980 нче еллар уртасыннан башлап, илдәге сәяси үзгәрешләр белән бәйле, әдәбиятта иҗтимагый аңы үскән, гражданлык тойгылары югары булган геройлар сурәтләнә башлый. Ф. Садриевның җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп иткән беренче күләмле әсәре – «Шаһзаманов эше» (1987) повестенда да игенченең җиргә

мөнәсәбәте аша социалистик җәмгыятьнең соңгы этабында барган үзгәрешләр күрсәтелә.

Язгы аяз көннәрнең берендә җир сөрүдән кайтып кергән тракторчы Илһам агроном Яхъяның яңагына сугып җибәрә. Язучы повесть буена әлеге адымның сәбәбен күрсәтмичә, укучыны интригада тота. Вакыйгалар үстерелеше примитиврак чыкса да, игенче психологиясен ачу әсәрнең чишелешен үткенәйтә. Шаһзаманов белән Хаков арасындагы конфликт, күпләр шикләнгәнчә, шәхси мөнәсәбәтләргә бәйле түгел икән. Агроном малларга чабып ашатырга мөмкин булган бер басу игенне өстән күрсәтмә нигезендә сукалаттырып юкка чыгарта. Хаковка боерыкны колхоз рәисе биргән. Ә ул, үз чиратында, райкомның икенче секретареның боерыгын үтәгән. Шулай итеп, хулиганлык адымы өчен Илһамны партия сафларыннан чыгару өчен җыелган бюро утырышы партия җитәкчеләренең гаебен фаш итү белән тәмамлана.

Ф. Садриев иҗатында заман проблемаларын киң фәлсәфи планда яктыртуга омтылыш та көчәя бара. Фәлсәфилек халыкчанлыгы, һәркемне борчый торган мәсьәләләргә юнәлдерелүе, ил гаме белән үрелеп бирелүе ягыннан тормышчан һәм көнитешкә якын. Шуңа язучының әсәрләренә әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләр генә түгел, киң катлам укучылар да битараф калмый: бәямөнәсәбәтләрен матбугат битләрендә чагылдыра киләләр. «Таң җиле» (1992) арада иң күп игътибарны җәлеп иткән роман булып чыга. 1993 ел дәвамында «Казан утлары» журналы әлеге әсәр белән бәйле «Безнең тормыш. Безнең әдәбият» дигән темага зур сөйләшү дә алып бара. Роман татар әдәби барышында югары бәя ала: «Чор әдәбиятының энҗе бөртеге булган әлеге роман сайланган теманың һәм күтәрелгән мәсьәләләрнең актуальлеге белән дә, әдәби эшләнеше һәм тәэсир көче буенча да, авторның образлар тудыру осталыгы ягыннан да аерым урын тота» [3, б. 11].

Әсәр үзәгендә гап-гади татар авылында гомер итүче Нуриасма исемле карчык тора. Язучы әлеге образга бәйле тормышны күп яктан колачларга омтыла. Анда кеше һәм җәмгыять, кеше һәм аның вөҗданы, авыл, табигать, милләт мәсьәләләре заман биеклегеннән бәяләнә.

Романның төенләнеше үлем вакыйгасына бәйле башланып китә. Авылның бер дигән ир-егете Рәмзи урманга утынга барган җирдә фаҗигале төстә һәлак була һәм язучы әлеге күренешкә бәйле әсәрне ялган һәм дөреслек, вөҗдан һәм намуссызлык каршылыкларына, яшәү мәгънәсе кебек мәңгелек фәлсәфи сорау-уйлануларга нигезли. Бөтен авыл Рәмзинең үлеменә турыдан-туры гаепле булучыларны ялган күрсәтмә биреп яклаганда, бары Нуриасма хакыйкатьне саклаучы бердәнбер кеше булып кала. Хикмәт исерек килеш руль артына утырган Гарифҗан, аңа күрсәтмә биргән колхоз рәисе Хөснуллинда гына түгел. Нуриасма авылдашлары арасыннан башланган шушы ялганның ил күләмендәге ялганга килеп тоташуын аңлый. Шулай итеп, Нуриасма дөреслеге власть һәм халык арасындагы ялганны ачып бирүче ачкычка әверелә.

Романда тормыш-яшәешнең төрле катламнары яктыртыла. Дөреслекне яшәү принцибы итеп алган Нуриасманы язучы ана-бала, ир-хатын, көндәше һәм авылдашлары белән мөнәсәбәттә ача. Язмышның нинди генә сынаулары килсә дә, ул һәркем өчен аклык-сафлык үрнәге булып кала. Нуриасма белән Сәгыйдулла, гаилә корган вакытта ук, намус пакьлеген изге канун итеп саклауны максат итеп куялар. Үзе аңлаган дөреслеккә омтылу һәм бернинди ташламаларсыз яшәве Нуриасманың үзенә генә түгел, аның гаиләсенә – балаларына да авырга килә. Язучы төрле тормыш вакыйгаларында героиняның гел туры юлдан баруын, кайчакта үз балаларына каты бәгырьле дә булуын сурәтли. Әлеге вакыйгалар фәлсәфи-психологик уйланулар белән үрелеп бара һәм укучыга яшәеш турында төрле яклап фикер йөртү мөмкинлеге бирә. Хакыйкатьнең үзе дә бертөрле генә булмыйча, кемнең хаклы, кемнең хаксыз икәнен аера алмаслык тормыш сынаулары чыгып тора. Авторның уңышы да шунда: Нуриасма сынауларны схематик образ сыман ансат кына узмый, ә икеләнү һәм күңел газаплары аша үтеп җиңүгә ирешә.

Ф. Садриев яратып кулланган алымнарның берсе – чагыштыру. Күп очракта бу төп геройның антиподы аша башкарыла. Әсәр героена дөньяга карашы, холкы, яшәү рәвеше, зәвыгы белән кап-

ма-каршы сурәтләнгән сәнгати образ фонында автор күрсәтергә теләгән сыйфатлар тагы да ачыграк чагыла. «Таң җиле»ндә Нуриасманың антиподы итеп Мәскәү кодагые бирелә. Мөселман карчыклары янында алардан да уздырып намаз укыган Гыйльменур рус дуслары янында чукына, дуңгыз ите ашап, аракы эчеп утыра. Үзенең күңел дөньясы саф, кешеләргә карата да ихлас Нуриасма кодагыеның бу гамәлләренә өнсез кала. Иман мәсьәләсендәге икейөзлек әсәрдә гафу ителмәслек түбәнлек буларак бәяләнә: Нуриасма Гыйльменурны үләр алдыннан да кичерми.

Ф. Садриев бала тәрбияләүдә милли-табигый мохитнең әһәмиятен югары бәяли. Нуриасманың олы улы Фәрит белән килене Нәсимә Себердә яшәгәндә туганнан бирле сәламәтлеккә туймаган Маратны ничек кенә дәвалап карасалар да, файдасы булмый. Аптырагач, табип киңәше белән баланы әниләренә кайтарып торырга булалар. Маратның әбисе белән таңнан торып кичкә кадәр хуҗалык эшләрендә кайнашуын, мал-туар, тавык-чебеш арасында йөрүен, яшьтәшләре белән агач башларына менеп уйнавын, су керергә йөрүләрен сурәтләп, язучы чын табигый яшәү бары авылда гына дигән фикеренә тугры кала: малай савыгу гына түгел, теле ачылып, өлкәннәргә тапкыр-тапкыр җаваплар да бирә башлый. Марат белән чагыштыру өчен әсәрдә шул ук Гыйльменурның оныгы Руслан китерелә. Чама белән Марат яшьләрендәге әлеге малайны эти-әниләре «дөрес» тәрбияләү максатыннан көндәлек катгый режимга көйләгәннәр, рәхәтләнеп уйнау, күңел ачу хокукларыннан, үзләренең иркә-назларыннан мәхрүм иткәннәр. Мондый тәрбиянең нәтиҗәсе итеп язучы Русланның абыйсын китерә. Әбисе сүзләренә караганда, ул үскәндә акыллы гына бала булган, үсмер яшькә җиткәч, начар юлга кереп, өйгә кайтмый йөри башлаган. Шулай итеп, романда шәхес тәрбияләү мәсьәләсендә авыл һәм шәһәр мохитын бер-берсенә каршы кую һәм авылны өстенлекле итеп күрсәтү бар.

Гомумән, Ф. Садриев иҗатында авыл прозасы традицияләре дәвам иттерелә. «Таң җиле»ндә, сайланган тормыш ситуациясенә бәйләп, мәет күмү йолалары җентекләп сөйләп бирелә, кыз каршылау, туйга әзерлек күренешләре бәян ителә. Язучы табигатьне,

кешеләрнең үзара мөгамәләләрен яратып сурәтли. Читтән кайткан һәр кешесен үз баласыдай якын күреп, ачык йөз белән каршылау (Гыйзденисаттинең Фәритләр белән исәнләшүе), кайтучыларның исә олысын-кечесен күчтәнәчләр белән сөендерүе (Үзбәкстаннан Сәлмән абзый алып кайткан калач тәме турындагы хатирә), күптән киткәннәрне хәтта балаларның да танып, хәтерләп торуы (Фәрит һәм кечкенә кызчык әңгәмәсе) авыл җирлегендә генә очрый торган матур гадәтләр буларак күрсәтелә. Бер-берсенә кереп хәл белешеп, шатлыгын да, михнәтен дә бергә күтәреп яшәгән авыл хатыннары Маһинур, Разия, Гыйздениса, Мосаллиялар турында язучы соклану катыш әрнү белән яза. Бөтен сәламәтлекләрен, гомерләрен колхоз эшенә багышлап та, тормыш авырлыгына зарланмыйча, булганына канәгать булып, кешеләргә яхшылык эшләүдән тәм табып яшәгән буын киткәч, алмашка кем калыр? Нуриасма уйлары аша романга татар авылы мохитенең үз йөзен югалта баруына борчылу-сызлану килеп керә.

Язучы тормыш, яшәү һәм үлем турындагы фәлсәфәне бер ноктага җыя: ике туйга әзерлек берьюлы бара. Ике хатын-кыз – ике юл башында: Нуриасма үлгәннән соңгы истәлекләре итеп кемгә камзул, кемгә яулык, кемгә намазлык бирәсен әйтеп калдыра, Зөбәрҗәт килен бүләге өләшә. Гаять тетрәндергеч мизгелләр булса да, бу гайре табигый хәл кебек кабул ителми. Моның сәбәбе – Нуриасманың үлемне тыныч күңел белән каршы алуында. Хәл белергә кергән Гыйзденисатти тынычландыргыч салмак тавышы белән Аллаһ биргән гомер, һәркемнең шуны үтүе, кыскамы ул, озынмы – тәмен, кадерен белеп яшәү кирәге турында сөйли. «Үлем турында сөйләсә дә, Гыйзденисаны тыңлавы рәхәт иде. Аның сөйләвендә чишмәнең мәңгелек челтерәве төсле тынычландыргыч моң, бернинди бизәкләргә төрелмәгән гадилек, сафлык, ачыклык бар иде... Тормыш белән үлем, төш белән өн аның өчен үзара тыгыз бәйләнештә торучы, күп очракта хәтта аерылгысыз әйберләр, яшәешнең нindidер бер серле мизгелендә без белмәгән гайре көчләр тәэсирендә бер-берсенә әвереләләр иде» [5, б. 145]. Шулай итеп, әсәрдә үлем – юкка чыгу, бетү булып түгел, ә тормышның башкаларда дәвам итүе кебек бирелә.

Роман символик детальләргә гаять бай. Язучы күбрәк кояш, таң, җил, нур, аклык символларына игътибар бирә. Нурлы, якты, балкучы, югары, бөек мәгънәләрен белдергән Нуриасма исеме дә очраклы сайланмаган. Ф. Садриевның мәртәбәле, хөрмәтле, алдагы буыннарга да үрнәк булып торырлык гомер юлы үтүче героинясын, Ф. Бәширов әйткәнчә, символ дәрәҗәсенә җиткерә. «Романның икенче өлешендә Нуриасма конкрет персонаж булудан битәр, гореф-гадәтләрне буыннардан-буыннарга тапшырыла килә торган яшәү кануннарын, халыкның акылын, тәҗрибәсен үзендә туплаган символ-образ булып күзаллана. Ул образда татар халкының гамәл-хыяллары да, язучының милләт язмышы турындагы уйланулары да гәүдәләнеш алган» [1, б. 21].

Образ-символлар турында сөйләгәндә, укучы игътибарын берничә кат җәлеп иттергән кызыклы деталь турында да әйтеп китәргә кирәк. Ул – Марат киеп йөргән тузып беткән иске чалбар. Нәсимә аны берничә тапкыр ташларга җыенса да, я Нуриасма, я Фәрит тотып кала. Әлеге чалбарның хикмәте соңыннан гына ачыклана: аны кечкенә чакта Фәрит үзе киеп йөргән икән. Ә аңа әнисе әтисенең сугыштан киеп кайткан гимнастеркасыннан теккән булган. Әсәрдә Сәгыйдулла – Фәрит – Марат чылбыры ир-ат символы буларак килгән чалбар аша күрсәтелә. Нуриасма шушы буыннар бәйләнешен тәэмин итүче, саклаучы хатын-кыз – ана архетибы буларак та алга баса.

Шулай итеп, «Таң җиле» романы күпкатламлы булуы, ягъни кешенең рухи дөньясын төрле яссылыкта (заман, хакыйкать, табигать, мәхәббәт, үлем һ.б.) карап, фәлсәфи гомумиләштерүләр ясый. Лирик аһәң, символик сурәтләр әсәрнең эмоциональ көчен куәтли. Сәнгати камиллек һәм мәгънәви бөтенлек романны татар әдәбиятының иң югары әсәрләре рәтенә куя.

Кеше һәм туган җир бәйләнеше фикер-идея катламы рәвешендә Ф. Садриев иҗатында әсәрдән-әсәргә кабатланып килә, җиргә, табигатькә мөнәсәбәт кешенең кешелеген билгеләүче критерий дәрәҗәсенә җиткерелә. «Авыш басу икмәге», «Шаһзаманов эше» кебек әсәрләрдә бу иҗтимагый нигездә каралса, «Көлми торган кеше» повестенда гаилә мөнәсәбәтләре яссылыгында сурәтләнә.

Улы хакына хатыны хыянәтенә түзеп яшәргә мәҗбүр булган Газизҗан, шәһәрдә мәхәббәтен табып, анда китү мөмкинлеге тууга карамастан, авылда кала. Сәбәп малаенда гына түгел, билгеле (инде ул да балигъ яшендә), гомере буе тракторчы булып эшләгән ирне җир белән бәйләүче әйтеп-аңлатып булмый торган җепләр бар икән! Автор моны турыдын-туры язмый, Газизҗанның табигатькә карата үтә нечкә тойгылары, хис-кичерешләре аша ирешә. Геройның китәргә җыену күренешен сурәтләгән урыннар аеруча тәэсирле килеп чыккан. Табигать һәм аның һәр сулышын күңеле белән тоеп торучы игенченең күңел матурлыгы бербөтен гармоник дөнья хасил итә. Айлар буе хезмәт хакы алмыйча эшләгән колхозыннан, хыянәтче хатыныннан, өметләрен акламаган сансыз улыннан никадәр генә туйса да, «искиткеч чибәр, чиста, саф» Фирдәүсәсе өзгәләнеп көтеп торса да, китә алмый ул. Табигый дөньядан аерыла алмаган игенче психологиясе эмоциональ детальләрдә чагылыш таба: «Ул Фирдәүсәнең күзләренә ярдәм сорагандай төбәлде, теле әйләнмәде, яргаланган иреннәре кызганыч дерелдәп бер ачылды, бер ябылды, тамак төбе белән еш-еш сулап алды. Ахырда ул бөтен барлыгы белән этеп бер сүз чыгара алды: «Бул... мый...». Бу сүзнең газаплы ялкыны офыктан-офыкка кадәр җирләргә дөртләп кабарлык иде...» [4, б. 71].

Соңгы еллар татар әдәбиятында авыл темасы шактый яктыртылса да, ул күбрәк милли-әхлакый, тарихи яки экологик якларны күздә тота. Авыл кешесенең күңел дөньясын хезмәтенә бәйле ачу совет чорында калган кебек иде. Ф. Садриев хикәя-повестьлары нәкъ менә гади хезмәт кешесенә хөрмәт тәрбияләү традициясен дәвам итүе белән дә әһәмиятле. Менә төп геройның куллары: «Газизҗанның кулы коточкыч авыр, имән кайрысыдай кытыршы иде, аңардан туфрак, май һәм җир исе килә иде. Әйтерсең лә, бу кул түгел, ә бәлки мәңге шушы җирдә үсүче, ләкин күзгә күренмәс пәһлеван агачының бер тере тамыры иде» [4, б. 71]. Әлеге кыска гына чагыштыру аша язучы игенченең асылын, туган җирнең газизлеген, кадерен ачып сала.

Кеше күңелендә матурлыкны күрә һәм тоя белү сәләте тудыру, үстерү – Ф. Садриев иҗатының максаты. Гүзәллек орлыклары

бала күңеленә кече яшьтән үк салынырга тиеш дип саный язучы. Ә матурлыкның чыганагын ул табигатьтә, аерым алганда, аның басу-кырларында, болыннарында күрә. Балалар өчен язылган «Арышлар сөйләшкәндә», «Тургай ни дип сайрый» әсәрләрендә генә түгел, ә «Шаһзаманов эше», «Таң җиле», «Кышкы яшен» кебек повестьларында да балаларны алып, гаилә белән кырга чыгу, арыш серкәсен очыру тавышларын тыңлау күренешләре сурәтләнә. Язучының эстетик дөнья пространствосында кыр, басу сакраль мәгънәгә ия матурлык идеалы булып тора. Хикмәт – аның кырны Кеше – Табигать – Хезмәт төшенчәләрен берләштерүче символ буларак кабул итүендә. Кыр кошы – сабан тургаеның да әсәрләрендә еш очравы шуның белән аңлатыла. Язга, матурлыкка, муллыкка, хезмәткә дан җырлаучы буларак кабул ителгән әлеге кошны язучы үзенең күңел халәтенә туры килә дип саный һәм балалар өчен язылган күләмле «Тургай» (2016) повестен дә шул исем белән атый.

Ф. Садриев әсәрләренең теле, сүз белән сурәт ясау осталыгы турында аерым билгеләп үтү мөһим. «Тел-стильнең үтә дә нәфислеге, нәзакәтлеге, нечкәлеге; хис-кичереш дөньясының мәгърур музыкаль симфонияләрдәге шикелле бөек бер гармония һәм драматизм белән агышы; вакыты-вакыты белән югары романтиканың, ә кайчак иң-иң трагик аһәңнәр өскә калкып кеше рухиятенең гаять киң диапазонда һәм тирәнлектә-биеклектә чагылуы – болар барысы да бергә проза әсәрләрен шигърият белән якынайта, алар арасындагы чикне җуядыр. <...> Ф. Садриев прозасының кайбер урыннары (бигрәк тә геройларның эчке кичерешләрен биргәндә, яисә табигать күренешләрен тасвирлаганда, яки автор үзе хисләнеп лирик кичерешләргә кереп китсә) нәкъ менә шундый – зур күләмле әсәрдән аерып шигъри әсәр кебек кулланырлык дәрәҗәдә сәнгатьледер», [2, б. 92] дип яза Мансур Вәлиев.

Йомгаклап әйткәндә, Ф. Садриев – халык белән тыгыз элемтәдә яшәп иҗат итүче әдип. Ул авыл халкының рухи-мәдәни яшәешенә аерым игътибар бирә, татар тормышын бизәкләп, матур сыйфатларын калкуландырып сурәтли, милли яшәешнең нигезен авылда

– табигый яшәү рәвешендә таба. Аның әсәрләрендә һәркемне борчыган мәсьәләләр күтәрелсә дә, үзәккә – Кеше, аның бәхете куела. Бәхет исә, язучы фикеренчә, рухи һәм матди бөтенлек, гармония, шәхес ирегендә. Әлеге концептуаль караш язучының фәлсәфи-психологик стиле, катлаулы характерлар итеп тасвирланган геройлары, беркемне кабатламаган образлы теле, зәвыклы сурәт алымнары аша укучыга җиткерелә.

ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ЧЫГАНАКЛАР

1. *Бәшир Ф.* Исә җилләр... // Бәширов Ф. Сөйлә, каләм! Әдәби уйланулар, тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 143 б.

2. *Вәли-Барҗылы М.* Намуслы кешеләр // Мәйдан. – 2011. – № 3. – Б. 83-95.

3. *Заһидуллина Д.Ф.* Таң җилләре кебек // Заһидуллина Д.Ф. Яңа дулкында (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). – Казан: Мәгариф, 2006. – 255 б.

4. *Садриев Ф.* Көлми торган кеше // Садриев Ф. Дәверләр аһәңе: повестьлар һәм хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 439 б.

5. *Садриев Ф.* Таң җиле: Роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 263 б.

## ФИЛОСОФИЯ ЖИЗНИ И ОТЧЕГО КРАЯ В ПРОЗЕ ФОАТА САДРИЕВА

***Ганиева Айгуль Фирдинатовна,***
*кандидат филологических наук,*
*Институт языка, литературы и искусства*
*им. Г. Ибрагимова АН РТ,*
*Казань, Россия,*
*aygulgani@mail.ru*

Закамье Татарстана – славный регион, подаривший татарской культуре многочисленных талантливых людей. Уроженец Муслюмова и ныне там проживающий известный писатель Фоат Садриев внес весомый вклад в обогащение татарского словесного искусства. Свободно ис-

пользуя возможности традиционного реализма, он в своих произведениях описывает природу родного края на уровне идеализации, как место, охраняющее сущность человечества, возвышая его самые прекрасные качества. Его проза отличается лирико-философской глубиной, эмоциональностью, народностью языка и изобразительных средств.

***Ключевые слова:*** Закамье Татарстана, Фоат Садриев, татарская проза, роман, повесть, образ, герой, реализм.

## PHILOSOPHY OF LIFE AND NATIVE LAND IN PROSE OF FOAT SADRIEV

***Ganieva A.F.,***
*Candidate of Philological sciences,*
*Ibragimov Institute of Language, Literature and Art*
*of the Tatarstan Academy of sciences,*
*Kazan, Russia,*
*aygulgani@mail.ru*

The famous Tatar writer Foat Sadriev was born and live in Muslyumovo region. He made a significant contribution to the enrichment of Tatar literature. Freely using the possibilities of traditional realism, in his works he describes the nature of his native land at the level of idealization, as a place that protects the essence of humanity, exalting its most beautiful qualities. His prose is characterized by lyrical and philosophical depth, emotionality, vernacular language and descriptive means.

***Keywords:*** Kama area of Tatarstan, Foat Sadriev, Tatar prose, Novel, Novella, image, protagonist, Literary realism.

УДК 821.512.145

# А. ӘХМӘТГАЛИЕВАНЫҢ «САГЫНГАН ЧАКЛАРЫМДА» ДРАМАСЫНДА ЗАМАН ҺӘМ ГЕРОЙ КОНЦЕПЦИЯСЕ

***Миңнуллина Фатыйма Хәлиулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты,*
*Казан, Россия,*
*minnullina77@mail.ru*

Мәкаләдә А. Әхмәтгалиеваның «Сагынган чакларымда» драмасы анализлана. Биредә совет идеологиясенең кешенең дөньяга карашын, әхлагын үзгәртүе, илдәге сәяси вакыйгаларның, шәхес культының гаиләләрне, кеше язмышларын җимерүе, гомерлек рухи газапта калдыруы һ.б. алгы планга чыгуы билгеләнә. Пьесада кешене һәм әсәрдә тәкъдим ителгән тормыш моделен бәяләүдә әхлаклылык һәм әхлаксызлык, хакыйкать һәм ялган, намус һәм намуссызлык, шәхси һәм гомуми мәнфәгатьләр кебек принципларның өстенлек итүе билгеләнә. Драма, нигездә, психологик характердагы конфликтка корылган, персонажларның күңел дөньясы ачыла барган саен, ул конфликтның система тарафыннан рәхимсез имгәтелгән шәхесләр фаҗигасе нәтиҗәсе икәнлеге ачыклана.

***Төп төшенчәләр:*** драма, герой, пьеса, конфликт, жанр.

XX гасыр ахыры – XXI йөз башы татар драматургиясенең ирешкән уңышларының бере – шәхеснең күңел халәтенә игътибар арту. Р. Хәмид, Т. Миңнуллин, Д. Салихов, З. Хәким, Р. Зәйдулла, И. Зәйниев, А. Әхмәтгалиева һ.б. кешенең эчке дөньясына тулырак тукталалар, аеруча аның җәмгыятьтә тоткан урынын күрсәтүне алгы планга чыгаралар. Хәзерге татар әдәбиятында чорның дөньяви-иҗтимагый, рухи-әхлакый әһәмиятле мәсьәләләрен укучы игътибарына җиткерүдә А. Әхмәтгалиева иҗаты да игътибарга лаек.

«Сагынган чакларымда» драмасы белән автор олы драматик характерлар тудырырга, татар халкы тарихын колачлап бәяләргә

сәләтле булуын күрсәтте. Драманың сюжеты иҗтимагый проблемалар – шәхес фаҗигасе алга куелу белән үзенчәлекле. А. Әхмәтгалиева әсәрендә язмыш китергән сынаулар никадәр авыр, фаҗигале, геройларының тормышы, дөньяга карашы, эшгамәлләре ни дәрәҗәдә генә катлаулы булмасын, алар кешелек сыйфатларын саклап калалар, киләчәккә өмет белән карыйлар. Геройлар бирелешендә кеше күңеленең катлаулы һәм бай булуына да игътибар ителә. Әсәрнең драма жанрында язылуы да авторга тормышчан характерлар иҗат итәргә, кешенең эчке дөньясын, психологик халәтен, тормышка, яшәешкә карата булган фәлсәфи уйлануларын ачарга ярдәм итә. А. Әхмәдуллин сүзләре белән әйткәндә: «Драманың мөһим үзенчәлекләреннән берсе шунда: ул дәвернең фәлсәфи һәм әхлакый проблемаларын аңлау-төшенү һәм гәүдәләндерү юнәлешендә үсә. Аның бу үсешендә ачык төс алган тенденциядә яңа җәмгыять төзүнең, яңа кеше тәрбияләүнең сәнгатьчә хәл итәргә максатчан омтылыш чагыла» [1, б. 10].

Пьесада сугыш елларында яшәү һәм үлем, олы җанлылык һәм намуссызлык, бөеклек һәм түбәнлек төшенчәләре дөнья, ил язмышы белән рәттән куела. Драматург ретроспекция ярдәмендә, ягъни Шаһидә карчыкның хәтерендәге хәл-ситуацияләрне искә төшерү аша шәфкатьсезлек, имансызлык кебек сыйфатларга кагыла, «яңа» җәмгыятьнең, идеологиянең кешенең дөньяга карашын да, әхлагын да, үз-үзен тотышын да үзгәртүен күрсәтә. Шул рәвешле, төп геройның кичерешләре һәм фикерләре, хәтерендә калыккан күренешләр артыннан бару – ягъни «аң агышы» алымы аның психологик сурәтен шактый тулы тасвирларга мөмкинлек бирә. Пьесада кешене һәм әсәрдә тәкъдим ителгән тормыш моделен бәяләүдә әхлаклылык һәм әхлаксызлык, хакыйкать һәм ялган, намус һәм намуссызлык, шәхси һәм гомуми мәнфәгатьләр дигән принциплар өстенлек итә. XXI гасыр башында һәм XX йөзнең 1935-1945 еллар тирәсендә барган вакыйгалар аша, язучы шул чор шәхесләренең драматик халәтен, бу хәлгә китергән сәбәпләрне ачып бирә.

Драматизм исә төрле сәбәпләр аркасында туарга мөмкин. Алда әйтелгәнчә, пьесада драматизм кешенең эчке дөньясында

туа. Әсәрдә шулай ук иҗтимагый-сәяси, хезмәт һәм әхлак проблемалары үзара тыгыз бәйләнештә бирелә. Аеруча яңа урнашкан совет хөкүмәтенең эшчәнлеге, аерым алганда җитәкчелек итүнең яңа алымнарын, гамәлләрен төшенү калку бирелә. «Сагынган чакларымда» драмасында система корбаннары, сәясәт һәм гаилә каршылыгы, сәяси вакыйгаларның кеше язмышын җимерүе кебек мәсьәләләр күтәрелә. Нигъмәт сүзләрендә, мәсәлән, совет системасына карата булган тәнкыйди фикер чагылыш таба: «Ачуың да килмәс иде. Син әйтмешли, җыен ялкау, җыен булдыксыз түрә булып йөрсен әле. Тир түгеп тапкан малыңны талап, сәвит төзиләр, имеш. Ичмаса, үзләрен влач дигәнче, талаучылар, караклар дисеннәр иде...» [2, б. 67].

Әлеге сүзләрдә аерым бер кеше фаҗигасе генә түгел, ә ил, халык фаҗигасе ачыла. Драма, нигездә, психологик характердагы конфликтка корылган, персонажларның күңел дөньясы ачыла барган саен, ул конфликтның система тарафыннан рәхимсез имгәтелгән шәхесләр фаҗигасе нәтиҗәсе икәнлеге ачыклана. Язучы шәфкатьсезлек, имансызлык кебек сыйфатларга да кагылып, «яңа» җәмгыятькә нәкъ шул сыйфатларның хас булуын, кешеләрнең рухи ярлылануын, идеологиянең кешенең дөньяга карашын да, әхлагын да, үз-үзен тотышын да үзгәртүен күрсәтә. Җәмгыятьтәге, аерым кешеләр күңелендәге начарлык кешене шәхес буларак юкка чыгара. Шулай итеп, пьеса иҗтимагый проблема – шәхес культы фаҗигаләре белән бәйле мәсьәләләрне алга куюы белән үзенчәлекле: сәясәт һәм гаилә каршылыгы; илдәге сәяси вакыйгаларның кеше күңелен тупасландыруы; шәхес культының гаиләләрне, кеше язмышларын җимерүе, гомерлек рухи газапта калдыруы һ.б.

Бу яктан әсәрдә сурәтләнгән Хәмит образы аерылып тора. Төрле сәбәпләр табып сугышка бармаган бу кеше колхозлаштыру елларында авыл халкын җәберли, хатын-кызларны мәсхәрәли, үзенең эш-гамәлләрен тормышка ашыруга комачаулык итүчеләрне юк итә. Мәсәлән, ул заманында мулла кызы булган, Шаһидәнең әнисе Мәрзиянең аңа кияүгә чыгуына баш тартканы өчен үч итә: сугыш елларында салкын тидергән, урын өстендә

яткан яшь Зәкия авыр эшкә, бер кулы гарип булган Нигъмәт шахта эшләренә озатыла, икесе дә вафат була. Мәрзиянең: «Үзебез монда, кызларыбыз ФЗӨ дигән эт олаккан җирдә тилмерә. Исемлекне син төзеп биргәнсең», – дип әйтүе шуның бер мисалы [2, б. 71]. Хәмит җитәкчелек итүне, заман таләпләрен, җәмгыятьтә миһербансызлык, явызлык урнаша баруны чагылдыручы образ. Түбәндәге әңгәмәдә бу геройның кылган гамәлләренә бәйле рәвештә яңа идеология алып килгән кайгы-сынаулар турында бәян ителә:

«Нигъмәт. Ала-ай... Ала-ай... Үтмәс балта белән юнган калхузлары безнең сырган юрганга калды микәнни соң... *(Тынып кала. Ияген учлап утыра).*

Мәрзия *(рәнҗүле тавыш белән)*. Болай да күзгә кырып салырлык әйбер калдырмадылар бит инде, тагын ни генә эзләп төшәләр икән, җир йоткырлары?! Атасы дим, Нигъмәт, әйт инде берәр сүз!

Нигъмәт. Теге юлы калхузларына кермәгән өчен черки урынына канны эчкәннәр ие, хәзер кандала урынына ябышырга уйлаганнар инде алайса (...). Бу сәвит дигәннәре алты почмаклы өебезне дә, яңа салган келәтне дә, ихатадагы мал-туарны да талап алды бит инде.

Мәрзия *(торып, өй эченә карана)*. Әйтәсең бармы. Ястыкмендәргә чаклы алып чыгып киттеләр бит!

Нигъмәт. Төртсәң, аварга торган бу өйдән ни-нәрсәне тамаша күрсәтеп сатарга җыеналардыр» [2, б. 61].

Әлеге диалогта бер гаилә язмышы мисалында халыкның, илнең совет һәм сугыш дәверендәге тормышы, илнең, халыкның фаҗигале хәле тасвирлана.

А. Әхмәтгалиева тарафыннан хатын-кызлар, сугыш чоры балаларының иңнәренә төшкән авырлыклар, яу кырында якыннарын югалтканнарның газаплы кичерешләре Шаһидә хәтерләүләрендә шәхси кичереш-бәяләр белән уңышлы үрелеп бирелә. Драманың үзәгендә яткан төп чыганак, искә төшерү (ретроспекция) – төп алым. Пьеса вакыйгалар катламы ретроспекция ясап, карчыкның хәтерендәге хәл-ситуацияләрне искә төшерү ке-

бек уйланылган. Әсәр ахырында Шаһидә ясый торган нәтиҗә тормыш хакыйкәте, яшәеш кануны дәрәҗәсенә күтәрелә.

«Ф ә н и я . Әнкәй, беләсең бит инде, авыл сөтеннән бизеп барабыз. Балалар да борын җыера, үлән исе килә, диләр. Кайчагында әрем тәме килгән кебек шул сөттән...

Ш а һ и д ә . Ашатырсың сыерга әремне, якын да бармый ул аңа... *(Авыр сулап).* Адәм баласы дөньяның ачысын-төчесен татып караганнан соң гына әремнән бал тәме килгәнен аңлый шул, балам. Әрем ачысыннан күпкә ачырак сыйлары да бар язмышның, авыз иткәннәр үзләре генә белә…» [2, б. 60].

Вакыйгалар барышындаШаһидә көчле, намуслы, үз эчендәге тормыш каршылыкларын җиңә алучы характер буларак ачыла. Хәмитнең кылган гамәлләренә түзәрлек хәле калмаган кыз: «Бар, Хәмит, бар!.. Димәк, йә син, йә мин... Ходаем! Җир йөзен хет бер адәм актыгыннан чистартсаң иде!» [2, б. 78] – дип, Хәмитнең якты дөнья белән саубуллашуга этәргеч бирә. Әлбәттә, бу геройның эш-гамәлләрен бәяләү аша аны «көчле кеше» концепциясенә кертеп була. Язучы моның өчен тарихи-иҗтимагый, сәяси проблематикага мөрәҗәгать итә, геройларын хата-ялгышулар аша уздыра. Пьесаның тагын бер уңышлы ягы: авторның үз героен кискен үзгәрү дәверендә, билгеле бер рухи «тупсаларны» атлап үтү вакытында сурәтли алуында.

Пьесада Шаһидәнең кадерле кешеләрен югалтуы, яшьлегеннән мәхрүм ителүе аша ялгызлык мотивы тергезелә. Шул рәвешле әсәрдә идеология китереп чыгарган фаҗигаләрне яктырту, югалтуларны советчыл идеологиянең кешегә кыйммәт итеп каравы, шуны тәнкыйтьләү килеп керә. Пьесада кешене һәм әсәрдә тәкъдим ителгән тормыш моделен бәяләүдә әхлаклылык һәм әхлаксызлык, хакыйкать һәм ялган, намус һәм намуссызлык, шәхси һәм гомуми мәнфәгатьләр дигән принциплар өстенлек итә.

Җыеп әйткәндә, бүгенге татар драматургиясендә шәхескә, аның рухи мәнфәгатьләренә, уй-кичерешләренә, кайгы-хәсрәтләренә генә түгел, җәмгыятьтәге, гаиләдәге урынына да игътибар артты. Автор, яшәештәге яхшылык һәм явызлык көрәшенә нигезләнеп, геройларын сынау алдына куя. Әсәрләрнең

конфликты да әнә шул көрәштән үсеп чыга. Яшәешнең җитди мәсьәләләрен үзәккә куйган пьеса үзара мөнәсәбәттәге ярату һәм нәфрәт, өмет һәм өметсезлек, ышану һәм ышанмау, горурлык һәм курку кебек төшенчәләрне иңләп үтә, аларның асылы турында уйланырга этәрә. Әрем исе – туган җир исе буларак, кешенең туган җире, авылдашлары, барыннан да бигрәк ата-анасы, сөйгәне, якыннары алдындагы җаваплылык символы дәрәҗәсенә күтәрелә. Гомумән, сызлану фәлсәфәсе белән сугарылган пьеса мелодраматик пафосы, тормышның серле дә, каршылыклы да күренешләре аша җитди уйлануларга этәрә.

## ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ЧЫГАНАКЛАР

1. *Әхмәдуллин А*. Яңарыш юлында. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – 206 б.

2. *Әхмәтгалиева А*. Сагынган чакларымда // Казан утлары. – 2017. – № 3. – Б. 57-100.

# КОНЦЕПЦИЯ ЭПОХИ И ГЕРОЯ В ДРАМЕ А. АХМЕТГАЛИЕВОЙ «ПОЛЫНИ СЛАДКИЙ ВКУС»

***Миннуллина Фатыма Халиулловна,***
*кандидат филологических наук,*
*Институт языка, литературы и искусства*
*им. Г. Ибрагимова АН РТ,*
*Казань, Россия,*
*minnullina77@mail.ru*

Статья посвящена изучению драмы А. Ахметгалиевой «Полыни сладкий вкус», где показана драма человека, на долю которого выпали суровые жизненные испытания. Акценты делаются на тенденциях ценностных трансформаций в характере героев. Современный социально-политический контекст проблемы рассматривается сквозь призму общечеловеческих ценностей. На основе анализа раскрываются характерные черты героев.

***Ключевые слова:*** драма, герой, пьеса, конфликт, жанр.

# THE CONCEPT OF THE ERA AND THE PROTAGONIST IN THE DRAMA OF A. AKHMETGALIEVA «WORMWOOD'S SWEET TASTE»

***Minnullina F.Kh.,***
*Candidate of Philological sciences,*
*Ibragimov Institute of Language, Literature and Art*
*of the Tatarstan Academy of sciences,*
*Kazan, Russia,*
*minnullina77@mail.ru*

The article is devoted to the study of A. Akhmetgalieva's drama "When I miss you" ("Wormwood's sweet taste"), which shows the drama of a person who has experienced severe trials of life. Emphasized the trends of value transformations in the character of protagonists. The modern socio-political context of the problem is considered through the prism of universal values. The characteristic features of the protagonist are revealed.

***Keywords:*** drama, protagonist, play, conflict, genre.

УДК 82.01.821.512.145

# 1920-1930 ЕЛЛАР ТАТАР ПРОЗАСЫНДА АГЫЙДЕЛ ХРОНОТОБЫ БИРЕЛЕШЕ

***Мөхәрләмова Гөлназ Нурфат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты,*
*Казан, Россия,*
*mukharlamgul@gmail.com*

Мәкаләдә ачык пространство образы буларак Агыйдел елгасы хронотоп-топонимы карала. 1920-1930 еллар татар прозасында ул сюжетны билгеләү функциясен үти, әсәрнең мәгънәсенә төшендерә, өйрәнелә торган чорның вакыйга һәм күренешләрен билгеләү аша аларның идея-эстетик үзенчәлекләрен дөрес һәм тирән аңлауга ярдәм итә.

***Төп төшенчәләр:*** хронотоп, хронотоп-топоним, ачык пространство, пространство образы, Агыйдел, бинар оппозиция.

1920-1930 еллар татар әдәбиятында ачык пространство буларак берничә хронотопик образ аерылып чыга, шулар арасында елга хронотобы аерым урын алып тора. Бу чорга караган әсәрләрнең күпчелегендә (М. Гафури, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, Ш. Камал, Г. Рәхим әсәрләрендә) әлеге хронотоп Идел елгасы белән бәйле булып, аның төрле мәгънәләрдә кулланылуын күзәтә алабыз: әсәрләрнең бер төркемендә ул ил юлын символлаштырса, икенчесендә туган илгә тиңләштерелеп бирелә, өченчесендә исә кешенең гомер агышын хәтерләтә. Дөньяның чиксез киңлеге, тулылыгы, елганың тизлеге, шул ук вакытта бормалы-сырмалы булуы, аның бөеклеге тормышның, шул исәптән иҗтимагый тормышның да бөтен катлаулылыгын һәм каршылыгын, анда күпсанлы коллизияләр һәм көтелмәгән борылышлар булуын күрсәтә. Татар әдәбиятында Идел хронотобының урынын Д.Ф. Заһидуллина да билгели [2, б. 33]. Әдәби әсәрләрдә елга, гадәттә, ачык киңлекне гәүдәләндерә. Елгада, тормыштагы ке-

бек үк, барысы да хәрәкәттә: ул я кайный-кайный ага, я култык өлешенә кереп, акрын гына билгеле бер үзән буйлап ага, я бөгеләсыгыла текә борылышлар ясый.

1920-1930 еллар татар әдәбиятында Идел хронотобы белән янәшә, әйтик, М. Әмирнең «Агыйдел», Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» повестьларында хронотоп-топоним функциясен Агыйдел елгасы да үти.

М. Әмирнең «Агыйдел» исемле әсәрендә елга матур һәм якты, очсыз-кырыйсыз киңлек итеп тасвирлана, шул рәвешле Агыйдел күренешләре ачык пространствоны характерлый. Елга матур сурәтләрдә, ачык төсләрдә бирелә: «Агыйдел!.. Рәсемдәге төсле матур, әкияттәге төсле серле, җырдагы төсле моңлы елга ул Агыйдел... Аның даны зурлыгы белән генә түгел, хозурлыгы белән таралган...». Агыйдел дә гел туры гына акмый, ул тормыш кебек бормалы: «Кыска гына ара эчендә дә чиксез күп борылышлар ясый, агымын әледән-әле үзгәртеп тора: бер карыйсың – яшәү көче, тормыш дәрте белән ярсыган яшь йөрәкне хәтерләтә; үзеннән-үзе биеп торган аякларын кая басарга, ташып барган көчен кая куярга белми аптыраган егетләр шикелле, ташларны актарып, уң яклап күтәрелгән текә тауларның каты ярларын кисеп, баш түбән ага. Ул арада булмый, көчле мәхәббәт кармагына эләгү нәтиҗәсендә төн йокысыннан мәхрүм калып, ай яктысына чыгып утырган яшь кызлар төсле, уйга батып китә; ике як ярларында үскән куаклардан асылып төшкән күләгә эчендә бөтенләй агуын онытып тора. Хәтта чит-читләрендә төнбоеклар үсүгә дә каршы килми» [1, б. 12-13].

Биредә әлеге пространство образы кеше тормышы чагылышы итеп бирелә, тормыш хронотобы белән тәңгәлләшә. Автор кешелек тарихында билгеле бер вакытка тормыш туктап калган мизгелләрнең дә, вакыт агышы акрынаеп яки, киресенчә, вакытның тизрәк үтүен билгеләгән моментлар барлыгын да безгә елга мисалында искәртә: «... Күп тә үтми, тагын, бик кирәкле эшен исенә төшергән кеше сыман, яңа тауларга таба борылып ашыга башлый. Ташларга бәрелүдән туган кечкенә-кечкенә дулкыннар күп булып

җыелышалар да, кызык күрергә ашыккан төркемдәй, берсен-берсе төртешә-төртешә, үзара әрләшә-әрләшә алга йөгерәләр» [1, б. 13]. Алга таба язучы пространствоны тагын да киңәйтә төшә: «…Барган юлында очраган кечкенә-кечкенә елгаларны үзенә ияртеп, зурая бара, зурайган саен «акылга утыра». «Ай уймаккай кебек сызылып аккан Ашказар»ны, төбенә шом яшереп аккан тыныч Димне, «нәзеккәй билле, ак тәнле кызлар» үстергән Уфа суларын ияртеп, ул шактый үсеп җитә, зур хезмәтләргә ярый башлый» [1, б. 13]. Киң һәм күп сулы Агыйделдән зур пароходлар, баржалар йөрерлек була. Ниһаять, Агыйдел, үзенең Кама, Идел кебек абзыйларына кушылып, Каспийга – диңгезгә чыга – киң тормыш эченә керә...» [1, б. 13]. Бу елганың иксез-чиксез юлы тормышның да шундый булуын күрсәтеп кенә калмыйча, ә бәлки илнең «иксез-чиксез» пространствосын үзгәрешләр колачлап алуы турында сөйли.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: әсәрнең беренче өлешендә әлеге пространство образы алдагы вакыйгалардан аермалы буларак, авылны биләп алган билгеле бер тынлык халәтендә бирелә: «Без төшкән тәнгәлдә Агыйдел каты акмый: өзлексез акрын гына күчеп торган киң, шома көмешкә ошый аның ул җире. Аргы як ярында үскән бөдрә таллардан асылган күләгәләр аның иртәнге серен тагын да арттыралар» [1, б. 13]. Ике яшь егет – Ильяс белән Гаязның авылга кайтканчы, ул үзенең тыныч һәм тигез тормышы белән яши бирә. Авылның Башкортстанның «пароходлар йөри торган» урыннарыннанерактарак урнашкан булуы да шул турыда сөйли. Озакламый студентлар әлеге матур һәм тыныч авыл тормышының тынычсыз, начар якларын да күрә башлый: «Табигатьнең чиксез матурлыгына күмелеп утырган тыныч авылның тынычсыз яклары, күңелсез яклары безгә күренергә ашыктылар» [1, б. 23]. Шулай итеп, үз көенчә яшәп ята торган авылның тынычлыгын бозучылар табыла. Алар арасында үзенең карлыккан тавышы белән кычкырып сөйләшүче, тукылдап йөрүче төнге каравылчы Имәли дә, егетләрнең тынычлыгын алучы Артыкбикә дә, сәер сүзләр сөйләшүче Ильяснең абыйсы да, Ильяс белән Гаяз үзләре дә бар. Ильяс белән Гаязның авыл

тынычлыгын бозучылар булуын язучы үзе ассызыклап әйтә: су коенганда алар тәвәккәлләп суга сикергәч, Агыйдел өстенең пыяла тигезлеге челпәрәмә килү күренеше шуңа ишарәли.

Авылның тынычсызлыгы Ильяснның күңел тынычсызлыгы белән тәңгәл килә, чөнки ул – шул авыл кешесе. Гаяздан аермалы буларак, Ильяснның күңеле һәрвакыт тынычсыз итеп бирелә. Әсәрдән күренгәнчә, аның «бөтенесеннән кул селкеп, күңелне борчыган барлык сорауларны онытып, табигать кочагына чумаргамы» дип уйлаган чаклары аз булмый. Ул алда торган эшләрнең күплегеннән һәм зурлыгыннан курка. Ләкин Ильяс никадәр авылга якын булмасын, алар Гаяз белән бу авылда бары тик кунак, биредә «вакытлыча» гына. Егетләр чит пространствога килеп эләгәләр. Шул рәвешле биредә Үзенеке/Читнеке бинар оппозициясе тәгаенләнә. Кунак булудан егетләр шактый күп вакытлар үтеп, авылда үз кеше булгач кына туктыйлар, бу пространство алар өчен үз пространствога әйләнә: «беренче көннәрдә безнең өчен искиткеч булып күренгән Агыйдел буйлары, ямьле тугайлыклар, куе урманнар, карага имәнеч ташлы таулар – һәммәсе дә табигыйләштеләр. Баштарак үзләренең төрле характерлары белән кызык булып тоелган кешеләр дә гади төс алдылар...» [1, б. 83].

Повестьта әдәби геройлар Агыйдел елгасының матурлыгына гына сокланып калмыйча, таулар, тигезлекләрнең гүзәллеге турында да хәйран калып сөйлиләр. Шулай бервакыт тауларга йөрергә чыккач, алар тигез киң болын буенча барып, куе урман белән капланган Тугай тавына килеп чыгалар. Шунда куе үлән арасында ял иткән арада «кәрешкә, мәтрүшкә, кәккүк чәчәкләре»нең хуш исен иснәп, «үлән арасына ятып җиләген» ашыйлар [1, б. 127]. Шулай итеп, дөнья алар өчен тагын да киңәя, һәммәсе дә «иркен тын ала». Тауның иң биек җиренә менеп җиткәч, яшьләрнең күзалдына бер хозур күренеш килеп баса: «Моннан инде дөнья чиксез киң булып күренә. Әллә кайлардагы исеме мәгълүм булмаган авыллар, чиксез озын булып борылып-борылып аккан Агыйделне аръяклап җәелгән киң-киң тугайларда тәңкә кебек чәчелеп яткан кечкенә-кечкенә күлләр, йомгак шикелле генә булып торган

печән кибәннәре...» [1, б. 135]. Шул рәвешле, автор яшьләрнең уй-ниятләренең ихласлыгына, теләк-омтылышларының тормышка ашуына, аларның барлык юлларны да җиңел үтә алуына ышаныч белдерә.

Өстәп әйтергә кирәк: бу ачык пространство образы – Агыйдел елгасы һәм аның буйларының матурлыгы геройларның халәтен тәгаенләп, тормышның яңаруына ишарәле кебек: «Матур иртәгә көлеп ачылган гөлҗимеш, зелпе чәчәкләреннән чыккан хуш исләр, тын яткан Агыйдел өстеннән бөркелгән салкынча һава һәм яңа гына елмаеп күтәрелгән иртәнге кояштан сибелгән рәхәт җылылык белән бергә кушылып, барлык тойгыларны да иркәлиләр, сөяләр» [1, б. 13].

Геройларның көзләр җитеп, авылдан шәһәргә китүләре турында сөйләгәндә дә автор ачык пространство буларак Агыйдел буендагы табигатьне тасвирлауга мөрәҗәгать итә: «Көзге аяз көн. Зәңгәр күк җилегендә тезелеп-тезелеп кыр казлары, кыр үрдәкләре оча. Тонык саф һавада ап-ак мамык төсле пәрәвезләр йөзә. Җәен ямь-яшел булып, күпереп утырган урманлы тау сары, кызыл, соры төсләргә кереп, алланган. Тугайлыктагы зелпе куаклары яшел әле. Куаклар тирәсендәге үләне чабылып алынган җирләргә, яңадан чабарлык булып, бөдрә курпы үскән» [1, б. 190]. Бу пространствоның киңлеге, иркенлеге, матурлыгы геройларның якты киләчәгенә ишарәли.

Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» повестенда да вакыйгалар башкорт җирләрендә, биек таулар, киң тугайлар арасында бормаланып аккан Агыйдел буйларында бара. Әлеге пространство шулай ачык буларак билгеләнә: «Агыйдел, безнең ындыр турында кинәт бер борма ясап, авылның эченә керә язып кала... Әле язгы ташкын бөтенләй кайтып бетмәгән икән. Зур, киң елгабыз үзенең биек ярлары эчендә тулышып, кайнашып ага. Балыкчылар, зур сөзгечләренең озын саплары югалып беткәнче суга чумдыра-чумдыра, балык аулыйлар...» [3, б. 48]; «Аргы якта әллә кайдан кая җәелеп яткан болындагы таллар ниндидер аерым бер көчле яшеллекләр белән бизәлгәннәр. Алардан бераз үтсәң,

Уралның безгә караган итәгенең тармаклары сырт-сырт булып тезелеп китәләр дә, бара-бара, каядыр еракта, күккә терәлгән җирдә, күгелҗем кара урманнар белән капланган биек тауларга барып ирешәләр» [3, б. 48]. Илдәге тынычсызлыкка Агыйдел елгасының тынычсыз агышы күрсәтә: «Балыкчылардан бер көймә алдык та, ярдан-ярга тулышып аккан Агыйделнең көчле дулкыннары белән көрәшә-көрәшә, ары якка чыктык» [3, б. 48].

Зур, киң Агыйдел буенда урнашкан авылларның да зур булуы күрсәтелә: «Зәңгәр Чишмә – үзенең зур базары белән бөтен Агыйдел буенда дан тоткан авылларның берсе, бәлки, беренчесе. Бөтен тирә-якның игене, малы, ялланырга теләгән ярлы җегетләре, уракпечән эшләре эзләгән фәкыйрьләр җомга саен безгә агылалар, бездән ерак җирләргә таралалар» [3, б. 13]. Гомумән, әсәрдә әдәби геройлар хәрәкәт иткән пространство әледән-әле Агыйдел елгасы белән бәйләнеп килә: «Агыйдел әллә кайлардан уралып-уралып, безнең шул җирләргә кагылып-кагылып үтә икән» [3, б. 35]. Әсәрнең төп геройларының берсе булган Солтан да акча эшләргә дип шахталарга килгәч, барактан ун гына сажин җирдәге бер бакча уртасыннан кечкенә генә елгага карап, туган җирен, якыннарын сагынуы турында әйтә: «Күңелем Зәңгәр Чишмәгә, Агыйдел буйларына китте». Шулай ук вагыйгаларның урынын алдагы җөмләләр билгеләи: «Сиңа, ди, шундый бер өй ясап бирим, бөтен Агыйдел буенда данын чыксын; өең, якмыйча, май кебек җылы булсын, ди» [3, б. 46]; «Агыйдел буендагы сөйләшүдән бер атна үтүгә, ул сәфәргә чыкты» [3, б. 50]; «Агыйдел буенда Гыйлаҗи белән мин генә калдым» [3, б. 51]; «Бик күп еллар Агыйдел буенда бергә каз бәбкәләре сакладык» [3, б. 53]; «Шулай, Агыйдел буенда бергә уйнап, бергә үскән җегетләр җир йөзенең әллә кай якларына таралдык та беттек...» [3, б. 64]. Төп геройга еш кына яшәү урынын (пространствосын) үзгәртергә туры килсә дә, ахыр чиктә аның Агыйдел буйларында кайтып төпләнү нияте аңлашыла: «Бер аяк белән чит илләргә китеп йөрү мөмкин булмаганга, мин инде калган көчемне шушы Агыйдел буйларына багышлармындыр, ахрысы» [3, б. 86].

Шулай итеп, әлеге әсәрләрдә Агыйдел хронотоп-топонимы төрле мәгънәләрдә кулланыла. М. Әмирнең «Агыйдел» повестенда ул башлыча геройларының тормыш юлы, гомер агышы белән тиңләштерелсә, Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» әсәрендә вакыйгалар бару урынын билгеләү өчен хезмәт итә. Әлеге хронотопик образ геройларның тормышында үзгәрешләргә ишарәләп, әсәрнең идея-эстетик үзенчәлекләренә төшенү мөмкинлеген бирә.

## ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ЧЫГАНАКЛАР

1. *Әмир М.* Агыйдел // Әмир М. Сайланма әсәрләр. Өч томда. Т. 3. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. – Б. 3-192.
2. *Заһидуллина Д.Ф.* Әдәби вакыт һәм әдәби урын // Татар әдәбияты: теория. Тарих / Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев, Н.М. Йосыпова. Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б. 32-34.
3. *Ибраһимов Г.* Кызыл чәчәкләр // Ибраһимов Г. Әсәрләр: 15 томда. Академик басма. Т. 3. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – 503 б.

## ХРОНОТОП РЕКИ АГИДЕЛЬ В ТАТАРСКОЙ ПРОЗЕ 1920-1930-Х ГГ.

***Мухарлямова Гульназ Нурфатовна,***
*кандидат филологических наук,*
*Институт языка, литературы и*
*искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ,*
*Казань, Россия,*
*mukharlamgul@gmail.com*

В статье рассматривается хронотоп-топоним реки Агидель как образ открытого пространства. В произведениях татарской прозы 1920-1930-х гг. он выполняет сюжетообразующую функцию, несет серьезную смысловую нагрузку, определяет свойственные изучаемому периоду события и явления, тем самым способствуя более объективному и глубокому осмыслению их идейно-эстетических особенностей.

***Ключевые слова:*** хронотоп, хронотоп-топоним, открытое пространство, пространственный образ, Агидель, бинарная оппозиция.

# THE CHRONOTOPE OF AGIDEL RIVER IN THE TATAR PROSE OF THE 1920S – 1930S

***Mukharlyamova G.N.,***
*Candidate of Philological sciences,*
*Ibragimov Institute of Language, Literature and Art*
*of the Tatarstan Academy of sciences,*
*Kazan, Russia,*
*mukharlamgul@gmail.com*

The article considers the chronotope-toponym of the Agidel river as an image of open space. In Tatar prose of 1920s-1930s it performs a plot-forming function, a message, defines events and phenomena of the period, thereby contributing to a more objective and deep understanding of their ideas and aesthetic features.

***Keywords:*** chronotope, toponym, open space, spatial image, Agidel river, binary opposition.

УДК 821.512.145

# МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ ИҖАТЫНДА ТУГАН ЯК ТЕМАСЫ: ОБРАЗЛАР, МОТИВЛАР ҺӘМ ПОЭТИКА

***Надыршина Ләйсән Рәдиф кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты,*
*Казан, Россия,*
*leysan_tatar@mail.ru*

Мәкаләдә XX–XXI йөзләр чигендәге татар интеллектуаль әдәбиятының күренекле вәкилләреннән берсе булган Марсель Галиев иҗаты анализлана. Әдипнең туган як темасын яктырткан лирик һәм прозаик әсәрләрендә төп образлар (туган җир, туган йорт, нигез һ.б.) һәм мотивлар (хәтер, сагыну, кайту һ.б.) аерып чыгарыла, аларның поэтик әһәмияте, эчтәлекне баетудагы роле билгеләнә.

***Төп төшенчәләр:*** Татарстанның Азнакай районы, татар әдәбияты, Марсель Галиев, мотив, образ.

Заман, туган җир, хәтер төшенчәләрен үзәккә куйган лирик-фәлсәфи рухтагы әсәрләрендә үзенә генә хас язу стиле белән сокландырган Марсель Галиев ике гасыр чигендәге татар интеллектуаль әдәбиятының күренекле вәкиле булып тора. Катлаулы эчтәлекле, яңача яңгырашлы шигырьләре һәм тирән психологизм белән характерланган романтик кичерешләр сурәтләнгән чәчмә әсәрләре янәшәсендә юмор-сатира үрнәкләре, әдәби тәрҗемәләре авторның киңкырлы эзләнүләрен чагылдыра.

Кама арьягында – Азнакай районы Балтач авылында туып үскән әдипнең иҗатында үткәннәр белән бәйле хәтер проблемасы һәрвакыт игътибар үзәгенә куелып, шигъри һәм проза әсәрләрен бер төенгә туплаган иң төп лейтмотив булып китә. Гомумән, А.Ф. Ганиева фикеренчә, 1960 нчы еллар татар әдәбиятында йорт-нигез образы белән тыгыз бәйләнештәге әхлакый хәтер темасы үзәк темага әйләнә [4, с. 13]. Марсель Галиев иҗаты да шушы үзенчәлек контекстында карала ала. Әдипнең күңел лирикасы үрнәкләрендә

хәтер мотивы туган як темасы һәм шушы тема яктылыгында ачылган туган җир, авыл, нигез, әти-әни образлары белән үрелеп бара («Мәдхия», «Иңнәрдә погон булса, күңелне сагыну баса», «Күңелдә бер бизәк» һ.б.). Әлеге шигырьләрдә лирик герой хисләре шагыйрьнең үз кичерешләре булып кабул ителә, әдипнең тормыш биографиясе белән бәйле детальләр бу янәшәлекне тагын да көчәйтә, сагышлы уйланулар әсәрләрнең төп эчтәлеген хасил итә һәм үткәнне сагыну мотивы белән кушылып китә. Кая гына барса да, лирик геройның күңелен биләгән җирсү хисе, вакыт агышында туган як образының да үзгәрә баруын аңлау лирик геройның балачак һәм яшьлек сафлыгын сагынуы белән тыгыз бәйләнештә укыла («Туган якның карашы», «Югалган блокноттан», «Һава өләшүче җарияләр», «Көтүче» һ.б.). *Чыбыркы, тургай, каен, учак, тугай, урман* кебек образ-детальләр лирик герой күңелендә сакланган авыл картинасын төгәлләштерүгә буйсындырыла. Туган җир турындагы хатирәләрнең күңелгә юаныч бирүе, әмма еллар шаукымы нигездән һаман да ерагайтуы турындагы сызланулы-сыктаулы кичерешләр шигырьләрдә лейтмотив булып үтә:

Туган җирем тургай булып
Сыйган күңел читлегенә.

Әреме дә гөл генә шул,
Әреме дә гөл генә...

Нигез ташы чума бара
Караңгы җир күгенә... [1, б. 214].

Шигырьләрдә кешенең һәрвакытта да сагышлы җанына туган җирендә тынычлык таба алуы, бар юлларның да туган якка юнәлгәнлеге турындагы идея татар әдәбиятында традицион булган мәңгелек кайту мотивын яңарта. «Сагынып кайту», «Бәхет», «Күреп кал», «Туган якка кайткач» кебек әсәрләр нәкъ менә шушы мотив яктылыгында укыла, «Ераклыклар җиле» шигырендә адәм баласының туган җир куенында мәңгелек сыену урыны табуы яшәешнең табигый чиге буларак кабул ителә, аның һәр кеше өчен кадерле, сакраль урын булуы хакындагы фикерне автор сәнгати формада җиткерә:

Бу җилкуар улың, кайта-кайта,
Юлларыңны күпме такырайтты.
Шул наратлар беркөн...
җилгә әйтер:
– Ниһаять, ул соңгы тапкыр кайтты... [1, б. 239].

Шагыйрьнең җырга әйләнгән шигырьләрендә дә («Актүбә чишмәләре», «Урсай җире» һ.б.) туган җирне ярату мотивы зур урын алып тора, еш кына ул «аерылышу, сагыш мотивы белән аваздаш» [5, б. 96] яңгырый.

Геройларның күңел кичерешләре, эчке дөньясы, уй-гамьнәре беренче урынга чыккан, вакыйгалар шушы катлаулы хиссиятне ачу өчен фон ролен үтәгән, психологизм алымнарына иркен мөрәҗәгать итеп язылган хикәяләрендә туган як, төбәк, нигез образлары яшәү мәгънәсен соңлап аңлауга бәйле үкенеч хисе белән бер бәйләмдә килә. Әйтик, шушы рухта иҗат ителгән «Сатурн һәм умач» хикәясендә автор кешене үткәндәге якты хатирәләр бәхетле итеп яшәтүе турында сөйли, һәр кешенең тамыры туган җиренә береккәнлеген ассызыклый, нигез, туган тел, хәтер – шәхесне бөтенлектә яшәтүче, җанының иң нечкә кылларын тибрәндерүче төшенчәләр буларак раслана. Иң мөһиме – кеше үзенең балаларына да шушы кыйммәтләрне мирас итеп тапшырырга тиеш. Гомере буе авылыннан читтә яшәгән, фәндә бик зур уңышларга ирешкән, дөньякүләм дан казанган Камил Акчурин бу хакыйкатьне соңлап төшенә, кызы Ләләгә туган телен өйрәтә алмавына ачына, «үз кызыма туган җиремне күрсәтә алмаган нинди ата инде мин» дип үрсәләнә. Әсәр исеменә чыгарылган гыйбарәдә үк туган җир, нигез төшенчәләре галәм киңлекләренә каршы куела, кешенең үз тамырларын онытмаска тиешлеге проблемасы калкыта. Камилне туган ягына үзе дә аңлата алмаган җирсү, ашкыну алып кайта, аның һәр гамәле, уй-фикере хәтерен кузгата, автор тамчы гөл, чишмә, кашык белән катык ашау һ.б. детальләр аша геройның күңел төпкелендә яткан хатирәләр дәрьясын «казып чыгара», туган җиргә ашкынып кайту аның язмышын үзгәртә, һәлакәттән коткарып кала.

Язмышлары туган җирдән читтә үткән геройлар «Затлы чыбыркы хуҗасы» (1976) һәм «Язмышлар» (1985) хикәяләрендә дә

үзәктә тора. Беренче хикәядә авылдан үксезлеге, үзен яклый алмавы аркасында нахак сүз ишетеп чыгып киткән көтүче Гамиснең күңеленә туган җирдән читтә үткән еллары салган җәрәхәт психологик җирлекле портрет детале аша бик төгәл итеп җиткерелә: «Күзләрендә элеккеге моң юк, әллә нинди салкынча, үтәли караш» [2, б. 245]. Шул ук вакытта Гамиснең ничә еллар инде чыбыркы шартлатасы килеп яшәве аның сагыну-җирсү хисен күрсәтә, авылда чыбыркы түгел, көтүче дә калмавы турындагы сүзләр сала тормышына хас үзгә бер ямь, табигыйлекнең үткәндә калуы, авылның һәм авыл халкының үзгәрүе турында сызланып уйландыра.

«Язмышлар» хикәясендә туган җиргә, телгә, халкыңа, тамыр-тарихыңа, ата-анаңа хыянәт кеше җанын каралтучы коточкыч гамәл буларак кабул ителә. Шундый хыянәткә барган Рәниф язмышы мисалында автор тамырларыннан аерылган кеше үзеннән соң лаеклы нәсел дә калдыра алмый, тормышы китек була, җан газабы аның язмышын яралы итә, дигән идеяне үткәрә: «Ата белән баланың туган җирләре уртак булмаса, күңел бердәйлегенә ирешү читен икән шул. Үз телемне өйрәтә алмадым...» [2, б. 262]. Хикәядә һәр кеше үз ямышын үзе сайлый дигән фикер кызыл җеп булып сузыла, туган җирдән аерылып яшәү юлын сайлаучыларның яшәү ямен, тәмен татудан мәхрүм калулары шәхес фаҗигасе дәрәҗәсендә кабул ителә.

М. Галиевнең күләмле проза әсәрләрендә дә лирик-романтик сызык беренче урынга куела, прозадагы геройлар еш кына үкенү, сагыну, җирсү, сагыш, хәсрәт хисләре дулкынында яши, шушы халәттән качу рәвешендә, хәтер мотивы аша үткәнгә юнәлдерелгән ретроспектив хатирәләр кире кайтмас яшьлек гүзәллеге, үткәндә калган гамьсезлек хакындагы сентименталь уйлануларга китерә. Мәсәлән, «Ул чакта» (1977-1978) повестенда «Кеше ни өчен яши?» соравына җавап эзләп, Сәйяр һәркемнең яшәү максатын түбәндәгечә билгели: «Үзеңнән соң да яшәү, кешеләр хәтерендә генә түгел, матди җирлектә дәвам итү – хикмәт шуңа ирешүдә түгел микән?..» [2, б. 126]. Повестьта әлеге идея Сәйярнең әбисе – Җиһан карчык образы мисалында җиткерелә, яшәеш принциплары табигать белән гармониядә, тормышны яратып, дини-

әхлакый кануннарны хаклап гомер кичерү, яшәве белән дә, үлеме белән дә якыннарына бер мәшәкать тудырмаудан гыйбарәт әлеге образ, тарих, хәтер, нәсел сакчысы буларак сурәтләнеп, татар әдәбиятындагы ана архетибының бер модификациясе буларак карала, автор аны үзе үк текстта «авыл анасы» дип атый. Җиһан карчыкның яшәеш кануннарын үзенә өлге итеп алган Сәйяр аның нәсел дәвамчысы, рухи-әхлакый кыйммәтләрне киләчәк буынга илтүче буларак кабул ителә.

М. Галиевнең бөтен иҗат дәверендә зур урын алып торган, сакраль, изге урын буларак сурәтләнгән туган як, нигез образы әдипнең «Нигез» повестенда, көчле позиция алып, әсәр исеменә үк чыгарыла. Повестьның һәр вакыйгасы, лирик-фәлсәфи чигенешләр, сынландырулар – барысы да туган җир образын детальләр аша төгәлләштерүгә буйсындырыла, туган җир – кешенең олы дөньяга күзе ачылган, шәхес буларак формалашкан урыны дигән идеяне раслый. «Каспий диңгезенең башы – безнең авыл чишмәсеннән икән бит!» дигән гыйбарә аша бу идея әсәр тукымасына кертеп җибәрелә. Хикәяләүче герой Тәнзил хатирәләре аша әти-әни, туганнар, авыл кешеләре һ.б. образларның портреты, холык-фигыльләре аерым эпизодлар аша бөртекләп торгызыла, авыл халкының гаҗәеп саф, чиста күңел дөньялары укучы хозурына тәкъдим ителә.

Повестьның үзәгендә кеше язмышы проблемасы тора, гомерләрен сугыш фаҗигасе тамырдан үзгәрткән геройларның хис-кичерешләренең шаһите, алар турындагы хәтерне саклаучы өянке образы, әдәбияттагы «дөнья агачы» архетибының модификациясе буларак, нигез, туган як символына әйләнеп китә. Ул – кешеләрне олы юлдан читкә озатып калган һәм аларны беренче булып каршы алган, туган якның аерылгысыз өлешен тәшкил иткән сакраль образ: «Сугыш бетеп, бер ел үткәч, Алтын Болак авылы кешеләре, матур бер гадәт уйлап чыгарып, минем ялгыз моңсулыгыма җылы кул белән кагылдылар. Җиңү көнендә хатын-кызлар, яудан кайткан ир-атлар минем яныма җыелды. Шушыннан киткәннәр иде бит алар, шушыннан озатып калганнар иде бит аларны...» [3, б. 273]. Повестьта мәңгелек кайту мотивы бөтен сюжетны бер үзәккә юнәлдерә, туган җирнең үз бала-

сын һәрвакыт кабул итүе турындагы идея лейтмотив булып үтә: «Кош оясы кебек, авыл улларын-кызларын ерак-еракларга очырып җибәрә дә киредән үзенә җыя. Буыннан-буынга шулай кабатланган. Кемнәрнеңдер эчәр суы, кабар ризыгы бетмәгән – кире кайтып төшә. Кемнәрнеңдер юлы чит туфракта мәңгегә өзелеп кала... Буыннан-буынга шулай кабатланыр...» [3, б. 300-301]. Нинди генә авырлыклар кичерсә дә, күңелендә никадәр тирән җәрәхәтләр булса да, адәм баласының бу ярасы «чишмә сулары, авылдашларының җылы карашы, кыр-тугайларның шифалы җиле белән генә, әкрен-әкренләп кенә төзәлергә, җөен калдырып йомылырга мөмкин» [3, б. 300].

Автор тарафыннан иркен кулланылган сынландыру алымы өянкенең уйлануларын мөстәкыйль бәйләм буларак күзалларга мөмкинлек тудыра, кешеләр белеп-төшенеп бетермәгән хакыйкатьне үзендә саклый өянке, күпме сер, җан газабы, шикләнүуйланулар шаһите булган ул. Повесть азагында карт өянкенең авуы – тулы бер чор, дәвер белән хушлашу, үткән белән бәхилләшү кебек укыла. «Юлга аркылы ауган карт агач без белгән Өянке түгел. Өянкенең асылы бу мәлдә якты, чиксез биеклеккә ашып, дөнья хәтеренә кушылырга ашыга иде» [3, б. 334]. Мондый бетем яшәештә һәр нәрсәнең вакытлы булуын, дөньяның үзгәреше табигый процесс булуын, бары хәтернең мәңгелеген ассызыклый.

Шул рәвешле, туган җир, нигез, хәтер, нәсел-тамыр, туган тел төшенчәләре Марсель Галиев иҗатын иңләп бара, туган якны сагыну, җирсү, тамырлар өзелүгә үкенү мотивлары әдипнең лирика һәм прозасын моңсу-сызланулы укылышка көйли.

## ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ЧЫГАНАКЛАР


1. *Галиев М.* Әсәрләр. 6 томда. Т. 1. – Казан: Идел-Пресс, 2011. – 408 б.
2. *Галиев М.* Әсәрләр. 6 томда. Т. 3. – Казан: Идел-Пресс, 2011. – 392 б.
3. *Галиев М.* Әсәрләр. 6 томда. Т. 4. – Казан: Идел-Пресс, 2011. – 376 б.
4. *Ганиева А.* Модификация образа дома в современной татарской прозе // Филологические науки. Вопросы теории и практики. – 2017. – № 11 (77). – Ч. 1. – С. 12-15.
5. *Хәбетдинова М.* «Без бу җиргә юкка килмәгән...» (Марсель Галиевкә 70 яшь) // Казан утлары. – 2016. – №10. – 94-101 б.

# ТЕМА РОДНОГО КРАЯ В ТВОРЧЕСТВЕ МАРСЕЛЯ ГАЛИЕВА: ОБРАЗНАЯ СИСТЕМА, МОТИВИКА И ПОЭТИКА

***Надыршина Лейсан Радифовна,***
*кандидат филологических наук,*
*Институт языка, литературы и искусства*
*им. Г. Ибрагимова АН РТ,*
*Казань, Россия,*
*leysan_tatar@mail.ru*

Статья посвящена анализу творчества Марселя Галиева, представителя интеллектуальной татарской литературы рубежа XX–XXI вв. На материале лирических и прозаических произведений, посвященных теме родного края, выявляются основные образы (родной земли, отчего дома и др.) и мотивы (памяти, тоски, возвращения и др.), анализируемые автором статьи как на уровне поэтики, так и на содержательном уровне.

***Ключевые слова:*** Азнакаевский район Республики Татарстан, татарская литература, Марсель Галиев, мотив, образ.

# THE NATIVE LAND'S THEME IN THE WORKS OF MARCEL GALIEV: FIGURATIVE SYSTEM, MOTIVATION AND POETICS

***Nadyrshina L.R.,***
*Candidate of Philological sciences,*
*Ibragimov Institute of Language, Literature and Art*
*of the Tatarstan Academy of sciences,*
*Kazan, Russia,*
*leysan_tatar@mail.ru*

The article analyzes Marcel Galiev's works, one of the representative of intellectual Tatar literature at the turn of the 20$^{th}$ – 21$^{st}$ centuries. On lyric and prose works about native land, the main images (the native land, home, etc.) and motives (memory, melancholy, return, etc.) identified and analyzed on the poetics, and content level.

***Keywords:*** Aznakaevsky district of the Republic of Tatarstan, tatar literature, Marcel Galiev, motif, image.

# СУДЬБА ЯЗЫКА –
# СУДЬБА НАЦИИ

* * *

# ТЕЛ ЯЗМЫШЫ –
# МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ

УДК 81’282.3

# ХӘЗЕРГЕ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ КӨНЧЫГЫШ, БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ КӨНБАТЫШ ӨЛКӘЛӘРЕНДӘ ТАРАЛГАН ТАТАР СӨЙЛӘШЛӘРЕНЕҢ ФОРМАЛАШУ ТАРИХЫННАН (МИНЗӘЛӘ СӨЙЛӘШЕ МИСАЛЫНДА)

***Хисамов Олег Ришат улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем.*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институты,*
*Казан, Россия,*
*ohisamov@mail.ru*

Мәкаләдә татар теленең урта диалектына караган минзәлә сөйләшенең формалашу этаплары турында сүз бара. Шулай ук сөйләшнең өйрәнү тарихы һәм аның төп лингвистик үзенчәлекләре яктыртыла.

***Төп төшенчәләр:*** татар теле, татар теленең урта диалекты, диалектология, татар диалектологиясе, Минзәлә сөйләше.

Татар тел белеменең мөстәкыйль тармакларының берсе булган – татар диалектология фәне үзенең бер гасырга якын булган үсеше дәвамында, башка төрки телләр белән чагыштырганда, бик зур уңышларга иреште. Татар диалектология фәненең аеруча уңышлы чоры итеп үткән гасырның алтмышынчы елларыннан башлап, хәзерге гасырның беренче ун еллыгын күрсәтергә кирәк. Ярты гасыр эчендә татар диалектологларының зур булмаган төркеме Россиядә таралган барлык сөйләшләрне баштан-аяк өйрәнеп чыктылар. Төрки халыклардан беренчеләрдән булып, татар теленең Диалектологик Атласын төзеделәр [2]. Әлеге Атлас 838 торак пунктны үз эченә ала.

Диалектологларыбызның тырышлыгы белән төрки телләрнең лингвистик географиясе һәм ареал лингвистикасының нигез ташлары салынды. Безнең диалектологлар диалектологик атлас өчен материаллар туплау белән бер үк вакытта татар сөйләшләрен

монографик өйрәнү буенча да зур кыйммәткә ия булган материаллар туплап бардылар.

Татар диалектологларының тагын бер зур хезмәте итеп татар теленең зур Диалектологик сүзлеген күрсәтергә кирәк [9]. Анда тупланган материаллар татар диалектологиясенең тагын да югары үрләргә күтәрелүендә ышанычлы нигез булып торалар.

Диалектология фәне, нигездә, билгеле бер төбәкләрдә авыл шартларында яшәүчеләрнең сөйләм телен өйрәнә. Татар авыллары, көнбатышта Рязань һәм Тамбов өлкәләреннән башлап, көнчыгышта Кемерово өлкәсенә һәм Красноярск краена, төньякта Вилюй елгасына, көньякта Әстерхан өлкәсенә хәтле сузылган гаять зур территориягә таралып утырганнар. Әмма татар халкының иң зур күпчелеге Татарстан, Башкортстан республикаларында гомер кичерә.

Югарыда күрсәтелгән киңлекләрдә таралган татар теле өч диалектка – урта (казан татарлары), көнбатыш (мишәр) һәм көнчыгыш (себер татарлары) диалектларына бүленә.

Татар теленең иң зур диалекты булып саналган урта диалект (казан татарлары диалекты) үз эченә зур территориядә, башлыча Татарстан һәм Башкортстан республикаларында һәм аларга якын булган төбәкләрдә – Казан артыннан башлап, Чиләбе, Курган һәм Оренбург өлкәләрендә таралган күп санлы сөйләшләрне ала. Фәндә урта диалект вәкилләре – казан татарлары Идел буе болгарларының варислары булып исәпләнә һәм башлыча үзләренең борынгы бабалары биләгән туфракларда яшиләр дигән фикер урнашкан. Урта диалект сөйләшләре системасының катлаулы булуы байтак кына тарихи сәбәпләргә бәйле: Идел буе болгарларының җирле кыпчак кабиләләре тарафыннан ассимиляцияләнүе, күрше фин-угор, төрки, славян халыклары белән үзара тәэсир итешеп яшәүләре, бу халыкларның татарлар тарафыннан өлешчә ассимиляцияләнүе, татар халкының бер өлешенең дини яктан изоляцияләнүе, аерым этник төркемнәрнең төп массадан территориаль ерак торуы, соңгы чорларда мишәр диалекты йогынтысының артуы һ.б.

Хәзерге вакытта урта диалект (казан татарлары) түбәндәге сөйләшләргә бүленеп карала: Казан арты сөйләшләре төркеме

(Әтнә, Лаеш, Балтач, Мамадыш, Дөбъяз – Казан арты районнары), тау ягы сөйләшләре төркеме (Кама Тамагы, Норлат, Тархан – Идел һәм Зөя елгалары арасы), керәшен татарлары сөйләше (Казан арты, Түбән Кама сөйләшләре – Татарстан һәм Башкортстан Республикаларының чиктәш районнары, нагайбәк (Чиләбе өлкәсе), бәрәңге (Мари Иле), минзәлә (Татарстанның көнчыгыш, Башкортстанның көнбатыш районнары), бөре (Башкортстанда Агыйделнең урта агымы), нократ-кистем (Киров өлкәсе һәм Удмурт Республикасы), касыйм (Рязань өлкәсе), пермь (Пермь өлкәсе), златоуст һәм красноуфим сөйләшләре (Башкортстанның төньяк-көнчыгыш районнары, Свердловск өлкәсе), эчкен (Курган һәм Чиләбе өлкәләре)...

Соңгы елларда башкарылган фәнни тикшеренүләр татар әдәби теленең формалашуында һәр диалектның ролен төгәлрәк билгеләргә мөмкинлек бирде. Татар диалектологлары барлык татар диалектларының да (урта – казан татарлары, мишәр, себер татарлары (тубыл-иртыш, бараба, том диалектлары) нигезен борынгы кыпчак теле тәшкил итә дигән нәтиҗәгә килделәр.

Кыпчаклардан тыш татар халкының, аның аерым төркемчәләренең формалашуында угыз кабиләләре дә әһәмиятле роль башкаралар. Билгеле булганча, Идел һәм Җаек буйларына кадәр таралган угыз кабиләләре XI гасыр урталарында әлеге территориядән кыпчаклар тарафыннан кысып чыгарылалар.

Кыпчаклар белән озаграк һәм тыгызрак мөнәсәбәттә булган регион тел ягыннан М.И. Әхмәтҗановның «Шәҗәрә материаллары буенча Ык елгасы бассейнында барган этнолингвистик процесслар» [4] дигән мәкаләсендә анализлана. Галим монголлар басып алуына кадәр Ык елгасы бассейнында болгарлар һәм угырлар яшәгән дип саный. Идел буеннан болгарлар бу территориягә күпләп күчеп утырган булалар инде. Угырларның бер өлеше көньяктан килгән кыпчаклар тәэсирендә төньякка һәм төньяк-көнчыгышка таба кузгала, ә икенче бер өлеше кыпчак телен кабул итеп яшәгән урыннарында кала.

1552-1557 еллар вакыйгаларыннан соң Казан һәм Казан арты халкының бер өлеше, басып алучыларга буйсынырга теләмичә, Ык елгасы бассейнына күчеп утыра.

1652-1657 елларда Кама аръягы ныгытма линияләрен төзү башлана. Бу вакытта әлеге эштә катнашуга Казан астыннан һәм көнбатыш өлкәләрдән тагын татарлар күчеп утыртыла. Шул рәвешле XVII гасырга бу җирләрдә кыпчак-нугай чыгышлы булган татарлар күпчелеккә әйләнәләр.

Җир биләмәләренә мөнәсәбәтле рәвештә әлеге территориянең халкы (хәзерге Башкортстан республикасының көнбатыш, Татарстан республикасының көнчыгыш районнары) төп 3 социаль катламга бүленәләр, типтәрләр, казан кешеләре һәм башкортлар. Әлеге катламнар арасында башкорт катламы иң югары дәрәҗәдә була. Казан кешеләре һәм типтәрләр дәүләткә генә түгел, җир биләүче башкортларга да бәйле булалар.

Бу социаль катламнар тел үзенчәлекләре, хуҗалык итү алымнары, тормыш культурасы яки рухи мәдәният ягыннан берберсеннән бер нәрсә белән дә аерылмаганнар. Җирләре булмаган типтәрләр һәм казан кешеләре төрле юллар белән өстенлекләре күп булган башкорт катламына керергә омтылганнар. Ә иң күп санлы катламны типтәрләр тәшкил иткән.

XVIII-XIX гасырларда фәнни әдәбиятта типтәр-бобыль катламында кайсы этник төркемнең өстенлек итүе хакында бәхәсләр күтәрелеп тора. Игътибар итегез, бу факт типтәрләрнең (ә шулар рәтеннән башкортларның да) аерым бер милләт түгел, ә бәлки социаль төркем булганлыклары турында галимнәрнең бернинди шикләре булмаганлыкны күрсәтүче дәлил. П.И. Рычков, П. Небольсин һәм П. Кеппен хезмәтләрендә типтәрләр арасында татарларның күплеге ассызыклана. Шуңа да карамастан бары тик XX гасыр башында гына Казан император университетындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте вәкиле, татар теле белгече, этнограф Г.Н. Әхмәров типтәрләрнең телен, мәдәниятен һәм тормыш-көнкүрешен тирән өйрәнү нәтиҗәсендә, типтәрләрнең күбесе татарлардан дигән ахыргы нәтиҗәгә килә. Галим типтәрләрнең теле, диннәре, гореф-гадәтләре һәм авыл атамалары аларның Казан һәм Вятка губерналарыннан чыкканлыкларын раслаучы дәлил итеп күрсәтә.

Региондагы татарларның тел үзенчәлекләрен беренче булып фәнни яктан өйрәнгән рус галиме А.Г. Бессонов була. 1881 елда аның «О говорах Казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам» исемле хезмәте басылып чыга. Анда галим региондагы татар сөйләшләрен казан татарлары сөйләше белән чагыштыра һәм нәтиҗәдә алар бер-берсеннән аерылмыйлар дигән нәтиҗәгә килә. Региондагы татар сөйләшләренең бары тик күпмедер дәрәҗәдә башкорт теленең һәм мишәр сөйләшенең тәэсирен кичергәнлекләрен ассызыклый. А.Г. Бессоновның әлеге фикеренең дөреслеген әлеге территориядәге сөйләшләрне махсус өйрәнгән галим Д.Б. Рамазанова материаллары да раслый [8]. Галимә Башкортстанның көньяк-көнбатышында таралган сөйләшләр, күпмедер дәрәҗәдә, мишәр диалекты тәэсирендә формалашканнар дигән нәтиҗәгә килә.

Шушы регионда киң таралыш алган, минзәлә сөйләшенең фонетик үзенчәлеге саналган “d” тартыгын А.Г. Бессонов татар әдәби телендә кулланылышта булган “д” тартыгы белән тәңгәлләштерә. Сүз уңаеннан шунысын да әйтеп китәргә кирәк: әлеге авазны без үткән гасырның 50 нче елларында Казан артыннан һәм тау ягы районнарыннан язып алынган диалектологик текстларда да очратабыз. Ягъни бу аваз минзәлә сөйләшендә генә түгел, урта диалектның башка сөйләшләрендә дә булган икән.

Региондагы татар сөйләшләрен өйрәнүгә үзенең өлешен танылган тюрколог Н.Ф. Катанов та кертә [6]. Ул 1898 елда 3 ай дәвамында Бәләбәй өязендәге сөйләшләрне тикшерә. Ул мондагы халыкның сөйләше икегә аерыла – өязнең көнчыгышында таралган чынлап та башкорт сөйләшләре һәм өязнең көнбатышында яшәүче татарлар сөйләше дигән нәтиҗәгә килә.

Бу мәсьәләдә совет тюркологы, башкорт теле һәм диалектологы А.А. Юлдашевның [11] да фикерләре кызыклы. Бөтен гомерен шушы эшкә багышлаган галим төньяк-көнбатыш диалектын башкорт теленә кертеп карауны дөрес түгел дип саный. Һәрвакыт әлеге сөйләшнең татар теленең урта диалектына кергәнлеген ассызыклый һәм аның татар әдәби теленә бик якыная барганын

искәртә. Ул берничек тә башкорт теле системасына керә алмый дигән фикер үткәрә.

Лингвист-тюрколог Җ.Г. Киекбаев үзенең тикшеренүләре нәтиҗәсендә хәзерге башкорт әдәби теленең нигезендә ике диалект (көнчыгыш һәм көньяк диалектлар) ята дигән нәтиҗәгә килә. Ул өченче диалектның барлыгын инкяр итә һәм ул диалект татар теленеке дип саный.

Алда искә алып киткән галимнәрдән тыш, минзәлә сөйләшен өйрәнүгә Җ.Г. Алмаз, А.Ш. Әфләтүнов, Г.Х. Әхәтов, Ф.С. Баязитова, Л.З. Җәләй, Л.Т. Мәхмүтова, И.С. Насипов кебек галимнәр дә үз өлешләрен кертәләр. Әлеге галимнәр, бер тавыштан, минзәлә сөйләшенең татар әдәби теленә якынлыгын ассызыклыйлар.

Шактый зур территориягә таралып утырган минзәлә сөйләше үзенең төп элементлары ягыннанербөтен. Шул ук вакытта периферик элементларны, лингвистик һәм экстралингвистик факторларны исәпкә алып, сөйләш төп, әгерҗе, янаул һәм бәләбәй урынчылыкларына бүленә.

Сөйләшнең төп фонетик үзенчәлекләре итеп без инде югарыда күрсәтеп үткән интердентderл [d] авазының кулланылуыннан тыш (*Беd, сабан туйы, димәйбеd, җыйыын дибеd*), сүз башында [й] тартыгы урынына [ж] тартыгын куллануны күрсәтергә кирәк. Бу үзенчәлек, гомумән, сөйләшнең генә түгел, урта диалектның төп үзенчәлеге һәм урта диалектның барлык сөйләшләрендә дә очрый. Мәсәлән, *җафрак* – яфрак, *җозак* – йозак, *җон* – йон, *җөрү* – йөрү һ.б.

Тартыклар системасы, гомумән алганда, әдәби телнекеннән аерылмый. Татар әдәби теленә һәм татар теленең Казан ханлыгы чорында формалашып беткән казан арты, тау ягы сөйләшләренә бик якын тора. Бу аңлашыла да, Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, ханлыкның төп халкы үзләренең ата-бабаларының изге туфракларына килеп егыла. Әйткәнебезчә, IX–X гасырлардан башлап, Урал итәкләреннән Идел елгасы бассейнына иксез-чиксез кыпчак төркемнәре агыла башлый.

Үзенчәлек авазлар тәңгәллегендә генә чагылыш таба. Мәсәлән, кайбер сүзләрдә әдәби телдәге [д] тартыгы урынына яңгырау спирант [з] кулланыла: *бозай* – бодай, *Изел* – Идел, *казак* – кадак һ.б.

Сөйләштә әдәби телдәге *-ый/-ий* дифтонгы урынына *-ай/-әй* дифтонгы кулланыла. Шулай ук бу күренешне дә сөйләш өчен генә уникаль күренеш дип әйтеп булмый. Ул урта диалектның кайбер сөйләшләрендә һәм көнчыгыш диалектларда да актив кулланыла. XX гасыр башына кадәр татар әдәби язма сөйләмендә кулланылышта була.

Кайбер грамматик үзенчәлекләр: мин, син алмашлыклары юнәлеш килешендә *мийә/сийә, миңә/сиңә* вариантында кулланылырга мөмкин. Мәсәлән, *Шул wахытта мийа қыстыбый китерде.*

Сөйләшнең тагын бер үзенчәлеге булып анда анау//анаwу//анаwы//анаwу, монау//монаwу//монаwы//монаw күрсәтү алмашлыкларының кулланылуы тора. Кайвакытта әле *монау* алмашлыгына тартым кушымчасы да өстәлеп *монаусы* варианты барлыкка килә. Мәсәлән, *Монаусы матур.*

Үзенчәлекле сорау алмашлыклары кулланыла: кем, ний, нәрсә//нәрсәкәй//нәстә//нәстәкәй//нийәстә//нийәстәкәй//нәмәрсә//нәмәрсәкәй, ничә, ничек, кайсылай, нихәлле, ник, нигә//нәрсәкәйгә//нәмәрсәгә//нийәстәкәйгә һ.б.; күпме, кайа, қайан, қайчан//качан, қайсы, нинди. Мәсәлән: *Нәрсәкәй сөйлиләр, бич йаза барасыз. Нийәстәкәй сора, шуны бирә ул.*

Кайбер торак пунктларда инфинитив *-мак, -ма, -мага* формалары *кирәк* модаль сүзе белән бергә кулланыла: *Төбә ничек буйамақ кирәк, изән бийап күз тондо. Запасқа әпәй алып чықма кирәк.*

Гомумән, йомгаклап, шундый нәтиҗәгә киләбез. Татар теленең һәр диалектында, гомуми кыпчак фоны белән беррәттән, шул диалект өчен генә хас үзенчәлекләрне тәшкил итә торган башка билгеләр дә (болгар, фин-угор, угор (югор), кет, самодий кабиләләре) бар. Һәр диалект үзен формалаштыруда катнашкан төрле этник төркемнәргә бәйле рәвештә, аңа гына хас булган үсеш юлын кичергән. Ләкин татар диалектлары, бер төркем аермалы билгеләре белән бер-берләренә каршы куелуга карамастан, иң беренче чиратта, уртак системалы элементлар нигезендә милли телебезнең аерылгысыз бер өлешен тәшкил итәләр.

Диалектлар системасында күзәтелгән аермалыклар бу диалектларда сөйләшә торган халыкларны бер-берсеннән аермыйлар. Уртак тарихи язмыш, рухи һәм материаль мәдәният телебездә бик күп гасырлар дәвамында барлыкка килгән уртак билгеләр ярдәмендә татар халкының тарихи, тел, рухи һәм мәдәни уртаклыклыгын барлыкка китергән. Хәзерге көндә татарлар аерым этник һәм тел билгеләрен саклаган хәлдә бер халык, бер милләт буларак яшәүләрен дәвам итәләр. Төрле географик киңлекләрдә кавемдәш яки башка гаилә халыклар белән борынгы чорлардан ук аралашып яшәү һәр диалектка, һәр сөйләшкә генә хас булган үзенчәлекләр туугa да сәбәп булган. Татар халкы бу шартларда да туган теленең иминлеген саклап, башка телләрнең, кардәш телме, башка гаилә телеме яки хаким телнең көчле тәэсиренә бирелмичә, безгә – бүгенге көндә яшәүче оныкларына үзенең көчен-гайрәтен, акыл-зирәклеген югалтмый-таратмыйча саклап кала алган.

## ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ЧЫГАНАКЛАР

1. *Арсланова А.А.* Кыпчаки и термин Дашт-и Кыпчак: по данным персидских источников XIII-XVIII вв. // Сборник научных статей и очерков. Т. 1. Ч. 1. – Казань: Ихлас, 2014. – С. 28-47.

2. Атлас татарских народных говоров. Изд. 2-е, доп. и перераб. – Казань: ИЯЛИ, 2015. – 630 с.

3. Атлас татарских народных говоров [Электронный ресурс]. Режим доступа: http://atlas.antat.ru

4. *Ахметзянов М.И.* К этнолингвистическим процессам в бассейне р. Ик по материалам шеджере // Сборник научных статей и очерков. Т. 1. Ч. 1. – Казань: Ихлас, 2014. – С. 170-187.

5. *Бессонов А.Г.* О говорах Казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам // Журнал Министерства народного просвещения. – СПб., 1881. – Ч. CCXVI. – С. 220-242.

6. *Катанов Н.Ф.* Отчет о поездке, совершенной с 20 мая по 20 августа 1898 года в Белебеевский уезд Уфимской губернии // Ученые записки Императорского Казанского университета. – Казань, 1900. – Кн. 7-8. – С. 1-30.

7. *Киекбаев Ж.Г.* Башҡорт диалекттары һәм уларҙың тарихына ҡыҫҡаса инеш // Ғилми язмалар. Башҡортостан дәүләт университеты. III сығарылыш. Башҡорт филология серияһы. № 2. – Өфө, 1958. – Б. 41-78.

8. *Рамазанова Д.Б.* Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. 2-е изд. – Казань: ИЯЛИ, 2020. – 208 с.

9. Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – Б. 839.

10. *Юлдашев А.А.* К изучению говоров башкир Туймазинского района БАССР // Башкирский диалектологический сборник. – Уфа: ИИЯЛ БФАН СССР, 1959. – С. 141.

11. *Юлдашев А.А.* Язык тептярей: дис. ... канд. филол. наук. – М., 1950.

12. *Юсупов Ф.Ю.* Морфология татарского диалектного языка. Категория глагола. – Казан: Фэн, 2004. – 592 с.

# ИЗ ИСТОРИИ ФОРМИРОВАНИЯ ТАТАРСКИХ ГОВОРОВ, РАСПРОСТРАНЕННЫХ В ВОСТОЧНЫХ ОБЛАСТЯХ СОВРЕМЕННОЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН И ЗАПАДНЫХ ОБЛАСТЯХ РЕСПУБЛИКИ БАШКОРТОСТАН (НА ПРИМЕРЕ МЕНЗЕЛИНСКОГО ГОВОРА)

***Хисамов Олег Ришатович,***
*кандидат филологических наук,*
*Институт языка, литературы и*
*искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ,*
*Казань, Россия,*
*ohisamov@mail.ru*

В статье идет речь об этапах формирования мензелинского говора среднего диалекта татарского языка. Затрагиваются также вопросы изучения говора и его основные лингвистические особенности.

***Ключевые слова:*** татарский язык, средний диалект татарского языка, диалектология, татарская диалектология, мензелинский говор.

# FROM THE HISTORY OF THE TATAR SUBDIALECTS DISTRIBUTED IN THE EASTERN PARTS OF THE REPUBLIC OF TATARSTAN AND THE WESTERN PARTS OF THE REPUBLIC OF BASHKORTOSTAN (ON THE EXAMPLE OF THE MENZELINSKY SUBDIALECT)

***Khisamov O.R.,***
*Candidate of Philological sciences,*
*Ibragimov Institute of Language, Literature and Art*
*of the Tatarstan Academy of sciences,*
*Kazan, Russia,*
*ohisamov@mail.ru*

The article deals with the stages of the formation of the Menzelinsky subdialect, the middle dialect of the Tatar language. The issues of the study of the subdialect and its main linguistic features are also addressed.

***Keywords:*** Tatar language, middle dialect of the Tatar language, dialectology, Tatar dialectology, Menzelinsky subdialect.

УДК 81’282

# МИНЗӘЛӘ СӨЙЛӘШЕНЕҢ ФОРМАЛАШУ ҺӘМ ӨЙРӘНЕЛҮ ТАРИХЫ

***Йосыпов Фәрит Йосыф улы,***
*филология фәннәре докторы,*
*Казан, Россия,*
*ferits@yandex.ru*

Сөйләшүчеләрнең саны һәм таралыш территориясенең зурлыгы ягыннан минзәлә сөйләше татар теленең иң зур сөйләшләреннән санала. Хәзерге вакытта аның нигезендә миллион ярымнан артык кеше аралаша. Мәкаләдә минзәлә сөйләшенең формалашу тарихы Россия дәүләт борынгы актлар һәм Башкортстан Республикасы архивларында сакланучы документлар, шулай ук авторның күп санлы экспедицияләр вакытында туплаган материаллары нигезендә тикшерелә.

***Төп төшенчәләр:*** Минзәлә сөйләшенең таралу территориясе, сөйләшнең формалашу тарихы, йомышлы татарлар, мишәрәкләр, яңа башкортлар, типтәрләр.

Татарларның мөстәкыйль халык булып формалашкан туфраклары – Идел һәм Урал буйлары. Бу җирләр халкыбызның бик борынгы гасырлардан бирле тарихи Ватаны булып санала. Төрле фаҗигале язмыш сәбәпләре аркасында дөньяның төрле почмакларына таралырга мәҗбүр булса да, татарларның иң күп өлеше бүгенге көннәрдә дә Урта Идел, Түбән Кама һәм Урал алды географик төбәгендә яши. Моннан тыш татар авыллары Татарстан һәм Башкортстан белән күрше булган милли республикаларда һәм өлкәләрдә тоташ массив булып урнашканнар.

Сөйләшүчеләрнең саны, шулай ук таралыш территориясенең зурлыгы ягыннан минзәлә сөйләше татар теленең иң зур сөйләшләреннән санала. Ул Татарстан Республикасының көнчыгыш (Әгерже, Зәй, Тукай, Минзәлә, Сарман, Мөслим, Актаныш, Әлмәт, Азнакай, Баулы, Бөгелмә), Башкортстан Республикасының көньяк-көнбатыш (Илеш, Дүртөйле, Кушнаренко, Чакмагыш, Благовар, Бүздәк, Чишмә, Бакалы, Шаран, Туймазы, Яңаул, Кал-

тасы, Кызыл Кама (Краснокамск), Ауыргазы, Әлшәй, Бәләбәй, Бишбүләк, Кармаскалы, Мәләүез) районнарында таралган. Бу сөйләш, Татарстанның көнчыгыш, Башкортстанның көньяк-көнбатыш районнарын эченә алып, тоташ территория хасыйл итә.

Сөйләшнең үзенчәлеген тәшкил итә торган билгеләр сөйләш таралган барлык территорияләр өчен дә бер үк дәрәҗәдә хас түгел. Алар нигездә Татарстан һәм Башкортстан Республикаларына чиктәш булган, Агыйдел, Ык, Сөн елгаларының бассейннарында таралган урынчылыкларда күзәтелә. Галимнәрнең фикеренә караганда, Татарстаннан көнчыгыш тарафка киткән саен бу билгеләрнең саны сизелерлек арта, кайбер үзенчәлекләр исә бөтенләй юкка чыга [31, б. 57; 37, б. 6]. Бу, үз чиратында, минзәлә сөйләшенең формалашу үзенчәлеге белән аңлатыла. Билгеле булганча, 1552 елда Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, Казан тирәсендә яшәгән татарларның күпчелеге Кама аръягындагы, аеруча Агыйдел, Ык, Сөн елгалары буйларындагы ул вакытта чагыштырмача халык аз яшәгән җирләргә агыла. Казан ягыннан килгән татарларның саны бу төбәктә гомер сөрүче төрки-татар кабиләләренең санынnан дистәләрчә артып китә. Шул рәвешчә, казан татарларының сөйләше биредә төп аралашу чарасына әйләнә. Казан татарларының сан ягыннан һәм иҗтимагый тормыштагы өстенлеге соңгы гасырларга кадәр дәвам итә. Башкортстанның көньяк-көнбатыш төбәкләрендә, киресенчә, казан татарларының саны ул кадәр үк зур булмый. Татар халкының мәдәни үзәгеннән ераклашкан саен, биредә бик борынгы заманнардан бирле яшәп килгән җирле татар-төрки халыкларының теле, рухи һәм материаль мәдәниятенең җирле төркемнәр тәэсиренә бирелә башлавы үзен сиздерә башлый. Шуның нәтиҗәсендә, вакыт узу белән, биредә яңа формалашып килгән татар сөйләшләренә, шул исәптән минзәлә сөйләшенә һәм халык мәдәниятенең төрле тармакларына җирле үзенчәлекләр үтеп керә башлый, тора-бара татар сөйләшләре таралган төбәкләрнең көнчыгыш чикләрендә башкорт, казах телләре һәм себер татарлары сөйләшләре белән уртак булган билгеләр барлыкка килә. Бу билгеләрнең

кайберләре Татарстанның көнчыгыш, Башкортстанның көнбатыш өлешләрендә таралган сөйләшләрне борынгы, шулай ук хәзерге көнчыгыш төрки телләр белән якынайта. Чөнки, тарихчыларның әйтүләренә караганда, Урал итәкләре бик борынгы заманнардан бирле кешелек цивилизациясе үзәкләренең берсе булып исәпләнә. Бу төбәкләрне II–III гасырларда борынгы хуннар, VIII гасырларда кыпчак кабиләләре үз иткәннәр. Соңрак, кыпчакларның күп өлеше Идел болгарлары яши торган Урта Идел һәм Түбән Кама бассейнына күчеп китсәләр дә, аларның шактый зур өлеше биредә яшәп калган. Бу яклар Идел болгарларының көнчыгыш биләмәләре булып әверелгән. Себер ханлыкларының көнбатыш чикләре Кама һәм Агыйдел буйларына кадәр дәвам иткән. Р.Г. Кузеев Башкортстанның көнбатыш өлеше бик борынгыдан ук болгарлар тарафыннан үзләштерелгән булган дип исәпли [23, б. 23]. Кайбер галимнәр исә Идел Болгарстанының көнчыгыш чикләре Агыйдел һәм Җаек елгаларына кадәр үк барып җиткәннәр дип күрсәтәләр[11]. Н.А. Мәҗитов һәм Ә.Н. Солтановалар да Көнбатыш Башкортстанның шактый өлеше Болгар дәүләте составында булган дип саныйлар [26, б. 246-247]. Хәзерге башкорт тарихчылары да, Болгар дәүләте монголлар тарафыннан җимерелгәч, болгарларның бер өлеше Башкортстанның көнбатыш һәм төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш өлешләренә күчеп утырганнар дип күрсәтәләр [35, б. 32-33]. Галимнәр Урал алды территориясендә борын-борыннан болгар-татар дәүләтләре халкына генетик яктан бик якын торган этник төркемнәр яшәгән дигән нәтиҗә ясыйлар [37, б. 14]. Бу территорияләрдә, күп кенә тарихчыларның әйтүенчә, VIII гасырга кадәр үк Болгар кабиләләре берлегенә кергән яки аларның тәэсирен кичергән халыклар яшәгән[12]. Моннан тыш болгарлар төрле гасырларда зур булмаган төркемнәр

[11] *Шпилевский С.М.* Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губернии. – Казань: Унив. тип., 1877. – С. 159.

[12] Башкирские шежере / Сост. Р.Г. Кузеев. – Уфа: Башкирское кн. изд-во, 1960. – 304 с.; Кузеев Р.Г. Происхождение башкирского народа. – М.: Наука, 1974. – 569 с.

хәлендә Урал һәм Урал артындагы җирләргә дә үтеп кергәннәр. Минзәлә сөйләше вәкилләре яши торган төбәкләрдә яшәгән халыкларның бердәм этнографик төркем буларак оеша башлавы болгар чоры заманында ук башланган дигән фикер дөреслеккә туры килә. Шуның нәтиҗәсендә Идел буе һәм Урал итәкләрендә яшәүче төрки кабиләләрнең берничә гасыр үзара тәэсир итешү дәвамында материаль һәм рухи мәдәниятендә уртак билгеләр барлыкка килгән. Шушы чорда ук бу якта яшәүчеләрнең казан татарлары теленә нигезләнгән җирле сөйләше формалаша башлый [31]. Идел ягыннан килгән болгарлар һәм аларга якын кабиләләр телдә, рухи мәдәниятнең башка тармакларында болгар-татар традицияләрен дәвам итсә, биредә борынгыдан яшәп килгән төрки кабиләләр әлеге сөйләшнең күрше, Урта Азия төркиләре белән уртак булган күренешләрне саклап калуга ярдәм иткән.

Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларында да Көнбатыш Башкортстан туфракларында яшәүче кавемнәр әлеге ханлыкларның сәяси, икътисадый, мәдәни йогынтысы астында кала бирә. Башкортстан гына түгел, Себер ханлыгының Урал төбәгендәге җирләре дә XX гасыр башына кадәр татар икътисадый мәнфәгатенең әһәмиятле үзәкләренең берсе булуын дәвам итә.

Минзәлә сөйләшенең формалашуында, Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, казан татарларының күпләп бу якларга күчеп килүе җирле халыкның материаль, рухи мәдәнияте нигезен барлыкка китерүдә хәлиткеч роль уйнаган дип әйтергә тулы нигез бар. Шуның нәтиҗәсендә булса кирәк, казан арты сөйләшләре өчен хас булган төп билгеләр минзәлә сөйләшенең нигезен тәшкил итә торган үзенчәлекләр системасы буларак формалаша. Шуңа да игътибар итәргә кирәк: казан арты һәм минзәлә сөйләшләре белән уртак булган кайбер үзенчәлекләр соңгы елларда, әдәби телнең көчле йогынтысына карамастан, бүгенге көнгә кадәр актив кулланылуын дәвам итә (мәсәлән, тел-теш [d] тартыгын ([д] тартыгына якын булган тартык аваз) куллану һ. б.).

Минзәлә сөйләше, берничә гасыр үзгә шартларда үсүенә карамастан, Казан ханлыгы чорында нигез сөйләш булып формалаш-

кан казан арты сөйләшләренең төп билгеләрен саклап кала алган. Моңа, безнең фикеребезчә, биредә яшәүче төрле төрки төркемнәр арасында казан татарларының сан ягыннан күп булуы гына түгел, бәлки аларның икътисадый, материаль һәм рухи мәдәниятләре ягыннан да өстен булуы ярдәм иткән дип уйларга кирәк. Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, Урал итәкләренә күчеп килгән татарларның биредәге башкортлар белән биш гасырга якын аралашып яшәүләренә карамастан, минзәлә сөйләшенә башкорт теле өчен генә хас булган үзенчәлекле билгеләр үтеп керә алмаган. Беренче чиратта, борынгы һәм гомуми төрки телдәге саңгырау тел очы өрелмәле [с] тартыгын фарингаль [һ] авазы белән алмаштыру (минзәлә сөйләшендә: *сарық* – башк. *һарык*, *сөт – һөт, сап – һап, сары – һары* һ. б.; борынгы һәм гомуми төрки телдәге аффриката (татар әдәби теле һәм урта диалектның күпчелек сөйләшләрендә – беркатлы, өрелмәле [ч] тартыгының тел очы өрелмәле [с] авазы белән тәңгәлләштерү (минзәлә сөйләшендә: *чибәр* – башк. *сибәр, чебен – себен, чалғы – салғы, чалбар – салбар* һ. б.), шулай ук тартык авазлар өчен башкорт теленә хас булган ассимиляция һәм диссимиляция күренешләре дә минзәлә сөйләше өчен хас түгел (минзәлә сөйләшендә: *қошлар* – башк. *коштар, ташлар – таштар, қойашны – кояшты, қартны – картты, қызлар – кыззар, айны – айзы, баладан – баланнан, арбадан – арбадан* һ. б.

XVI–XX гасырларда әдәбиятта «башкорт җирләре» дип аталып йөргән туфракларга күчеп килгән татарларны архив материалларында, тарихи әдәбиятта ул заманнарда ***ясаклы татарлар, казан татарлары, казан кешеләре, типтәрләр, йомышлы татарлар, мишәрләр, мишәрәкләр, башкортлар, яңа башкортлар*** дип атап йөрткәннәр. Шушы чуар этник төркемнәрнең нигезен казан татарлары тәшкил итүе күпчелек галимнәрдә шик уятмый. Без өйрәнә торган территориядә яшәүче татарлар архив материалларында күпчелек очракта типтәрләр, йомышлы татарлар, ясаклы татарлар дип аталып йөртелгәннәр. Без бу мәкаләбездә нигездә шушы төркемнәр турында сүз алып барачакбыз.

Башкорт җирләренә үзәк өлкәләрдән күчеп утырган халыкның иң зур төркемен типтәрләр тәшкил иткән. Типтәрләрнең килеп

чыгышы турында тарихи әдәбиятта бик күп фикерләр яшәп килә. Бер төркем тарихчылар типтәрләрне Идел буйларыннан күчеп килгән татарлар һәм җирле башкортлар белән кушылудан килеп чыккан этник төркем дип исәпли [20]. Соңрак бу терминның этнос атамасы түгел, бәлки башкорт җирләрендәге авыл халкының социаль катламын аңлатуы ачыклана [39]. Соңгы хезмәтләрдә типтәрләр этник үзенчәлекләргә ия булган социаль катлам дип карала [16]. Архив документларында һәм тарихи материалларда типтәр катламына татарлардан тыш мари, удмурт, чувашларның да кертелгәнлеге күренә. Типтәрләрне өйрәнүче галимнәр аларның тормыш-көнкүреш ягыннан казан татарларыннан аерылмаулары һәм сөйләшләре татар теленә бик якын булулары турында әйтәләр[13]. 1939, 1959, 1970, 1979 елгы халык санын алу вакытында бу төбәкләрдә яшәгән типтәрләр үзләрен татарлар дип күрсәткәннәр[14].

Типтәр тарихы белән шөгыльләнүче галимнәр бу социаль-этник төркемнең, XVI гасырдан башлап, Башкортстан территориясенә күчеп килгән төркемнәрдән оешкан дип исәпли. Башкортстан Рус дәүләтенә кушылганнан соң, андагы җирләр дәүләт карамагына күчә, дәүләт бу җирләрне, башка кешеләргә сатмау һәм аннан кулланган өчен ясак түләү шарты белән җирле башкорт кабиләләренә, шулай ук моңа кадәр бу җирләргә килеп төпләнеп, бу төбәкнең үз халкы булып өлгергән башка төркемнәргә дә рәсми рәвештә теркәп куя. Шулай да «вотчина» дип аталган

[13] *Бессонов А*. О говорах казанско-татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам // Журнал Министерства народного просвещения. СПб. – 1881. – Ч. CCXVI. – С. 200-242; Катанов Н.Ф. Отчет о поездке, совершенной с 20 мая по 20 августа 1898 года в Белебеевский уезд Уфимской губернии // Ученые записки Императорского Казанского университета. – Казань, 1900. – Кн. 7-8. – С. 1-30; Катанов Н.Ф. Опыт исследования урянхайского языка с указанием главнейших родственных отношений его к другим языкам тюркского корня: монография. Т. 2. – Казань: Типо-литография Императорского Университета, 1903. – 538 с.

[14] *Исхаков Д.М.* О некоторых аспектах проблемы места Приуральских татар в этнической структуре татарской нации // Приуральские татары. – Казань, 1990. – С. 4-12.

бу җирләрне читтән күчеп килгән җирсез халыкка арендага бирергә рөхсәт итә. Рәсми документларда, Урал төбәкләренә күчеп килеп, типтәр атамасы астында йөргән татарларның башкорт җирләренә төрле характердагы антлашмалар нигезендә, гадәттә җир хуҗаларының рус хакимиятенә булган ясакларын түләп тору шарты белән, урнашулары күренә. С.М. Васильев башкорт җирләренә антлашма нигезендә утырган һәркем типтәр исеме белән аталган дип аңлата [12]. Әлеге антлашмалар телдән генә дә, язма рәвештә дә төзелгәннәр. Башкорт җирләренә төрле антлашмалар нигезендә утыру бигрәк тә көнбатыш төбәкләр өчен хас булган. Башкортстандагы җирле һәм килгән халыклар белән мондый мөнәсәбәтләр XX гасыр башларына кадәр дәвам иткән.

**Йомышлы татарлар**. Татарларның, XVI гасырдан башлап, Башкортстан һәм Урал төбәкләренә күчеп утырулары һәр очракта да стихияле рәвештә генә дәвам итмәгән. Бу процессны туктату чарасын таба алмаган патша хөкүмәте, бу хәрәкәткә икенче бер юнәлеш биреп, аны колониаль сәясәтенә туры китереп, рәсми рәвештә алып барырга ниятли. Билгеле булганча, Казан ханлыгы Рус дәүләтенә кушылгач, империянең көнчыгыш чикләрен башкорт һәм кыргыз-кайсак (сүз хәзерге казахлар турында бара) һөҗүмнәреннән саклау ихтыяҗы туа. Шул сәбәп белән 1578 елда Минзәлә, Бөре (Бирск), Уфа шәһәрләре төзелә башлый. Рус хөкүмәте бу шәһәрләргә һәм алар тирәсенә, руслардан тыш, хәлиткеч заманнарда үзләренә тугрылыклы булып калган йомышлы татарларны урнаштыра. Аларның бер өлешенә шушы крепостьлар тирәсендәге буш җирләр дә бүлеп бирелә. Шулай итеп, элекке Казан ханлыгы һәм кәгазьдә генә рус дәүләтенә «ирекле» кушылган башкорт җирләре арасында беренче ныгытылган чик буе линияләре барлыкка килә. Соңыннан Башкортстанда булып торган төрле баш күтәрүләр бу ныгытмаларның колониаль рус дәүләте өчен ни дәрәҗәдә бик тә вакытлы һәм бик тә кирәкле булуларын ничәмә-ничә кат исбат иттеләр. Вакыт узу белән бу линияләр, әкренләп, Башкортстанның үзәк өлешләренә, хәтта XVIII гасыр азакларында Чиләбе һәм Курган өлкәләре белән чиктәш булган казах далаларына кадәр барып җитә.

Йомышлы татарларның күпчелеге рус дәүләте химаясында (протекторатында) берничә гасыр яшәгән мишәрләрдән торганлыктан, шул заманга караган документларда аларны ***мишәр, мишәрәк*** атамалары белән аталып йөртелүләре архив материалларында һәм күп санлы экспедицияләр вакытында язып алынган легендаларда чагылыш таба. Мишәрләрнең бу якларга, югарыда әйтеп узганыбызча, Уфа һәм Минзәлә шәһәрләре һәм дәүләт чикләрен күчмә халыкларның һөҗүмнәреннән саклау өчен рус императорының указы нигезендә Казан ягыннан күчереп утыртылганнары турында сөйләнә[15].

Татар-мишәрләр турында сүз барганда, тагын бер әһәмиятле фактка игътибар итәргә кирәк. Билгеле булганча, элек рус армиясендә татарлардан бары тик мишәрләр генә хезмәт иткән. Соңга таба бу эшкә Оренбург губернасындагы Себергә һәм Казахстанга якын булган чик буйларында яшәүче бүтән татарлар да тартыла башлый. Тора-бара көнчыгыш өлкәләрдә яшәүче хәрби сословиегә кертелгән күп кенә башка татарларны да мишәрләр дип атау гадәткә кереп китә.

П.И. Кеппен дә, шушы чор халыкларының тарихы турында сүз барганда, йомышлы татарларны мишәрләр дип атау кабул ителгәнлеген әйтә. Ул шушы уңай белән бер указдан өзек китерә: «В Уфимском уезде обитают служилые татары, называемые мещеряками» [20, с. 363; 27, с. 492]. Йомышлы татар-мишәрләр башкортларның вотчина дип аталган (дәүләтнең гомерлеккә файдаланырга биргән) җирләрендә яшәгәннәр, аннан файдаланган өчен аларга оброк түләгәннәр. Ләкин 1736 елның 11 январь указы нигезендә 1735 елгы башкорт восстаниеләрен бастыруда актив катнашканнары өчен алар оброктан, ә 1754 елда барлык түләүләрдән дә азат ителәләр. 1797 елда бу җирләрдәге мишәрләр Оренбург хәрби идарә карамагына кертеләләр һәм башкорт авыллары белән бергә кантоннарга бүленәләр. Шушы хәлләрдән башлап, йомышлы мишәрләрнең административ һәм социаль шартлары башкортлар белән тиңләштерелә. Шулай да

[15] ЦГА БР. Ф. 2. оп. 1, ед. хр. 67.

башкортларның электән килгән «җир хуҗалары» дигән мактаулы атлары башкорт булмаган халыкларны үзенә тартып торган. Шунлыктан, җае чыгу белән, һәр этник төркем башкорт булып язылырга хыялланган. Рус хөкүмәте, мишәрләрне социаль хокуклары белән башкортлар белән тиңләштерүгә карамастан, мишәрләр арасында да башкорт сословиесенә күчәргә теләүчеләр шактый күп булган. Шушы сәбәпләр нәтиҗәсендә хәзерге Татарстан Республикасының көнчыгыш, Башкортстанның көнбатыш төбәкләрендә яшәгән йомышлы мишәрләрнең күпчелеге рәсми кәгазьләрдә башкорт булып күрсәтелә башлыйлар.

Бу яклардагы йомышлы мишәрләрнең төгәл саны беркайчан да билгеле булмаган, чөнки ул ел саен Идел ягыннан килгән йомышлы татарлар һәм бу социаль катламга үз теләге белән күчкән ясаклы татарлар хисабына арта барган[16].

1797 елдан башлап йомышлы мишәрләр, Оренбург хәрби идарәсе карамагына кертелеп, төрле кантоннарга бүленәләр һәм аларның төп хокуклары башкортлар белән тигезләнә.

Оренбург губернасы төзелә башлау белән, рус хөкүмәте бу якларга татарларга күчеп утырырга рөхсәт бирүче кайбер документлар кабул итә. 1736 елгы указ нигезендә башкорт восстаниеләре вакытында рус хөкүмәтенә тугрылык күрсәткән йомышлы татарларның, типтәрләр һәм бобыльләрнең башкортлардан алып торган җирләре гомерлеккә үзләренә бирелә. Моннан тыш аларга баш күтәргән башкортларның җирләрен сатып алырга рөхсәт тә ителә.

1840 елгы «О военном управлении Башкирско-Мещерякским войском» дигән положение буенча, бу территориядә яшәүче халыкларның барлык эшләре белән җитәкчелек итү шушы гаскәр идарәсенә тапшырыла. 1855 елда Башкорт-Мишәр гаскәренә Уфа һәм Оренбург губерналарында яшәгән барлык типтәрләр, бобыльләр кабул ителә һәм бу административ берәмлек Башкорт гаскәре дип аталып йөртелә башлый. Бу авыллардагы татарлар, типтәрләр, ясаклы татарлар рәсми кәгазьләрдә баш-

[16] ЦГА БР. Ф. 138, оп. 2, ед. хр. 22, 87, 97. ЦГАДА. Ф. 45, оп. 2, ед. хр. 74, 16.

корт дип күрсәтелә башлый. Элеккеге ыруглык, этник билгеләр нигезендә төзелгән административ бүленеш бозыла. Бер үк кантон һәм волостьларга башкорт, мишәр, типтәрләр, ясаклы татарлар да кертелә. Электән үк башкортларга гына бирелгән кайбер өстенлеккә өмет иткән татарлар һәм типтәрләр үзләрен башкорт дип язуга ирешә.

Административ системадагы үзгәрешләр XIX гасыр урталарында башкорт восстаниеләрен булдырмауны күздә тотып төзелгән кантоннарны бетерү белән тәмамлана. Икенчедән, рус дәүләтенә кушылганнан соң, Уфа провинциясе һәм Оренбург губернасы территорияләре чик буе өлкәләре булудан туктый. Шулай итеп, хәзерге вакытта минзәлә сөйләше вәкилләре яшәгән Уфа провинциясенең көнбатыш һәм үзәк өлкәләрендә мишәр кантоннары тотуга ихтыяҗ бетә. Шунлыктан кайбер мишәр һәм башкорт кантоннары, казак сословиесеннән чыгарылып, ясакка кертеләләр.

Югарыда сөйләгәннәрдән күренгәнчә, мишәр термины, хәзер этнография фәнендә кабул ителгәнчә, этник төркемне генә билдереп калмаган, бәлки хәрби хезмәт (казак хезмәте) алып баручы татарларга карата да кулланылган булуы аңлашыла.

* * *

Хәзерге көндә Татарстанның көнчыгыш, Башкортстанның көнбатыш өлешләрендә гомер-гомергә яшәп килгән миллион ярымнан артык кеше буыннан-буынга үзенең ана телен татар теле дип санап килә. Үткән гасырның алтмышынчы елларына кадәр бу төбәктә уку-укыту, административ идарә итү эшләре, кагыйдә буларак, татар телендә алып барылды. Халык санын алу вакытында халык туган телен татар теле, үзен милләт буларак татар дип атап килде.

Иске административ бүленеш буенча биредә яшәгән татарлар төрле чорларда Казан, Уфа провинциясе, өлешчә Оренбург губернасы составында булып, Минзәлә, Бәләбәй, Өфе өязләренә караганнар. 1920 елда оештырылган Башкорт автономияле социалистик республикасы төзелү белән, бу җирләрдә борынгыдан

ук яшәп килгән татарлар ике дәүләт чикләре арасында бүленеп калдылар. Күп гасырлар Казан губернасы чикләрендә бердәм икътисад, тел, рухи мәдәният уртаклыгында яшәгән халыкның берлегенә зур зыян килде. Шушы көннән башлап, Урта Идел, Түбән Кама, Урал итәкләрендә күп гасырлар буе уртак язмыш кичергән халык ясалма тудырылган шартларда яши башлады. Татар халкының иҗтимагый тормышына көчләп башкорт теле кертелде. XX гасырның урталарыннан башлап, мәктәпләрдән, мәктәпкәчә балалар, мәдәният оешмаларында татар теле кысырыклап чыгарыла, аның урынына көчләп башкорт теле укытыла башлый. Татар әдәбиятының, мәдәниятенең тәэсире бик нык кими башлый. Шулай булуга да карамастан, татар халкы үз телен, үз сөйләшен саклап калу һәм аны киләчәк буыннарга җиткерү юлында каһарманнарча көрәш алып бара.

Минзәлә сөйләше татар теленең иң күп өйрәнелгән сөйләшләреннән санала. Төрле гасырларда иҗат иткән галимнәр бертавыштан сөйләшнең фонетик, грамматик төзелеше, төп лексик байлыгы ягыннан татар әдәби теленә бик якын торган, аны тагын да баетуга зур өлеш керткән сөйләш итеп саныйлар[17].

[17] Мәсәлән, кара: *Бессонов А.* О говорах казанско-татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам // Журнал Министерства народного просвещения. СПб. – 1881. – Ч. CCXVI. – С. 200-242; *Катанов Н.Ф.* Отчет о поездке, совершенной с 20 мая по 20 августа 1898 года в Белебеевский уезд Уфимской губернии // Ученые записки Императорского Казанского университета. – Казань, 1900. – Кн. 7-8. – С. 1-30; *Җәләй Л.Җ.* Татар диалектологиясе. – Казан: Татгосиздат, 1947. – 136 б.; *Залялетдинов Л.З.* Средний диалект татарского языка. – М., 1954. – 24 с.; *Юлдашев А.А.* Язык тептярей: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – М., 1950. – 16 с.; *Махмутова Л.Т.* О татарских говорах северо-западных районов Башкирской АССР // Материалы по татарской диалектологии. – Казань, 1962; *Афлетунов А.Ш.* Языковые особенности татар западной и юго-западной части БАССР: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1961; *Алмаз Җ.* Башкортстанның Дүртөйле һәм Илеш районнары татарларының сөйләшенә карата // Татар теле һәм диалектологиясе мәсьәләләре. – Казан, 1959. – 145-165 б.; *Рамазанова Д.Б.* Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – 191 с.; *Баязитова Ф.С.* Мензелинский говор татарского языка // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 7. – Казань, 1989. – С. 67-83 һ.б.

Минзәлә сөйләшенең хәзерге татар әдәби теленә нигез булып торган урта диалект сөйләшләренә якынлыгы турында аеруча басым ясап әйтергә кирәк. Казан ханлыгы территориясеннән бу якларга күчеп килгән татарлар татар сөйләшләренә хас булган төп билгеләрне саклап калганнар. Урал төбәкләрендә XVI гасырдан соң барлыкка килгән татар сөйләшләре дә бу уртак хәзинәгә тугрылыклы булып калалар. Яңа шартларда барлыкка килгән үзенчәлекләрнең күбесе шулай ук бу төбәктә таралган барлык татар сөйләшләре өчен уртак күренешләр итеп каралалар. Чөнки алар уртак тарихи, мәдәни, социаль, икътисадый шартларда барлыкка килгәннәр.

Урал итәкләрендә таралган татар сөйләшләре турында беренче фәнни мәгълүматларны татар диалектологиясе фәненә нигез салган рус галиме А.Г. Бессонов язып калдыра. Ул үзенең 1881 елда Санкт-Петербургта басылып чыккан «О говорах казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам» дигән хезмәтендә Урал төбәкләрендә таралган типтәр сөйләшләрен казан татарлары шивәсенә иң якын торган сөйләшләр дип белдерә. Бу Башкортстан территориясендәге татар сөйләшләренең казан татарлары теленә якынлыгын фәнни дәлилләгән беренче хезмәт була. Ул ислам динендәге типтәрләрнең сөйләшен беркадәр дәрәҗәдә генә башкорт һәм мишәр сөйләшләренең йогынтысына бирелгән татар сөйләше дип исбатлый. Галимнең бу фикерләре безнең һәм башка тикшеренүчеләрнең материаллары белән дә раслана. XX гасыр азагында алып барылган тикшеренүләрдән күренгәнчә, А.Г. Бесссонов бу сөйләшләргә башкорт теленең йогынтысын конкрет дәлилләр китереп исбатламый. Алай гына да түгел, бу төбәктәге татар сөйләшләрен башкорт сөйләшләре итеп карарга тырышкан башкорт телчеләреннән аермалы буларак, тел очы йомык (кайбер галимнәрнең күзәтүенчә теш-ара) [d] тартыгының сөйләштә [з] авазы урынына кулланылуына да игътибар итми. Ул бу авазны бик хаклы рәвештә йомык [д] тартыгы белән тиңли. Дөрестән дә, әлеге аваз үзенең ясалу хосусияте ягыннан башкорт телендәге теш-ара «сакау» [з] тартыгыннан аерылып тора.

Соңрак А.Г. Бессоновның бу фикере башка галимнәр тарафыннан да раслана[18].

А.Г. Бессоновның бу төбәкләрдә таралган типтәр сөйләшләренең казан татарлары шивәсенә (хәзерге терминология буенча татар теленең урта диалектына) якын торуын [а] сузыгының нык иренләштереп әйтелүе белән дә раслый. Моннан тыш галим мишәр сөйләшләренең дә, беренче чиратта, казан татарлары шивәсенә якын торуы турында әйтә. А.Г. Бессоновның Урал итәкләрендә яшәүче татарларның, аерым алганда, минзәлә сөйләше турында әйткән фикерләре үзенең фәнни әһәмиятен бүгенгә кадәр дә югалтмаганнар. Иң әһәмиятлесе – бу яклардагы татар сөйләшләренең татар теленә бик якын булуы соңгы елларда башкарылган фәнни тикшеренүләр белән дә расланып киләләр.

Урал итәкләрендә таралган татар сөйләшләренең казан татарлары теленә якын торуы төрки телләр белгече мәшһүр Н.Ф. Катанов тарафыннан да әйтелә. Ул 1898 елда Бәләбәй өязенең мишәр, башкорт, типтәр, керәшен татарлары яшәгән авылларында булып, аларның тел үзенчәлекләрен өйрәнә. Бу авылларда яшәүчеләрнең теле керәшен татарлары теленә, ягъни казан татарлары теленә якын торуы турында әйтә. Н.Ф. Катанов та, А.Г. Бессонов кебек үк, бу сөйләшләрдә башкорт теле өчен хас булган теш-ара «сакау» [з], [с] тартыклары булуы турында бер сүз әйтми. Димәк галим бу авазны йомык [д] тартыгыннан аермый. Башкорт автономияле социалистик республикасы корылганнан соң, башкорт телен рәсми булдыру, аның нигез сөйләшләрен барлау максатында үткәрелгән күп санлы лингвистик экспедицияләр дә Башкортстанның көньяк-көнбатыш өлешендә яшәүчеләрнең теле татар теленә бик якын тора дигән нәтиҗәләр ясый.

---

[18] Мәсәлән, кара: Җәләй Л. Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. – Казан: Таткнигоиздат, 1954; Афлетунов А.Ш. Из методики проведения наблюдений над говорами среднего диалекта татарского языка (на материале диалектологических экспедиций Казанского университета 1954-56 гг.) // Тезисы докладов II регионального совещания. – Казань, 1958; Юсупов Ф.Ю. Сафакүл татарлары. Тарих, тел, халык иҗаты. – Казан, 2006.

Урал итәкләренең Татарстан Респуликасына кергән өлешендә яшәүчеләрнең сөйләшен, татар диалектологларыннан беренче булып, күренекле тел галиме Латыйф ага Җәләй (Җәләлетдинов) өйрәнә башлады. 1947 елда басылып чыккан «Татар диалектологиясе» дигән югары уку йортлары өчен язылган дәреслегендә бу сөйләш **«минзәлә сөйләше»** дигән исем астында карала. Татар диалектологиясенең беренче адымнары гына ясалган вакытта ук, автор бу сөйләшне татар теленең иң зур сөйләше дип атый. Ул минзәлә сөйләшенең казан арты сөйләшләре белән булган уртаклыгына да игътибар итә. Бу, беренче чиратта, әлеге сөйләшләрдә тел очы, йомык [d] тартыгының булуы, д < d тәңгәллегенә карый. Бу күренешнең таралышын галим ни өчендер көнчыгыштан (Минзәлә ягыннан) көнбатыш юнәлештә күзәтә. Әлеге тел үзенчәлекләренең татарларның баштан көнбатышка, аннан соң гына көнчыгышка таба булган миграция процессларында барлыкка килгәнен аңлау өчен ул вакытта тарихи һәм архив материаллары җитәрлек булмаган, күрәсең. Сөйләшнең фонетик, грамматик, лексик билгеләрен анализлап, автор аның урта диалект составында мөстәкыйль сөйләш булырга хаклы икәнен дәлилли. Минзәлә сөйләшенә хас булган үзенчәлекләр галимнең 1954 елда «Татар теленең урта диалекты» дигән темага якланган докторлык диссертациясендә дә шактый тәфсилле итеп тикшерелә. Ләкин, бу якта яшәүчеләрнең сөйләше ул вакытта җитәрлек өйрәнелмәгәнгә күрә, ул минзәлә сөйләшенең таралыш чикләрен төгәл итеп билгели алмый. Л. Җәләй фикеренчә, минзәлә сөйләше Минзәлә һәм аңа күрше булган районнарда гына таралган дип карала.

XX гасырның икенче яртысыннан башлап, минзәлә сөйләшенең Башкортстан республикасы территориясендә таралган өлешләре дә өйрәнелә башлый. Бу эшкә беренче булып күренекле тел галиме, атаклы башкорт теле белгече Әхнәф Әхмәт улы Юлдашев алына. Ул үзенең 1950 елда якланган «Типтәр сөйләшләре («Язык типтярей») дигән кандидатлык диссертациясендә Башкортстанның көнбатыш районнарында таралган татар сөйләшләрен анализлауга да шактый урын бирә. Биредә ул Учалы районында таралган типтәр сөйләшен Бәләбәй, Бүздәк, Туймазы, Бакалы, Шаран

районнарында яшәүче татарларның тел үзенчәлекләре белән чагыштырып өйрәнә[19].

Ә.Ә. Юлдашев, тел материалларын анализлаганда, тарихи чыганакларны да оста куллана. Автор фикеренчә, күпчелек очракта типтәрләр дип башкорт җирләренә күчеп килгән, үз җирләре булмаган казан татарларын атап йөрткәннәр. Ул типтәрләрнең башкорт җирләрендә кайчан һәм нинди сәбәпләр белән күчеп килүләрен, бу сөйләшләрнең, беренче чиратта, башкорт теле белән чагыштырганда, татар әдәби теле һәм татар сөйләшләренә якын торуын ышанычлы дәлилләр белән исбатлап күрсәтә. Ул, башкорт галимнәреннән аермалы буларак, типтәр атамасының этник билгедән бигрәк, сыйнфый-социаль катламны белдергәнен аңлата. Типтәрләрнең бердәм этник берлек, телләренең бердәм сөйләш була алмавының төп сәбәбе итеп, Ә.Ә. Юлдашев Идел буе өлкәләреннән чыккан татарларның берничә гасыр буенча Башкортстандагы татарлар составына агылып торуын атый[20]. Авторның Башкортстанда таралган татар (типтәр) сөйләшләренең нигездә бер-берләренә якын булулары турындагы фикерләре дә зур әһәмияткә ия. Бу татар диалектологларының узган гасырның 60-80 нче елларында уздырылган тикшеренүләре белән дә расланды.

Башкортстандагы татар сөйләшләрен өйрәнүдә күренекле татар диалектологы Л.Т. Мәхмүтованың роле зур булды. Ул 1954-1957 елларда Башкортстанның көнбатыш районнарына оештырылган диалектологик экспедицияләр белән җитәкчелек итте. Шушы материаллар нигезендә ул минзәлә һәм бөре сөйләшләре турында фәнни мәкаләләр язып бастырды [31, б. 57-86]. Ул, татар телчеләреннән беренчеләрдән булып, тарихи Башкортстан җирләренә мөнәсәбәттә кулланылган башкорт, типтәр, мишәр терминнарының этник мәгънә белдерүдән бигрәк, социаль терминнар буларак кулланылуына игътибар итте. Башкортстанның

[19] *Юлдашев А.А.* Язык тептярей: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – М., 1950. – 16 с.

[20] *Юлдашев А.А.* Язык тептярей: дис. ... канд. филол. наук. М., 1950. – С. 246.

көнбатыш районнарында яшәгән татарларның сөйләшләрен өйрәнгәндә, галимәнең бу фикерләре дөрес фәнни нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирде. Соңыннан Башкортстанда татар сөйләшләре өйрәнү буенча Л.Т. Мәхмүтова тарафыннан башлап җибәрелгән эшне аның укучылары дәвам итте.

Башкортстанда татар сөйләшләрен, аерым алганда минзәлә сөйләшен өйрәнүгә Казан дәүләт университеты галимнәре дә өлеш керттеләр. Студентларның диалектологик практикасына җитәкчелек итү барышында 1956 елда Җ. Алмаз тарафыннан Илеш һәм Дүртөйле районнарында яшәүче татарларның тел үзенчәлекләре өйрәнелеп, «Башкортстанның Дүртөйле һәм Илеш районнары татарларының сөйләшенә карата» дигән мәкаләсендә яктыртыла[21]. Галим татар диалектологиясендә бу төбәктә яшәүчеләрнең сөйләше буенча кызыклы гына күзәтүләр ясый, бай лингвистик материал китерә. Ул да, халык арасында сакланып калган күп кенә легендаларга таянып, башкорт һәм типтәр терминнарының, беренче чиратта, җиргә мөнәсәбәттә булган социаль катламны белдерүен әйтә.

1954-1956 елларда әлеге территориядә яшәүчеләрнең тел үзенчәлекләре Казан дәүләт университеты укытучысы Ә.Ш. Әфләтүнов тарафыннан да өйрәнелә. Ул, бу якта яшәүчеләрнең тел үзенчәлекләрен татар теленең башка сөйләшләре белән чагыштырып, кандидатлык диссертациясе яклый. Галим Башкортстанның көнбатышында яшәүчеләрнең телен татар әдәби теленә һәм күрше татар сөйләшләренә бик якын тора дип исәпли. Ә.Ш. Әфләтүнов фикеренчә дә, биредәге татарларны кайбер язмаларда һәм халык санын алу кенәгәләрендә башкорт, типтәр дип әйтү аларның сыйнфый-социаль катлам билгеләреннән чыгып бирелгән дип исәпли.

XX гасырның 60 нчы елларыннан башлап СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы галимнәре Татарстанның

[21] *Алмаз Җ*. Башкортстанның Дүртөйле һәм Илеш районнары татарларының сөйләшенә карата // Татар теле һәм диалектологиясе мәсьәләләре. – Казан, 1959. – б. 145-165.

көнчыгыш, Башкортстанның көнбатыш районнарында яшәүче татарларның тел үзенчәлекләрен татар теленең Диалектологик атласын төзү максатында махсус программа нигезендә өйрәнүгә кереште. Шушы эш барышында Ф.Ю. Юсупов, Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова әлеге географик зонада яшәүче татарларның сөйләшләре, татар авылларының тарихы, халык авыз иҗаты буенча бай фактик материал тупладылар.

Ф.С. Баязитованың «Татар теленең Түбән Кама тирәсендә таралган сөйләшләре», шулай ук Д.Б. Рамазанованың «Татар теленең Урта Кама тирәсендә таралган сөйләшләре» дигән темаларга якланган кандидатлык диссертацияләре минзәлә сөйләшенең аерым урынчылыкларын яктыртуга багышланды. Д.Б. Рамазанова Татарстанның Әгерҗе, Удмурт Республикасының күрше авылларында таралган татар сөйләшләрен минзәлә сөйләшенең бер өлеше итеп карый.

Ф.С. Баязитова, Татарстанның Алабуга, Чаллы, Актаныш, Сарман, Минзәлә, Әлмәт, Бөгелмә, Мөслим районнары, Башкортстанның Бакалы, Чакмагыш, Илеш, Шаран районнарындагы татар авылларының сөйләш үзенчәлекләрен өйрәнеп, «Татар теленең минзәлә сөйләше» дигән мәкаләсен бастырып чыгарды. Урал итәкләренең киң территориясендә таралган татар сөйләшләре буенча махсус сораулык буенча тупланган бай материал нигезендә ул минзәлә сөйләшенең көнбатыш һәм көнчыгыш чикләрен билгели һәм, аннан алдагы тикшерүчеләрнең фикерен раслап, бу сөйләшнең барлык территориядә дә нигездә бер төрле икәнлеген әйтә. Мәкалә авторы билдергәнчә, минзәлә сөйләше көнбатыш чикләрендә урта диалектның мамадыш, көнчыгышта бөре сөйләшләренең кайбер үзенчәлекләре белән баетыла.

Ф.Ю. Юсупов 1967, 1968, 1969, 1970 елларда Татарстанның Актаныш, Зәй, Минзәлә, Башкортстан Республикасының Илеш, Дүртиле, Чакмагыш, Благавар, Бүздәк районнарында яшәүчеләрнең тел үзенчәлекләре, татар авылларының тарихы, халык авыз иҗаты буенча бай материал туплады, аларны үзенең күп санлы хезмәтләрендә бу татарларның тарихын, сөйләшләренең формалашу этапларын яктыртканда файдаланды. Сөйләштә кул-

ланыла торган аерым күренешләрне гомумиләштерү, сөйләшне мөмкин кадәр тулырак яктырту максатында, башка авторларның күзәтүләре дә искә алынды.

Күп еллар буенча алып барылган эзләнүләр нәтиҗәсендә, әлеге төбәктә яшәүче татар һәм типтәр сөйләшләре татар теленең аерылгысыз бер сөйләше – күп гасырлар дәвамында төрле сәяси-икътисадый шартларда, төрле этник төркемнәрнең үзара мөнәсәбәтләре нәтиҗәсендә формалашкан мөстәкыйль татар сөйләше икәне исбат ителде.

## ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ЧЫГАНАКЛАР


1. *Асфандияров А.С.* Башкирия в период кантонного управления (1798-1865): дис. ... канд. ист. наук. – Уфа, 1969.
2. *Асфандияров А.С.* История сел и деревень Башкортостана. – Уфа: Китап, 1997.
3. *Афлетунов А.Ш.* Языковые особенности татар западной и юго-западной части БАССР: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1961.
4. *Әфләтүнов Ә.Ш.* БАССРның көньяк-көнбатыш өлешендә яшәүче татар сөйләшләренең тел үзенчәлекләре: дис. ... канд. филол. наук. – Казан, 1961.
5. *Баева Н.Х.* Говор башкир долины реки Ай. Фонетика и морфология // Башкирский диалектологический сборник. – Уфа, 1959.
6. *Баязитова Ф.С.* Түбән Кама тирәсендәге керәшен татарлары сөйләшенең фонетик һәм грамматик үзенчәлекләре // Материалы по татарской диалектологии. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1974.
7. *Баязитова Ф.С.* Татар теленең Түбән Кама тирәсендә таралган сөйләшләре: дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1973.
8. *Борһанова Н.Б.* Казан арты керәшен сөйләшләрен төп билгеләре буенча төркемләү // Татар теле һәм әдәбияты. Алтынчы китап. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977.
9. *Бурганова Н.Б.* Особенности говора татар нагорной стороны ТАССР // Материалы по татарской диалектологии. – Казань, 1955.
10. *Бурганова Н.Б.* Говор каринских и глазовских татар // Материалы по татарской диалектологии. – Казань, 1962.
11. *Бурганова Н.Б.* О некоторых архаичных формах глагола в заказанских говорах // Тезисы докладов итоговой научной сессии за 1970 г. ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФАН СССР. – Казань, 1971.

12. *Васильев С.М.* Припущенники на башкирских землях в I половине XVIII в. (тептяро-бобыльское население Башкирии): дис. ... канд. ист. наук. – М., 1950.

13. *Залялетдинов Л.* Средний диалект татарского языка: автореф. дис. … докт. филол. наук. – Казань, 1952.

14. *Исхаков Д.М.* Расселение и численность татар в Поволжско-Приуральской историко-этнографической области в XVIII–XIX вв. // Советская этнография. – 1980. – № 4.

15. *Исхаков Д.М.* Тептяри: социально-этническое и языковое содержание термина // Башкирская этнонимия. – Уфа, 1987.

16. *Исхаков Д.М.* Этнографические группы татар Волго-Уральского региона. – Казань, 1993.

17. *Исхаков Д.М.* От средневековых татар к татарам нового времени. – Казань, 1998.

18. *Катанов Н.Ф.* Отчет о поездке, совершенной с 20 мая по 20 августа 1898 года в Белебеевский уезд Уфимской губернии // Ученые записки Императорского Казанского университета. – Казань, 1900. – Кн. 7-8. – С. 1-30.

19. *Кеппен П.И.* Девятая ревизия: исследование о числе жителей в России в 1851 г. – СПб., 1857.

20. *Кеппен П.И.* Хронологический указатель материалов для истории инородцев Европейской России. – СПб., 1861.

21. *Киекбаев Ж.Ғ.* Башкорт теленең фонетикаһы. – Өфө, 1958.

22. *Киекбаев Ж.Ғ.* Башкорт диалекттәре һәм уларзың тарихенә кыскаса инеш // Башкорт дәүләт университетының гыйльми язмалары. 112 сыгарылыш. Башкорт филологияһе серияһы. – Өфө, 1958.

23. *Кузеев Р.Г.* Очерки исторической этнографии башкир. Ч. I. – Уфа: Башкнигоиздат, 1957.

24. *Кузеев Р.Г.* Численность башкир и некоторые исторические процессы в Башкирии в XVI–XX вв. // Археология и этнография Башкирии. – Уфа, 1968.

25. *Кузеев Р.Г.* Происхождение башкирского народа. – М.: Наука, 1974.

26. *Мажитов Н., Султанова А.* История Башкортостана с древнейших времен до XVI века. – Уфа: Китап, 1994.

27. Материалы по истории Башкирской АССР. Ч. I. – М.-Л., 1936.

28. *Максютова Н.Х.* Восточный диалект башкирского языка. – М.: Наука, 1976.

29. Материалы по татарской диалектологии. – Казань, 1962; 1974; 1978.

30. Материалы по истории Башкирской АССР. Ч. II. – М.-Л., 1949.

31. *Махмутова Л.Т.* О татарских говорах северо-западных районов Башкирской АССР // Материалы по татарской диалектологии. – Казань, 1962.

32. *Небольсин П.* Отчет о путешествии в Оренбургский и Астраханский край // Вестник Императорского Русского географического общества. Ч. I. Кн. 1-2. – СПб., 1852.

33. *Оглоблин И.Н.* Обозрение столбцов и книг Сибирского приказа (1596-1768). Ч. II. – М., 1895.

34. Очерки по истории Башкирской АССР. Т. I. Ч. I. – Уфа: Башкнигоиздат, 1956.

35. Очерки по истории Башкирской АССР. Ч. I–II. – Уфа: Башкнигоиздат, 1959.

36. *Рамазанова Д.Б.* Грамматические особенности говора пермских татар // Материалы по татарской диалектологии. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1974.

37. *Рамазанова Д.Б.* Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984.

38. *Рахматуллин У.Х.* Ясашные башкиры и башкирские припущенники в связи с колонизацией Башкирии в XVIII в. // Вопросы социально-экономической и политической истории Среднего Поволжья и Приуралья периода феодализма. Научная сессия. Тезисы докладов. – Чебоксары, 1973.

39. *Рахматуллин У.Х.* Заселение Башкирии (30-90-е гг. XVIII в.): автореф. дис. … канд. ист. наук. – М., 1975.

40. *Томашевская Н.Н.* От социального пространства к социальному времени: опыт этнической истории башкирского этноса в настоящее время. – Уфа, 2002.

41. *Черемшанский В.М.* Описание Оренбургской губернии. – Уфа, 1859.

42. *Юлдашев А.А.* Говор тептярей Учалинского района Башкирской АССР // Академику В.А. Гордлевскому к его семидесятилетию. – М.: Изд-во АН СССР, 1953.

43. *Юлдашев А.А.* К проблеме формирования башкирского национального языка // Вопросы башкирской филологии. – М.: Изд-во АН СССР, 1959.

44. *Юсупов Ф.Ю.* Татар теленең Көньяк Урал һәм Урал арты (Чиләбе һәм Курган) өлкәләрендә таралган сөйләшләре: дис. … канд. филол. наук. – Казан, 1972.

45. *Юсупов Ф.Ю.* Татарские говоры Южного Урала и Зауралья (Челябинской и Курганской областей): автореф. дис. … канд. филол. наук. – Казань, 1972.

46. *Юсупов Ф.Ю.* Көньяк Урал һәм Урал арты сөйләшләре. – Казан, 1979.

47. *Юсупов Ф.Ю.* Сафакүл татарлары. Тарих, тел, халык иҗаты. – Казан, 2006.

48. *Юсупов Ф.Ю.* Башкортстанда һәм Урал төбәкләрендә яшәүче татарларның тарихы һәм сөйләшләре // Мирас. – 2002. – № 9. – 54-65 б.

## ИСТОРИЯ ФОРМИРОВАНИЯ И ИЗУЧЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО ГОВОРА ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

***Юсупов Фарит Юсупович,***
*доктор филологических наук,*
*Казань, Россия,*
*ferits@yandex.ru*

По территории распространения и численности населения мензелинский говор является самым крупным говором татарского языка. На нем в настоящее время говорит более полутора миллиона носителей. По историческим и археологическим данным, ранние тюрки на территории Приуралья появились на рубеже III-IV вв. нашего тысячелетия. В статье история формирования говора рассматривается с использованием архивных данных, документов РГАДА и архивов Республики Башкортостан, а также материалов, собранных автором во время многочисленных экспедиций.

***Ключевые слова:*** территория распространения мензелинского говора, история формирования, служилые татары, мещеряки, новые башкиры, тептяри.

# THE HISTORY OF THE FORMATION AND STUDY OF MENZELINSKY SUBDIALECT OF TATAR LANGUAGE

***Yusupov F.Yu.,***
*Doctor of Philology,*
*Kazan, Russia,*
*ferits@yandex.ru*

The Menzelinsky subdialect is the largest subdialect of the Tatar language in terms of its distribution and spoken population. It is currently spoken by more than 1.5 million native speakers. According to historical and archological datas, the early Turks appeared on the Ural area at the turn of the 3rd – 4th centuries. The article examines the history of the formation of the subdialect using archival data, documents of the Central Archives and Archives of Bashkir Republic, as well as materials collected by the author during numerous expeditions.

***Keywords:*** geographical distribution of Menzelinsky subdialect, history, Service class Tatars, Meshcheryaks, new Bashkirs, Teptyars.

УДК 811.512.145′282

# ФОНЕТИЧЕСКИЕ ОСОБЕННОСТИ КОНСОНАНТНОЙ СИСТЕМЫ МЕНЗЕЛИНСКОГО ГОВОРА НА ТЕРРИТОРИИ АКТАНЫШСКОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

***Хусаинова Алина Ямилевна,***
*кандидат филологических наук,*
*Институт языка, литературы и*
*искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ,*
*Казань, Россия,*
*Husainova_Alina@mail.ru*

В данной статье рассматриваются ядерные и периферийные фонетические особенности системы согласных в мензелинском говоре на территории Актанышского района РТ. Приводятся примеры соответствий согласных и другие фонетические явления (ассимиляция, диссимиляция, выпадение, вставка согласных и др.). Выявляются ядерные элементы татарской диасистемы, также приводятся сравнения с другими говорами и другими тюркскими языками.

***Ключевые слова:*** диалекты, фонетические диалектизмы, консонантизм, мензелинский говор, соответствия согласных.

Актанышский район находится на северо-востоке республики Татарстан. Население данной территории является носителем мензелинского говора. Данный говор распространен на обширные территории республик Татарстан и Башкортостан. Изучение мензелинского говора имеет богатую историю. Многие ученые-диалектологи: Дж. Алмаз, А.Ш. Афлятунов, Г.Х. Ахатов, Ф.С. Баязитова, А.Г. Бессонов, Л.З. Заляй, Л.Т. Махмутова, И.С. Насипов, Д.Б. Рамазанова, А.А. Юлдашев и др. исследовали говор различными методами. Исследователи подчеркивают близость мензелинского говора к татарскому литературному языку.

Мензелинский говор, распространенный на большие территории по основным ядерным элементам однороден. В то же время, учитывая периферийные элементы, лингвистические и экстро-

лингвистические факторы, говор подразделяется на следующие подговоры: центральный, агрызский, янаульский и белебеевский.

Одной из основных особенностей мензелинского говора является употребление вместо литературного круглощелевого [*з*] интердентального согласного [d]: *кыd* – кыз (девочка), *dур* – зур (большой), *яdу* – язу (писать) и др. *Беd, сабан туйы, димәйбеd, җийыын дибеd*. Звук [*d*] также встречается и в отдельных заказанских говорах, в сафакульском говоре. Также данное явление свойственно башкирскому и туркменскому языкам. По мнению ученых, исследовавших данное языковое явление в мензелинском и других говорах, диалектный звук [*d*] отличается тем, что он ближе к татарскому литературному [д], нежели к башкирскому литературному [з]. Также необходимо отметить, что «шепелявый» звук [з] в башкирском языке имеет свою глухую пару [с]. А в мензелинском говоре звук [*d*] не имеет глухую пару. Поэтому существует мнение, что историю данного звука необходимо рассматривать в контексте угорского субстрата. Интердентальный [*d*] системно распространен в центральном и янаульском подговорах мензелинского говора. В агрызском и белебеевском говорах данное явление теряет свою системность [6, с. 217-218].

Система согласных в основном не отличается от литературных эквивалентов. Особенности говора заключаются в соответствиях звуков и других фонетических явлениях.

Другая особенность говора, характерная для говоров среднего диалекта: в начале слова вместо литературного [й] используется звук [ж] *җул* – юл (дорога), *җафрак* – яфрак (листик), *җозак* – йозак (замок), *җон* – йон (шерсть), *җөрү* – йөрү (ходьба), *җаулык* – яулык (платок) и др. Встречаются и параллельное использование [*җ*]//[й] *җибәрү//йибәрү* (посылать), *җиләс//йиләс* (прохладный). *Солтаңгул җакларында була торган ийе, кыр җагында*.

В.А. Богородицкий отмечает, что звук [ж] татар Приволжья и звук [*ж*] у казахов является дальнейшим развитием древнетюркского звука [*й*] (j) [3, с. 41-42].

В некоторых словах вместо литературного [д] используется звонкий спирант [з]: *бозай* – бодай (пшеница), *Изел* – Идел (Вол-

га), *казак* – кадак (гвоздь), *казерле* – кадерле (дорогой), *назан* – надан (неграмотный). Данная особенность встречается и в заказанских говорах. Эти чередования звуков [т] – [д] – [з] стоят в неразрывной связи с общетюркскими чередованиями типа ajaq|| azaq|| adaq «нога» и т.п. Сравните, например, татарский литературный койрок, тувинский quduruq и др.

Также для данного говора свойственно соответствие согласных [х] – [к]: *катын* – хатын (жена), *вахыт* – вакыт (время), *хәрдәш* – кәрдәш (родственник). Это соответствие также наблюдается в заказанских говорах. Наряду с этими вариантами параллельно бытуют литературные формы: *қатын/хатын* (жена), *эрәқмәт/рәхмәт* (спасибо) и др. Также и в других тюркских языках. Чередование [к]~[х] в середине слова, в основном, свойственно азербайджанскому языку: *јахары, јахын, јаха*. Чередование [к]~[х] в начале слова встречается в чувашском и якутском языках. В чувашском *хара* (на татарском *кара*), *хур* (на татарском *каз*). В якутском *хара* (на татарском *кара*), ха:л (на татарском *кал*). В сары-уйгурском языке согласные [х], [к] используются параллельно: *кан – хан* [1, с. 46].

Губно-губной согласный [п] заменяет губно-зубной глухой согласный [ф]: *пылак* – флаг, *Нәпис* – Нәфис и др. Встречается и обратное явление, когда вместо смычного [п] используется щелевой [ф]: *фәрдә* – пәрдә (занавес), *фамидур* – помидор, *пронт* – фронт, *панар* – фонарь и др.

Явления ассимиляции и диссимиляции.

В определенных словах согласные [*ч*]/[*с*] в позиции начало слова уподобляются последующему согласному [ш]: *шишмә* – чишмә (родник), *шитләвек* – чикләвек (орех), *шишенү* – чишенү (раздеваться), *бачкыч* – баскыч (лестница), *шаршау* – чаршау (занавеска), *шыршы* – чыршы (ель), *шишәмбе* – сишәмбе (вторник) и др.

Сонорный [н] уподобляется последующему губно-губному [б] по месту образования: *томбоек* – төнбоек (кувшинка), *күргәмбез* – күргәнбез (увидели). Данное явление соответствует литературным орфоэпическим нормам.

Сонорные гласные [л]/[ң] уподобляются следующим за ними согласным [к]/[ғ] и [к]/[г] по месту образования *суң кул* – сул кул (левая рука), *җаңгыз* – ялгыз (одинокий), *җаңгыш* – ялгыш (случайно), *урмаңға* – урманга (в лес) и др. [н]>[ң] сиң генә – син генә, миң генә – мин генә.

Чередование [с]>[ч] *урычча* – русча (по-русски), *хакачча* – хакасча (по-хакасски). Также в русских заимствованиях *чимҗә* – семья (татарский литературный: гаилә), *чилсәwит* – сельсовет (татарский литературный: авыл советы).

Соответствия, встречающиеся в определенных группах слов: [з]>[ч] *килегечче* – килегезче (придите пожалуйста), *барыгыччы* – барыгызчы (идите пожалуйста); [ш]>[ч] *чуачча* – чувашча (по-чувашски), *ачаулық* – ашъяулык (скатерть); [ц]>[ч] *немечча* – немецчә (по-немецки); [ф]>[к] *куфайка* – фуфайка, *касфур* – фосфор и др.

Явление метатезы: *итмәк* – икмәк (хлеб), *азбар* – абзар (хлев).

Озвончение согласных звуков: [т]~[д] *дары* – тары (просо), *дигәнәк* – тигәнәк (репейник), [п]~[б] *кирбеч*– кирпеч (кирпич).

Оглушение согласных: [г]~[к] *сискерлек* – сизгерлек (чуткость), *тәлкәш* – тәлгәш (кисть, гроздь), [д]~[т]: *мыштыртау* – мыштырдау, *ти* – ди, *мыгыртау* – мыгырдау (ворчать), *тулкын* – дулкын (волна) и др.

В некоторых словах вместо переднеязычного [т] употребляется [к]: *читләwек* – чикләвек (орех), *типке* – кепка и др.

В заимствованиях из русского языка вместо губно-зубного согласного [в] употребляется губно-губной [б]: *багун* – вагон, *бичер* – вечер, *блас* – власть и др. Также смычный губно-губной [б] соответствует губно-губному [w]: *чобар* – чуwар (пестрый), *чобалу* – чуwалу (спутаться) и др.

В некоторых случаях в мензелинском говоре фарингальный щелевой звук [h] выпадает: *үнәр* – һөнәр (профессия), *әркем* – һәркем (каждый). Например, *Бәбәйтәкле күлмәк әммәсендә, балайтәкле дип тә әйтә қайссы.* Согласный [h] выпадает в позиции между двумя гласными, например, *шәәр* – шәһәр (город), *зәәр* – зәһәр (яд). Согласный [х] в арабо-персидских заимствованиях за-

меняет согласный [h]: *хава* – hава (небо), *хаман* – hаман (всё ещё), *хәйкәл* – hәйкәл (памятник), *хәрбер* – hәрбер (каждый). В то же время в центральном и агрызском подговорах, как и в заказанских говорах, активно бытует звук [h]: *hәм*, *hаман* и др.

Выпадение согласных: согласные [ғ]/[г] в позиции между одинаковыми гласными могут выпадать: *белмәәңгә* – белмәгәнгә (не зная), *тее* – теге (тот) и др. В других случаях согласные [ғ]]/[г] заменяются щелевым губным [w], либо среднеязычным щелевым сонантом [й]: *нийә* – нигә (почему), *түwел* – түгел (не), *йуwалу* – йугалу (потеряться) и др.

Щелевые согласные [w] и [й] в позиции между двумя гласными выпадают вместе с последующим согласным, либо сокращаются: *сӯқ* – суык (холодно), *қӯш* – куыш (дупло), *тийн/ тин* – тиен (копейка) и др.

Выпадение носового сонанта [н]: *асат* – ансат (легко), *муча* – мунча (баня), *белә* – белән (с) и др. Напимер, *Аd аwыру, асат үлем бирсен Ходай*.

Сокращение или выпадение двух рядом идущих одинаковых согласных, например, [нн]>[н]: *кигәнәр* – кигәннәр (одели), алғанар – *алганнар* (взяли), [кк]>[к] *чықан* – чыккан (вышел), [мм]>[м] *қыймәт* – кыйммәт (ценный), [лл]>[л]: *әлә* – әллә (разве) и др.

Вставка согласных. На юге распространения центрального подговора и в белебеевском подговоре мензелинского говора наблюдается вставка увулярного смычного [қ]: *тағын* дақ – тагын да, *йалғанчық* – ялгачы (обманщик) и др.

Вставка переднеязычного сонанта [р] *қычыртқан* – кычыткан (крапива), *қортлау* – котлау (поздравление) и др.

Вставка переднеязычного смычного согласного [т]: *чыбыртқы* – чыбыркы (кнут), йомыртқа – йомырка (яйца) и др.

В некоторых словах, как и в заказанских говорах, после звука [ң] добавляется согласный [г]: *сеңгер* – сеңер (сухожилие), *күңгел* – күңел (душа) и др.

Явление метатезы: *күгәлә* – күләгә (тень), *чәчкә* – чәчәк (цветок) и др. Также данное явление наблюдается в числительных,

когда числительное *егерме* находится в позиции перед числительным, начинающимся на губно-губной смычный согласный [б], то звуки в последнем слоге слова *егерме* меняются местами: *йегерем бер* – егерме бер (двадцать один), *йегерембиш* – егерме биш (двадцать пять) и др.

Таким образом, мензелинский говор на территории Актанышского района действительно проявляет близость к литературному языку. Также в нем присутствуют ядерные элементы, свойственные говорам среднего диалекта, вместе с тем, под влиянием различных исторических, социальных и иных факторов в них выявляются специфические черты. Близость исследуемого говора к литературному языку связана с историей татар Актанышского района. И даже сегодня местные жители остаются верны своим давним традициям и с особой бережностью чтут и сохраняют свой родной язык.

## ЛИТЕРАТУРА И ИСТОЧНИКИ

1. *Әхәтов Г.Х.* Татар диалектологиясе. Югары уку йортлары студентлары өчен дәреслек. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1984. – 216 б.

2. *Баязитова Ф.С.* Фонетические особенности говора татар районов Нижнего Прикамья // Тезисы докладов II научной конференции молодых ученых. – Казань, 1971. – С. 9-14.

3. *Богородицкий В.А.* Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками. – Казань: Татгосиздат, 1934. – 167 с.

4. Милли-мәдәни мирасыбыз: Актаныш. – Казан, 2010. – 415 б.

5. *Рамазанова Д.Б.* Татары Восточного Закамья: их распространение, особенности говора. – Казань: Магариф, 2001. – 205 с.

6. Татар халык сөйләшләре: Ике китапта. Беренче китап / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б. – Казан: Мәгариф, 2008. – 463 б.

# PHONETIC FEATURES OF THE CONSONANT SYSTEM OF THE MENZELINSKY SUBDIALECT IN THE TERRITORY OF THE AKTANYSHSKY DISTRICT OF THE REPUBLIC OF TATARSTAN

***Khusainova A.Ya.,***
*Candidate of Philological sciences,*
*Ibragimov Institute of Language, Literature and Art*
*of the Tatarstan Academy of sciences,*
*Kazan, Russia,*
*Husainova_Alina@mail.ru*

This article examines the core and peripheral phonetic features of the consonant system in the Menzelinsky subdialect in the territory of the Aktanysh region. Examples of consonant correspondences and other phonetic phenomena (assimilation, dissimilation, elision, epenthesis of consonants, etc.) are given. The core elements of the Tatar diasystem are identified, and comparisons with other dialects and other Turkic languages are also given.

***Keywords:*** Dialects, phonetic dialect, the consonant system, Menzelinsky subdialect, matching consonants.

УДК 811.512'373

# ТАТАР АВЫЛЫ МИКРОТОПОНИМИЯСЕ (ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ РАЙОНЫ ТАБАНЛЫ КҮЛ АВЫЛЫ МАТЕРИАЛЫНДА)

***Гаттарова Инзилә Илнур кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты аспиранты,*
*Казан, Россия,*
*inzilya-hammat@mail.ru*

Мәкаләдә татар авылы топонимиясе карала. Аерым алганда, микротопонимнарның структур һәм лексик-семантик үзенчәлекләре ачыклана. Тикшеренү Татарстан Республикасы Актаныш районы Табанлы Күл авылында җыелган материал нигезендә үткәрелде. Автор шулай ук әлеге җирлектә теркәлгән географик атамаларның этимологиясенә дә игътибар бирә.

***Төп төшенчәләр***: Татарстанның Актаныш районы, топонимика, микротопоним, этимология, семантика.

Географик атамаларның барлыкка килү, үсеш һәм яшәеш закончалыкларын тикшерүче топонимика фәнендә [10, б. 175] микротопонимнарны өйрәнү мәсьәләләре аерым урын алып тора. Татарстан микротопонимнар системасы 1971 еллардан алып ныклап өйрәнелә башлый. Әлеге мәкалә кысаларында татар авылы микротопонимиясенең структур һәм лексик-семантик үзенчәлекләрен өйрәнү күздә тотыла. Фәнни тикшеренү Татарстан Республикасы Актаныш районы Табанлы Күл авылында тупланган материал нигезендә башкарылды. Эш барышында микротопонимнарның этимологиясенә дә игътибар ителде.

Табанлы Күл – районның кечкенә авылларыннан берсе. Актаныштан 44 чакрым көньяк-көнбатыштарак Сикия елгасы ярында Мөслим районы чигендә урнашкан. Әлеге авылга 1820-1828 елларда нигез салына. Булачак авыл урынына хәзерге Башкортстанның Бакалы авылыннан ике бертуган Әлмәт белән Колмәт килеп чыгалар. Ул вакытта тирә-як калын урманнар белән

капланган булган. Урман эченнән инеш аккан, янында матур гына күл дә булган. Күлдә табан балыгы күп үрчегән. Күлнең матурлыгына, табан балыгының күплегенә сокланып, аңа Табанлы Күл дигән исем куялар [2, б. 327].

Риваятьнең башкачарак варианты да бар. XIV гасыр башында Бүләр-Биләр шәһәреннән Бараҗ кабиләсе кешеләре Агыйделнең Чулманга койган һәм Ык елгасының түбәнге агымы янындагы җирләргә килеп утыралар. Соңыннан нәкъ шул урында Бүләр олысы барлыкка килә. Бүләрхан улы Җәдәшнең угылы Ихсанның Әлмөхәммәт белән Килмөхәммәт дигән малайлары күлләргә бай, киек-җәнлекле куе урманлы урында Табанлы Күл дигән авылга нигез салалар [12, б. 309].

Тарихи чыганакларга күз салсак, Башкортстанның Бүздәк авылы да элек (1912 елларга кадәр) Табанлыкүл исемле мишәр авылы булып торган.

Бүгенге көндә Табанлы Күл авылы үз эченә дүрт авылны (Югары Яхшый, Түбән Яхшый, Табанлы Күл, Тәкмәк) алган Югары Яхшый авыл советы җирлегенә карый [1, б. 52].

Гомумтатар телендә киң һәм актив кулланышка ия булган *күл* гидрографик терминына нигезләнеп, Татарстан топонимиясенең байтак кына гидронимнары, ойконимнары (башлыча авыл атамалары) һәм микротопонимнары ясалган. Мәсәлән, Табанлы Күл – Актаныш районындагы авыл [9, б. 56]. Ф.Г. Гарипова да бу фактны искәртеп үтә: «Күл – Татарстанда утыз сигез авыл исем-атамаларында һәм микротопонимнар составында кулланыла» [3, б. 118].

Г.Ф. Саттаров болай дип яза: «Татар телендә иярүче кисәге әйбернең булуын, табылуын белдерүче ясалма сыйфат булган исем (бу очракта географик термин булган) сүзтезмәләрдән гыйбарәт географик атамалар ифрат күп. Алар әйберне шул географик объектта булуын, табылуын ачыклыйлар». Автор фикеренчә, татар телендә әйбернең, билгенең булуын, табылуын белдерүче ясалма сыйфатлар *-лы, -ле* кушымчалары ярдәмендә ясала [9, б. 306]. Галим теге яки бу әйбернең, билгенең табылуын яки табылмавын белдерүче сүзләрдән ясалган топонимнар һәм микротопонимнар рәтенә *Табанлы күл* гидронимын да кертә (Пермь өлкәсе Уинский районы Салават авылы) [9, б. 307]. Ф.Г. Гарипованың микротопо-

нимнар сүзлегендә исә *Табанлы күл урманы* дримонимы очрый: Табанлы күл урманы // Табанны күл урманы – Әмәкәй а., Мөслим р. Урман исеме. Информант – М. Сафин [8, б. 78].

Топонимнарның синтаксик юл белән ясалуын иң продуктив ысул буларак билгеләгән Р.И. Хаҗиев *Табанлыкүл* ойконимы сыйфат + исем конструкциясендәге структур типка карый дигән фикердә тора [11, б. 22].

Авыл топонимнарын барлап чыкканнан соң, аларны түбәндәге төрләргә бүлергә мөмкин:

1. Гидронимнар.

*Сикия елгасы.* Топонимист Р.И. Хаҗиев бер мәкаләсендә Мөслим районы Сикия авылын фитонимик терминнан ясалган (удмурт. сик «лес, роща») ойконим буларак атап үтә [12, б. 5378]. Сикия гидронимын да шул лексик-семантик төркем онимы буларак карый алабыз.

Авылдан ерак түгел *Калмыя елгасы* да ага. Калмыя елгасы Мөслим районы Горбуновка авылыннан башлана, Чуракай янында Сөнгә коя. Әгъбәс һәм Җылан да аның яр буенда урнашканнар. Ул төрле балыкка бай булган, хәзер моның белән мактана алмый [13, б. 222]. Р.Ш. Шагеев фикеренчә дә, бу ике елга – удмурт чыгышлы атамалар. Удмуртча *калым* «залив в реке, омут», *сик* «лес, роща» + *я (йа)* «место, изобилующее чем-либо» [14].

*Табанлы күле*, әйтеп үткәнчә, күлдә табан балыгы күп үрчегәнгә күлгә шундый атама бирелгән. Әлеге күл турында мәгълүматны без Ф.Г. Гарипова хезмәтендә очратабыз. Ул Калмыя елгасы бассейнындагы Табанлы күлен [4, б. 84] искә ала. Галимә Табанлы онимын ясалма гидронимнар рәтенә кертә. Гидронимнар ясаучы иң продуктив аффикс дип топонимист-галимә сыйфат ясаучы *-лы/-ле* аффиксын атый һәм гидроним нигезенең семантикасын исәптә тотарга куша. Бу очракта исә башлангыч нигез – балык атамасы (табан).

*Түбән елга* – Түбән очта урнашкан буа. Түбәнлектә урнашканга халык шундый атама биргән дигән фикер бар. Г.Ф. Саттаров *түбән* сыйфаты ярдәмендә ясалган атаманы географик объектның формасын, күләмен, өлешен, халәтен, караңгылык-яктылыгын

белдерүче сүзләрдән ясалган топонимнар һәм микротопонимнар рәтенә кертеп тикшерә [9, б. 282].

Промежуточным пунктом назначения миграции союза племен было местечко при впадении реки Сакмара в реку Урал. Дальнейшие миграции частей союза племен предполагаются такими: Бачман хан – возле устья реки Сакмара, современный город Оренбург. Балым султан (сын Бачман хана) – около рек Ик и Зай – Восточный Татарстан. Тура хан (брат Бачман хана) – гора Торатау, возле современного города Стерлитамак, Ишимбайский район Башкирии; возле современного города Уфа, река Слак, Башкирия. Кусям хан (сын Тура хана) – гора Торатау, возле современного города Стерлитамак, Ишимбайский район, Башкирия; возле устья реки Сакмара, современный город Оренбург.

В итоге, племена, пришедшие с Бачман ханом в регион Идель-Урал ногаи осели на огромной территории: юго-западная Башкирия, центральная Башкирия, северо-западная Башкирия, Закамье – Восточный Татарстан, Арская сторона – Северный Татарстан [16; 5, с. 44; 4, с. 4-5; 9, с. 24-25, с. 135-136].

Исследователи связывают гэрэйцев с переселившимися сюда из Крыма и Черноморского побережья татарскими племенами. По мнению М. Ахметзянова, доказательством тому служит названная «Чатыр-тау» гора в Азнакаевском районе. Переселенцы так ее назвали, так как она напоминала им Крымскую гору «Чатырдах». В 1856-1868 гг. Алексей Толстой упомянул об этой горе в своем поэтическом произведении «Крымские очерки»: «Всесильной волею Аллаха, Дающего нам зной и снег, Мы возвратились с Чатырдаха благополучно на ночлег» [24].

Необходимо отметить, что сведения о переселении по воле Токтамыш-хана в 1380-х гг. большого количества татар бывшего

Ногайского улуса (из Причерноморья и Крыма) на земли между Волгой и Уралом сохранились в текстах шеджере Габдуллы-хана, Кара-бека, Буркут-бека, Кара-ходжи, Хасана-Хусаина, Гирает бия, Муйтен бия, Буркыт бия, шеджере племени елан и др., а также в топонимических названиях упомянутого уже нами Чатыр-тау, а также: Кирмень, Кизлев, Балыклы, Урум, Суук-су, Чембели и др. Главная масса переселенцев прибыла в Среднее Поволжье. Они полностью овладели Булгарским улусом. Улусным бием тогда был назначен бывший золотоордынский правитель Габдулла-хан (Кара-би, Улус-би) [3, с. 10].

В этой связи интересно рассмотреть информацию, касающуюся Мангытского юрта в Казанском ханстве. Большая часть деревень, что расположены в бассейне реки Меша, во времена Казанского ханства относилась к Ногайской «даруге» (области). Эти земли находились в руках «мангытских князей» (ногайцев), административным центром княжества был город Чаллы. Сохранился довольно интересный письменный документ: «...город Чаллы возводится Казанским ханом в середине земель – «даруги» Нугайской и через него шли к хану Нугаев, жившему около Мензелинска (город Чаллы охранял переправу через Каму). Вся эта сторона называлась «даруга» Нугайская. Казанский хан назначил сюда одного человека князем. Спустя некоторое время город Чаллы окреп и разросся и разбогател».

В нескольких списках узбеко-казахских племен от 1428 года указано племя гирей, в списке Ногайских родоплеменных объединений второй половины XV века племя гирей отсутствует, из чего можно сделать вывод о том, что племя гирей попало под «юрисдикцию» Казанского ханства, а именно, Мангытский юрт Казанского ханства с середины XV века до середины XVI века (город Чаллы) [11, с. 100].

Доказательством этнической принадлежности населения Прикского бассейна к татарам Ногайской Орды служит текст родословной Гирает бия, а также Герей хана, несколько копий которых обнаружено исследователями на территории края. Интересен до-

кумент о выборах в 1549 году Хажи-Гирей-султана в чаллинском крае:

«Князья, не находя между собой друг друга достойным, разыскали Хаджи-Гирей-султана и сделали его ханом в [956 году Хиджры] месяце джумадиэль-ахир. В селе Султан начальник Кол-Чура сын Султан-Алия, села Упмас Балтач-бай человек с 10, села Качи Кушай-уста человек с 10, села Серда Колы сын Алия человек с 10, села Чепчык Ямгурчи с Кзыл-Кортом человек с 10, села Шаши князь Джан-Чура человек с 10, села Утня и села Нурма Кол-Урус еще человек с 10, села Шейхзадэ Кулуш-мурза человек с 10, Акчура человек с 10, из Дурт-Уйли Кибяк-Чирмиш человек с 10, князь Мухаммед около 50 человек, из Иске-Юрта Ядигер-бай (и) Касым-Сейд-бай человек с 10, села Кара-Дэвлэт Кунак-уста человек с 10, села Бизнэ Бахшанда-хафиз человек с 10, из Кара-Айша Тюшянек человек с 10, села Тимерчи Нугай сын Усты человек с 10 – эти лица привели Хаджи-Гирей-хана на царство и сделали ханом». «…город Чаллы очень усилился, стал многолюден и богат; один из беев его, Хаджи- или Гази-Гирей – решился поэтому отделиться от Казани и объявил себя независимым ханом. Несколько лет спустя ханом в Чаллах сделался Хафиз-Гирей; при нем началась сильная война с Казанью. На второй год войны казанский хан взял город Чаллы, разорил и уничтожил его до конца, а Хафиз-Гирей с семейством своим бежал в Бухару…». Возможно, в этом документе говорится об Уйазы Гэрэй илуве – сыне Гэрэй хана – Гази Гэрэе. Во всяком случае, по времени жизни совпадение есть несомненное [8; 10].

Рассмотрение вопроса выборов в территориальном ракурсе показывает: выборщики Гази Гирея, татарские князья, представляли территории, которые сопоставляются с землями нынешних Атнинского, Арского, Балтасинского, Кукморского, Сабинского, Мамадышского, Пестречинского, Лаишевского и Рыбно-Слободского районов Татарстана. То есть все районы на севере Татарстана в междуречье Волги-Камы-Вятки. Большинство аулов находится в Арском районе Татарстана. Резонно предположение, что

центр рода гэрэй был в городе Чаллы с 1479 года (возможно, и ранее с 1430-х гг.) и до 1556 года.

Итак, у нас возникали следующие сомнения и вопросы: Гирает бий и Гэрэй хан это один и тот же человек или два разных? Какое отношение имеет племя Гэрэй к кереитам? Какое отношение имеет Гирает бий к кереитам и гэрэ? Какое отношение имеют Гирей бий, Гэрэ хан, кереиты к ханам династии Гирей?

***Гирает бий и Гэрэй хан.*** Во-первых, скорее всего, мы имеем двух Гираетов. Первый Гирает бий – жил как минимум на полвека ранее до рождения Гэрэй хана. Гирает бий был высокопоставленным сановником Ногайской орды. Имя «Гирай» мы впервые встречаем в описании посольства великого хана Джучиева Улуса 12 февраля 1320 г. – 30 января 1321 г. к египетскому султану.

Однако второй Гирает бий проживал в Иманкале (будущей Уфе), по всей видимости, уже, как минимум, с XV века до середины XVI века. Получается, это два разных человека: Гирает – дипломат и Гирает бий – наместник главы Ногайской орды на Южном Урале.

Даже если отбросить сан хана у Гэрэя, которого у ногаев не было, по временному промежутку он не сопоставляется с Гирает бием, так как родился в конце XVI века. А Гирает бий, как мы знаем, жил в XV-XVI вв. Кроме того, на данный момент известные нам родословные, где родоначальник Гирает бий, не пересекаются своими представителями с родословными Гэрэй хана.

Далее о статусе Гэрэй хана. Это может быть и приписанный уровень владычества, лишь указывающий на руководящую должность в Ногайской даруге. Но, с другой стороны, это может говорить и о знатном происхождении, имеющем отношение к роду чингизидов, идущему с Причерноморья. Таким образом, Гирает бий и Гэрэй хан – два разных человека.

***Гэрэи и кереиты.*** Генетические исследования показывают: гэрэи Прикамья отличаются от азиатских народов.

Филологи отмечают: на тюркских языках значение слова «ворон» звучит как «карга». Этот этноним известен в этническом составе ряда тюркоязычных этносов (татар, башкир, казахов, ха-

касов и т.д.). Монгольский и ойрат-калмыцкий этноним «кэрээд» («кереeит») и тюркский «карга» являются терминами различного происхождения, и не могут быть отождествлены друг с другом.

Происхождение гэрэев и их приход в Прикамье, Прибелье по историческим документам, родословным местных жителей четко отождествляется с перекочевками Ногайской орды, а также родоначальником – Гэрэй ханом. Гэрэи и кереиты – разные племена.

***Гирает бий, кереиты и племя гэрэй.*** Гирает бий – сановник Ногайской орды, живший в XV-XVI вв. К кереитам он не имеет отношения. С родом Гэрэй хана, безусловно, он взаимодействовал. Но прямого родственного отношения не имеет.

***Гирает бий, Гэрэй хан, кереиты и династия крымских Гиреев.*** Мы мало знаем о происхождении и жизни Гирает бия. По имеющимся сведениям, можно предположить, что бий был мангытского происхождения. К роду крымских ханов он не имел отношения. Гэрэй хан, как уже говорилось выше, мог иметь некую опосредованную родственную связь с крымскими Гиреями. А крымские ханы Гиреи не имели отношения к кереитам.

## ЛИТЕРАТУРА И ИСТОЧНИКИ

1. *Ахметзянов М.И.* Татарские родословные. Кн. 1. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1995. – 127 с.

2. *Ахметзянов М.И.* Судьба Ногайской Орды // Звезда Поволжья. – 2004. – № 33-37. [Электронный ресурс]. Режим доступа: http://tatarica.narod.ru/history/tarih/nogai240904.htm

3. *Ахметзянов М.И.* Память о предках татар Поволжья и Приуралья (судьба татар Ногайской Орды). – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2007. – 48 с.

4. *Габдуллин И.Р.* Мещеряки Бирского уезда в XVII-XIX вв. (краткий исторический очерк) // Дворянский вестник. – 2009. – № 75. – 8 с.

5. Российская государственная библиотека. Отдел рукописей. Ф. 222 (Панина). П. XII.

6. Институт востоковедения РАН. Архив востоковедов. Ф. 131, оп. 1, д. 50.

7. Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ. Центр письменного и музыкального наследия. Ф. 99, оп. 1, д. 93.

8. Источники для изучения тарханства, жалованного башкирам русскими государями: [Представлено Историко-филол. отд. в заседании 23 окт. 1863 г.] / Изд. В.В. Вельяминов-Зернов. – СПб.: тип. Имп. Акад. наук, 1864. – 44 с.

9. Источники по истории Татарстана (XVI–XVIII вв.) / Сост. С.Х. Алишев, Р.Г. Фахрутдинов. – Казань: ИЯЛИ, 1993. – 160 с.

10. *Исхаков Д.М.* К вопросу об этносоциальной структуре татарских ханств (на примере Казанского и Касимовского ханств XV – сер. XVI вв.) // Панорама-Форум – 1995. – Вып. 3. [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://сувары.рф/ru/content/k-voprosu-ob-etnosocialnoy-strukture-tatarskih-hanstv-na-primere-kazanskogo-i-kasimovskogo

11. *Исхаков Д.М.* Татарская нация: история и современное развитие. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2002. – 233 с.

12. *Кузеев Р.Г.* Происхождение башкирского народа. – М.: Наука, 1974. – 360 с.

13. *Кузнецов А.Л.* История Сибири. 2018 [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://sib-guide.ru/siberia/ar/191

14. Национальный архив Республики Башкортостан (НА РБ). Ф. 2, оп. 1, д. 428, л. 14.

15. НА РБ. Ф. Р-473, оп. 1, д. 2431.

16. Российский государственный архив древних актов (РГАДА). Ф. 1173, оп. 1, д. 196.

17. Вспышки чумы в Золотой Орде становились фактором роста военной напряженности (Интервью с историком Т. Хайдаровым о зарождении и распространении чумы, а также о ее влиянии на развитие государств). [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://realnoevremya.ru/articles/111247-intervyu-istorika-o-chume-v-zolotoy-orde

18. *Стариков Н.В., Беляев Д.П.* Россия. Крым. История. – СПб.: Издательский дом «Питер», 2014. – 248 с.

19. *Тизенгаузен В.Г.* Сборник материалов, относящихся к истории Золотой орды Т. 1. / М.; Л.: Акад. наук СССР, Ин-т востоковедения, 1941. – 521 с.

20. *Трепавлов В.В*. Тюркские народы средневековой Евразии. Избранные труды. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2011 – 252 с.

21. *Хайдаров Т.Ф.* Историография эпидемии «Черной смерти» на территории улуса Джучи (1814-2016) // Золотоордынское обозрение. – 2017. – Т. 5. – № 1. – 193 с.

22. *Хамидуллин Б.* Правление крымских ханов Гиреев в Казани называют «эпохой национального возрождения». [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://realnoevremya.ru/articles/37507

23. История башкирских родов. Гирей. Том 2 / С.И. Хамидуллин, Ю.М. Юсупов, Р.Р. Асылгужин, Р.Р. Шайхеев, Р.М. Рыскулов, А.Я. Гумерова, Г.Ю. Галеева, Г.Д. Султанова. – Уфа: ГУП РБ Уфимский полиграфкомбинат, 2014. – 528 с.

24. *Хисамиева Г.К.* Татарская история – археология, этнография, эпитафии. // Маяк (Газета Азнакаевского района РТ). – 2006. – 14 апреля.

25. *Хойт С.* Кереиты в этногенезе народов Евразии: историография проблемы. – Элиста: Изд-во Калмыцкого ун-та, 2008. – 82 с.

## ON THE ISSUE OF CONNECTIVITY: GEREIS, KEREITS, GIRAET BI, GEREY KHAN, THE CRIMEAN KHANS

***Imangulov I.V.,***
*independent researcher,*
*Ufa, Russia,*
*il.iman@yandex.ru*

The article is describe the relationship between historical figures of Gerey Khan, the Giraet bi, the Kereits and Gerei tribes, and the dynasty of the Crimean Giray khans. Author think that Gerey Khan and Giraet bi are different historical figures, Kereits and Gereis are different tribes with only consonant names, but different genotypes and histories. Giray bi is also not related to the kereites, but he certainly interacted with the family of Gerey Khan. And the Crimean khans of the Giray dynasty had nothing to kerayits.

***Keywords:*** Local history, Tatars, Bashkirs, Golden Horde, Nogai Horde, Crimean khanate, Kazan khanate, history of Tatars, Turkic peoples, genealogies.

УДК 908

# ЭПИТАФИЯ ЯЗМАСЫНДА БЕР ГАИЛӘ ТАРИХЫ

***Әхмәтов Венер Рәшит улы,***
*төбәкне өйрәнүче,*
*Россия,*
*venerakmetov2019@gmail.com*

Мәкаләдә эпиграфик һәйкәл материалында, архив документларын һәм башка тарихи мәгълүматларны да җәлеп итеп, бер гаилә тарихы торгызыла, аның вәкилләре төбәк тарихында танылган шәхесләр булуы ачыклана.

***Төп төшенчәләр:*** татар эпиграфикасы, шәҗәрәләр, Татарстанның Актаныш районы, Башкортстанның Краснокама районы, Агыйдел елгасы.

Үзенчәлекле колоритлы Агыйдел буе бассейны татар авылларына 2020 елны очраклы эләгеп, мондагы татарларның рухи тормышын төрле яклап тикшерү кызыклы булды. Краснокама районы Агыйдел ярының икенче ягындагы Актаныш районына терәлеп тора һәм алар гасырлар буе аралашып яшәүче бер үк кан кардәшләр, туганнар булып торган. Көнчыгыш якта җир иркенрәк була, урман да күбрәк. Җыеннарда аралашкач-килешкәч, танышбелешләр өчен кышын, Агыйдел бозга туңгач, юл ачыла. Әзерләнеп куелган товарлар: бура, утын, мунчала, мүк Краснокама ягыннан Актаныш ягына китә. Актаныш ягыннан да алышбиреш өчен файдалы товарлар килә. Өйләнешү, авыллар күчеп утыру әле XX йөз башында да гадәти хәл булып тора.

Такталачык, Актанышбаш, Уразай, Каенлык, Балтач, Тәтеш, Ашыт, Бурсык, Күпербаш, Кабан кебек авыл исемнәре дә кешеләре белән күчә: алар көзгедә чагылгандай Ак Идел елгасының көнчыгыш ярында да кабатлана.

Тунуз авылында XIX гасырның икенче яртысына караган кабер ташы саклана. Безгә дә бу авылга килеп чыгып әлеге кабер ташын укып карарга насыйп булды. 1895 елда үлгән Шаһмөхәммәдкә атап куелган истәлек ташбилге тексты бик олы

булганга, текстның тарихи яктан кайбер кызыклы урыннарын гына өлешчә монда китерүне кирәк дип таптык.

Текст өзекләре:

6 – ...Шаһмөхәммәд бине Мохыйт (Мохыйт улы Шаһмөхәммәд) дар әл-бакайа (мәңгелек дөньяга)

7 – рихләт әйләде (күчте) мәсихийә (Христос туу ел исәбе белән) сәнә (ел) 1895 15 дикәбер

8 – 72 йәшендә җомга көн зәфөн улынды (җирләнде)

9 – догачы сәүдәгәр кийәве Йагкубның тәзкирәседер (истәлегедер) 1896 сәнәдә (елда) йазылды.

***Таш язманың өс ягы:***

Кал – көллүн йәгмәлү галә шакиләт(иһи) (әйт – һәркемсә үзе булдыралганча яшәр).



Кабер ташының өске өлеше. В.Р. Әхмәтов фотосы. 2020 ел

***Ташъязманың арт ягы:***

1 – **كل نفس ذايقة لموت** көллү нәфсин зайқател-мәwт (һәр җан үлем ачысын татыр. Коръәннең «Әлү Гыймран» сүрәсе, 185 аятеннән өзек – *В.Ә.*).

2 – 1314 (хиҗри ел, язылу 1896 елда булгач, кабер ташы куелу датасы 1896 ел беткәнче булган дип фаразларга кирәк, ягъни кабер ташы елның икенче яртысында кыш кергәнче куелган дип).

15 – [?дога]чылары: әһлийәсе (хатыны) Шәрифә (Шәрифәниса –хатынының исеме) ике угыл Шаһгали вә Шаһморат вә бер кызы Сылуҗиһан.

16 – ... [?дога]..........................се. (язу коелып беткән).

17 – [?] (язу коелып беткән).



Ташъязманың аскы өлеше. В.Р. Әхмәтов фотосы. 2020 ел

11-15 юлларда бер поэтик өзек төрле төрдә протограф буларак Актаныш районы кабер ташларында очрый: иң охшаганы – Мәчти авылында 1841 елгы кабер ташында, икенчесе – Чалманаратта 1873 елгы кабер ташында.

Бу ташъязмада кайбер тамгаларның бозылып язылуы укуны кыенлаштырды. Текстның урта бер өлеше генә шулай кыен итеп язылган, аста бар да җиңел, аермачык, ялгышсыз язылган һәм укыла. Бу өлешен ашыгып эшләгәннәрме, эшне тәҗрибәсез укучыга тапшырганнармы, әллә таш осталары таш чоку технологиясендә поэтик текст өчен сыйфатсыз трафарет кулланганнармы – болар бар да билгесез. Хәтта халык телендә махсус шулай эшләнгән дигән сүз дә бар. Бу ташъязма турында беркем дә укый алмый дигән даны чыгу юкка түгелдер. Беркем дә укый алмаса, ул ташъязма серлелек даны ала, бөек булып тоела башлый, имеш.

Чагыштыру өчен 3 авылда очраган текст үрнәкләре:

| | |
|---|---|
| 1896 Тунуз | бу мәрхүме догада әйләйүб йад ***<br>кыйла күреңез мөбәрәк рухны шад<br>иләһе! әйлә бу мәзфүне мәгфур ***<br>дәхый кыйл мәркаден нур илә мәүфүр |

| | |
|---|---|
| 1841 Мәчти | бу мәрхүме догада әйлә**нез** йад ***<br>кыйла күреңез мөбәрәк рухны шад<br>иләһе! әйлә бу мә**д**фүне мәгфур ***<br>дәхый кыйл мәркаден нур илә мәүфүр |
| 1873 Чалманарат | бу мәрхүме дога**ла** әйлә**ңез шад** ***<br>кыйла күр**ү**ңез мөбәрәк рухны **йад**<br>иләһе! әйлә бу **мәрхүме** мәгфур ***<br>дәхый кыйл мәркаде**ңе** нур илә мәүфүр |

Бу 1895 елгы кабер ташны тикшерү җимеше буларак ике табышмак чишелде: беренчесе исеме, икенчесе датасы. Кабер ташта 3 дата язылган.

1) 1895 елда вафат.

2) 1895-12-15 – үлү датасы.

3) Көнбатыш битендәге «1314» ел дип язылу ул кабер ташның ясалу датасы, 1896-1897 еллар. Кабер ташы беренче кыш үткәч, яз-көз арасы, җир утыргач куела дип фаразласак, һәм мондый бай кеше өчен вакытында эшләнүен дә искәртсәк, таш язылып беткәч тә, көзен җир туңганчы, якынча октябрь аена кадәр, җиргә куелганын фаразлый алабыз.

Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Әүхәди мулла шәҗәрәсе копиясе саклана [13]. Әлеге кадерле истәлек, кайбер тамгалары юкка чыккан булса да, кириллицага күчерелеп язылган бөтен авылның шәҗәрәсе, ыру агачы булып тора. Тик ул шәҗәрәдә, аның басма төрендә дә [10], әлеге язмада тикшерелүче кабер ташындагы кешенең исеме юк.

Кабер ташында берничә исем теркәлгән һәм алар 3 буын кешеләрен үз эченә ала, мондый күп мәгълүматлы кабер ташлары еш очрамый. Мохит улы Шаһмөхәмәт, уллары Шаһморат, Шаһгали, кызы Сылуҗиһан, кызының кияве Ягъкуб, хатыны Шәрәф. Ревизия материаллары боларны раслый. Хатынының исеме – Шәрәф сөйләм телендә кыскартылып бирелгәндер, ә тулы исеме – Шәрәфәтниса. Кызы һәм кияве 1859 елгы ревизия документларына кермәгән. 1859 елда ревизия үткәч тә туган булсалар, яшьләре 36 дан азрак булган дип фаразлый алабыз.

Ревизия [14] һәм кабер ташындагы язу буенча бу ыру агачы 5 буынлык итеп, ә М.Т. Шакирҗанов хезмәтендәге материаллар ярдәме белән 8 буынгача төзелде: 1) Мәхмүт (?1724 -...) > 2) Мряс (?1754-...) > 3) Мохит (1784-...) > 4) Шаһмөхәммәт (1828 ... 1895-12-15) > 5: 1) Шаһигали (1850 -...), 2) Шаһиморат (1855-...), 3) кызы Сылуҗиһан кияве Ягъкуб [16] > 6) Шаһигали улы Мөхәммәтзакир, 7) Шаһигали оныгы Касыйм, 8) Касыйм кызы Өммегөлсем [10].



Уртада Мохитовларның бер кирпеч бинасы, туган авыллары Краснокама районында. В.Р. Әхмәтов фотосы. 2020 ел

Шаһмөхәммәт балалары авыл байлары булган. Иң атаклысы дип Шаһгалине аерып күрсәтергә була. Шаһгали туган авылында берничә бина салдыра. Берсе, өч катлысы, тимер юл вокзалы булырга тиеш була, совет чорында бирәдә ятимнәр йорты, 1977 елгача мәктәп бинасының 1 нче корпусы була. Кирпеч кибет биналары әле дә сакланган (Шаһгалинең туганы Мохитов Фәхретдин кирпечтән кибетләр, складлар салдыра, улы Фәрвәҗ 2 катлы агач бина сала) [10, б. 5-6]. Шаһгали бай биналары тирәли яшерен җир асты юллары да салган, имеш. Тимер юлны ул Яңавыл станциясеннән Айбүләк һәм Кабан авылы аша Актанышка җиткермәкче була [10, б. 6-7]. Авылда әле дә Шаһгали бай шәхесенә караган төрле истәлекләр яши.




Тунуз авылында Шаһгали бай Яңавыл – Актаныш тимер юл вокзалы өчен корган бина, совет мәктәбенең беренче корпусы булып хезмәт иткән. М.Т. Шакирҗанов фотосы. 1976. [10, б. 38].
Актанышта Шаһгали бай йорты, совет банкы йорты өчен кулланылган. М.Т. Шакирҗанов фотосы. 2010. [10, б. 39]

Тунуз авылында кабер өсте корылмасы булган. Бу 2020 елның августында кешеләрдән сорашып ачыкланды. 1943 нче еллардан башлап, 1965 елларгача кабер өсте корылмасы кызыл кирпечкә сүтелгән. Кабер ташы 1,2 м, койма биеклеге 1,5 м була, өстендә 0,5 м биеклектә чуен рәшәткәсе булганлыгы ачыкланды, барлыгы 2 м. Тунуз авылындагы кебек кызыл кирпечтән коймалар Актаныш районындагы Мәчти авылында да сакланган, охшаш кабер ташлары да шул ук Мәчти зиратында еш очрый. Болар Агыйделнең ике ярында бер үк халык, рухи һәм материаль тормыш кайнавына, кеше күчү, алышуга өстәмә факт. Тунуз авылы кабер ташына иң охшаш таш та Мәчти авылында очраганга күрә, ясаучы осталары да бер үк кешеләр, бәлки бер үк оста йортыннан чыккан осталар булган дип әйтергә тулы нигез бар.

Шулай итеп, 1895 елда үлгән Шаһмөхәммәд кабер ташында язылган 3 буын кешеләре Агыйделнең ике ярында да урнашкан районнар өчен билгеле шәхесләр булып чыкты. Алар шул төбәк икътисады үсешендә, тарихында үз эзләрен калдырган танылган кешеләр. Бу кешеләр авылдашлары хәтерендә бүгенге көнгә кадәр сакланса да, авыл тарихчысы төзегән шәҗәрәдә очрамавы ачыкланды һәм авыл тарихын өйрәнгәндә аерым шәҗәрә текстлары гына түгел, ә ревизия язмалары, өстәмә архив материаллары да куллану отышлы булып чыкты.

## ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ЧЫГАНАКЛАР

1. XVIII нче йөз татар әдәбияты: Поэзия. – Казан: Дом печати, 2006. – 363 б.

2. *Ахмеров Г.Н.* Тептяри и их происхождение // Известия Общества истории, археологии и этнографии при Казанском университете. – 1908. – Т. 23. – Вып. 5. – С. 340-364.

3. *Ахметов В.Р.* Тюркский календарь по материалам татарской эпиграфики и рукописей // Отандық түркология: мәселелер, ізденістер, нәтиже (Л.Н.Гумилев атындағы Еуразия ұлттық университетінде 2007 жылдың 2 маусымында өткен халықаралық ғылыми-теориялық конференцияның материалдары). – Астана: ЕҰУ, 2007. – С. 143-147.

4. *Әхмәтов В.Р.* 12 еллык татар җәнлек календаре // Безнең мирас. – 2018. – № 1.

5. *Ахметов В.Р.* Эпиграфические памятники нового времени на Южном Урале, как источник по истории, этнографии и искусству татарского народа // Түркология. – 2007. – № 5-6. – С. 95-108.

6. *Махмуд ал Кашгари.* Диван Лугат ат Турк. – Алматы, 2005. – 1288 с.

7. Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык / Төз.-авт. Р. Мәрданов. – Казан: Җыен, 2006. – 704 б.

8. *Хәмзин К.З., Мәхмүтов М.И., Сәйфуллин Г.Ш.* Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. – 865 б.

9. *Черемшанский В.М.* Описание Оренбургской губернии в хозяйственно-статистическом, этнографическом и промышленном отношениях. – Уфа: Тип. Оренбургского губ. правл., 1859. – 242 с.

10. *Шакирҗанов М.Т.* Салават күпере. – Нефтекама: Матбугат йорты, 2010. – 52 б.

11. *Шакирҗанов М.Т.* Тарих төзәтмә сорый. – Нефтекама: Матбугат йорты, 2011. – 64 б.

12. *Шакирҗанов М.Т.* Тормыш мизгелләре. – Нефтекама, 2012. – 160 б.

13. Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ. Центр письменного и музыкального наследия. Ф. 99, оп. 1, д. 403.

14. Национальный архив РБ. Ф. И-138, оп. 2, д. 751, л. 321.

# ИСТОРИЯ ОДНОГО РОДА НА ПАМЯТНИКЕ ЭПИТАФИИ

***Ахметов Венер Рашитович,***
*краевед,*
*Россия,*
*venerakmetov2019@gmail.com*

В статье на материале эпиграфического памятника, с привлечением архивных документов и других исторических сведений, восстанавливается история одной семьи, выясняется, что ее представители оставили заметный след в истории родного края.

***Ключевые слова:*** татарская эпиграфика, родословные, Актанышский район Татарстана, Краснокамский район Башкортостана, река Агидель.

# HISTORY OF A FAMILY ON THE EPITAPH

***Akhmetov V.R.,***
*local historian,*
*Russia,*
*venerakmetov2019@gmail.com*

Using the epigraphic materials, and archival documents and other historical sourses, the history of one family analysed.

***Keywords:*** Tatar epigraphy, genealogies, Aktanyshsky district of Tatarstan, Krasnokamsky district of Bashkortostan, Agidel river.

УДК 929

# БАТЫРХАН БАДЕРТДИНОВ

***Байгильдина Фәридә Батырхан кызы,***
*төбәкне өйрәнүче,*
*Казан, Россия,*
*farida-rezeda@mail.ru*

Мәкалә минем әтиемә – Бадертдинов Батырхан Кашап улына багышлана. Тормыш юлының төп этаплары яктыртыла. Бер кешенең тормышы мисалында һәр кешедән соң аның игелекле эшләре, киләчәк буыннар хәтерендә мәңге яшәячәк истәлекләре калуы күрсәтелә.

***Төп төшенчәләр:*** Татарстанның Актаныш районы, Ватан тарихы, ватанпәрвәрлек, кеше язмышы, тәрбия, әхлакый кыйммәтләр.



Батырхан Бадертдинов.
1979 ел

Бадертдинов Батырхан Кашап улы 1932 елда Актаныш районы Карт авылында туган. Әтисе Кашап 1936 елда үлеп киткән. Хәтимә әби Батырхан абый кечкенә чакта ук аягын имгәтеп аксак булып калган. Сугыш башланганда Батырхан абыйга нибары 9 яшь була. Әнисе Хәтимә, бертуган абыйсы Тимерҗан, апасы Хәфизә, сеңлесе Бибидәнә белән ачлык-ялангачлык, авыр хезмәт, ятимлекнең ачысын тойган Батырхан абый сугыш чоры, сугыштан соңгы авыр тормышын гел искә ала. «Мине гел бала көенә дуңгыз көтүе көтәргә куйдылар, өстемдәге киемне дә абзый тартып ала торган иде», – дип ачынып сөйли торган булган.

1952-1955 елларда Владивостокта хезмәт итә. Аннан кайткач, Батырхан абый 3 ел буе җыелып килгән салымнарны түли. 1956 елда комсомол путевкасы белән Омск шәһәренә комсомол төзелешенә китә. «Без Омск шәһәрендә таныштык», – дип искә ала аның тормыш иптәше Хания апа. Хания апа комсомол путев-

касы буенча Башкириядән килгән була. Бары 3 класс бетергән Батырхан абый кечке мәктәпкә укырга керә. Ләкин аңа кечке мәктәпне тәмамларга насыйп булмый. 1958 елда әби авырый башлый, авылга кире кайтырга туры килә. Батырхан абый гомер буе укырга мөмкинлек булмаганына аянып яши. 3 класс белеме булса да, силос базы казыймы, юл күтәрәме – күләмен исәпләп, заказнарядларны үзе тутыра.



Актаныш. МТС. 1960 нчы еллар

Омскидан кайткач, вакытлыча туганнарында торып, буш нигездә өй салалар. 1958 елда Батырхан абый Актаныш МТС организациясендә С-100 тракторында эшли башлый, юл чистартуда, юл төзүдә катнаша. Карлы бураннарда, кышкы суыкларда трактор сүнеп, аның берүзе, тирә-якта җан иясе булмаган юлларда өшеп, кунып калган чаклары күп була.

«Колхозга эшкә кайтканчы Батырхан айга бер кайта иде», – дип сөйли Хания апа. Күп вакытта аның белән егерме-утыз шофер кайткан. Чөнки ул алдан тракторы белән юлны кардан чистартып барган. Машиналар трактор артыннан килгән. Актаныштан Чаллыга көнкүреш товарлары алып кайту кыш айларында бер атналык юл булган. Хәзер исә машина белән бер сәгатьлек юл. Батырхан

абый авылга кайткач, алар да авылга кергән. «Бер казан бәрәңге пешереп, катык, чәй эчереп тамакларын туйдырып җибәрә торган идем», – дип искә ала Хания апа. Районда техника аз булу сәбәпле, бер ялсыз эшләргә туры килә. Көз китеп яз кайткан еллары да булган. Актаныш сельхозтехникасының тулай торагында 10 елдан артык яшәп эшләргә туры килә Батырхан абыйга.

1968 елда Батырхан абый колхозга кайтып эшкә урнаша. 36 яшьтә булуга карамастан, Батырхан абыйның сәламәтлеге бик какшаган була. Тазалыгы булмаса да, гомеренең соңгы елларына кадәр С-100 тракторында эшли. Инде күптән эксплуатация вакыты чыккан иске тракторны үзе Киров шәһәрендәге заводка алып барып, 3 тапкыр ремонт ясатып кайта. Батырхан абый сәламәтлеге бик начарлану аркасында 59 яшендә эшен калдырырга мәҗбүр була.

«Батырхан бер вакытта да кешенең үтенечен кире какмады, изгелекле булды», – ди Хания апа. Аңа бик күпләргә башка авылдан өй күчереп (тарттырып) китерергә туры килгән. Хәтта мичләре дә шул килеш кайта торган булган. «Актаныш районында бик күп юллар төзеде. Мин килгәндә безнең яр астында бер генә агач та юк иде. 1970 елда Ташкомнан 25 өянке үсентеләре алып кайтып утыртты. Хәзер ул агачлар бик зур булып үстеләр. Елганың суы кимемәсен өчен 1980 елларда балалар белән тагын өянкеләр утыртты. Табигатьне бик сакларга тырышты. Суга пычрак түккәннәрен күрсә, бик ачынып кайта иде. Батырхан белән 5 бала тәрбияләп үстердек, кайнәмне 6 ел тәрбия иттек. Балалар, оныклар белем алырга тырышты, табигатьне саклады. 6 оныгым мәктәпне, институтны гел «5» кә бетереп, югары урыннарда эшлиләр. Оныгым Байгильдина Эльвира 22 яшендә Америкада бөтен дөнья галимнәре алдында энергетика буенча чыгыш ясады. 25 яшендә Финляндиядә диссертация яклады. Техник фәннәр докторы исемен алып, хәзерге вакытта Финляндиядә атом станциясендә эшли», – дип сөйли Хания апа.

Билгеле, озак еллар буе салкын кабиналы тракторда, көнне төнгә ялгап эшләү эзсез калмый. Бала чактан ук салкын тидереп, авыр елларда, авыр эш шартларында өстәлеп килгән чир Батыр-

хан абыйны 59 яшендә, 1991 елның 14 ноябрендә дөньядан алып китә. Шулай итеп, бала чактан ук эшли башлап, ул гомеренең 41 елын тракторда эштә үткәрә.

Хезмәте һәрвакытта мактауга лаек була. Бик күп медальләр, грамоталар белән бүләкләнә. Батырхан абыйга бирелгән медальләрне, медаль таныклыкларын, грамоталарны бик кадерләп саклый Хания апа. «Сугыштан соң илне безнең буын аякка бастырды, балачакны да, яшьлекне дә күрмәдек без. Күпләр пенсия яшенә дә житә алмый үлеп киттеләр. Сугыш чоры балалары сугыш ветераны исеменә лаек», – дип бетерде сүзен Хания апа. Батырхан абыйның мәңгелек истәлекләре булып исә утырткан агачлары, төзегән юллары, эшләгән яхшылыклары калган...



Карт авылы

# БАДЕРТДИНОВ БАТЫРХАН КАШАПОВИЧ

***Байгильдина Фарида Батырхановна,***
*краевед,*
*Казань, Россия,*
*farida-rezeda@mail.ru*

Статья посвящена моему отцу – Бадертдинову Батырхану Кашаповичу. Освещаются основные вехи его биографии. На примере жизни одного человека показывается, что после каждого человека остаются его добрые дела, его доброе имя, которые будут жить вечно в памяти потомков.

***Ключевые слова:*** Актанышский район Татарстана, история родины, патриотизм, судьба человека, воспитание, нравственное воспитание, мораль, ценность.

# BADERTDINOV BATYRKHAN

***Baygildina F.B.,***
*local historian,*
*Kazan, Russia,*
*farida-rezeda@mail.ru*

The article is dedicated to my father – Batyrkhan Badertdinov. The main milestones of his biography are highlighted. On the example of his life, it is shown that after each person, his memory and his good deeds, is still remains.

***Keywords:*** Aktanyshsky district of Tatarstan, local history, patriotism, human destiny, education, moral education.

УДК 929

# АЗАТ ТИМЕРШӘЕХ – АВЫЛЫМ ГОРУРЛЫГЫ

***Җәмилова Розалия Гарифҗан кызы,***
*ТР Актаныш районы Богады төп*
*гомуми белем бирү мәктәбенең*
*тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы,*
*ТР Актаныш районы, Россия,*
*Zyamilova.1983@mail.ru*

Мәкаләдә Актаныш төбәгенең күренекле нәселе – Хөсәеновлар гаиләсе турында сүз бара. Әлеге гаилә вәкиле – җырчы Азат Тимершәех улы Хөсәеновның тормыш юлы тасвирлана, иҗатына күзәтү ясала.

***Төп төшенчәләр:*** Татарстанның Актаныш районы, Азат Тимершәех, гаилә тарихы, сәнгать, музыка.

Актаныш районы халыктан чыккан талантларга бай як. Композиторлар Илгиз Закиров, Инсаф Хәбибуллин, Рәис Нәгыймов, Азат Хөсәенов, үзешчән композитор Резеда Шәйдуллина, танылган җырчылар Әлфия Авзалова, Хәнәви Шәйдуллин, Лилия Муллагалиева, Асаф Вәлиев, Азат Тимершәехләрнең киң сәнгать дөньясында күренекле урын тотулары безнең өчен зур горурлык. Авылым тарихында да һәм татар дөньясы сәнгатендә онытылмаслык исемнәр бар. Шундыйларның берсе – атаклы Хөсәеновлар нәселе.

Азат Тимершәех улы Хөсәеновнең тырышлыгы, иҗатка мәхәббәте, алдынгы карашлы булуы аны зур иҗади баскычка күтәрә. Ул татар сәнгатен, данын үстерүгә үзеннән бик зур өлеш кертә. Татар халкы тарихы һәм сәнгатенең үсеше, торышы бүгенге көндә актуальлеген югалтмый, киресенчә, бу өлкә белән елдан ел кызыксыну көчәя генә бара.

### *Хөсәеновлар кемнәр алар?*

Кеше табигате шулай корылган, ул үз замандашларын камилләштерү өчен, аларның бәхете өчен бөтен көчен, сәләтен би-

реп эшләгәндә генә үзе дә камиллеккә ирешә ала. Нәкъ шундыйлардан Богады җирлеге белән тыгыз бәйләнгән Хөсәеновларның нәсел шәҗәрәсенә тукталасым килә.

Тимершәех Хөсәен улы 1924 елның 2 июлендә Богады авылында дөньяга килә. Туган авылында белем алганнан соң, 1938 елда мәктәпне тәмамлау белән ул укытучы һөнәрен сайлап Минзәлә шәһәренә юл тота. Ул чор күзлегеннән чыгып караганда, һәр совет кешесе алдында җаваплы бурыч – уку, халыкны белемле итү була. 1940 елны яңадан Богады авылына кайтып балаларга башлангыч белем бирә. Ләкин яраткан эшен дәвам итәргә насыйп булмый. 1942 елның августында Тимершәех ага армия сафларына алына. Кечкенәдән кул арасына кереп, физик һәм рухи яктан чыныгып үскән егет югалып калмый, хәрби училищеда укуын дәвам итә.

Тормыш өчен, гомуми максат өчен көчләрен кызганмыйча эшләүчеләр, мөмкин кадәр бәхет китерергә омтылучылар гына чын бәхетлеләр дип саный ул. Үзе өчен генә түгел, иле, «кендек каны» тамган туган җире өчен аяусыз көрәштә яраланып госпитальгә эләгә. Каты яралану кабаттан аңа хәрби хезмәттә калырга мөмкинлек бирми. Ул туган җире – Богадыга кайта. Авылда ир-заты юк диярлек. Шулай да тормыш йөген тартып барырга ул үзендә көч таба һәм авылда «Сталин» колхозы идарәсенең ярдәмче вазыйфасын башкара. Тик аңа бер урында гына торырга насыйп булмый. Башкортстан республикасының Яңа Карман авылына китә, апасы белән 1944-1947 елларда шунда яши. Тимершәех аганың язмышы тиккә генә Башкортстан яклары белән бәйле түгелдер. Әйтерсең, туган нигез язмышы аңа да кагылган. Ә туып үскән авылы язмышы һәм тарихы болайрак булган.

Туган авылыбыз Богады исеме дә Башкортстанның Каңгы Богадысы дигән авыл исеменнән килеп чыккан. Бу авылда ике бертуган ир бала яшәгән. Бервакыт аларның әниләре җир казыганда, бабаларының җиргә күмеп куелган байлыгын таба һәм кече улына бүләк итә. Ә олы улы Мөмешмөхәммәт моңа бик үпкәли һәм Каңгы Богадысыннан чыгып китә. Ул агач кисеп сал ясый да Ка-

раидел буйлап Агыйдел елгасына төшә. Сал белән Бурсык авылына җитә, аннан Шәбез елгасы буйлап Такталачык авылына килә. Ул елгадан, агач йомычкасы агып килгәнен күреп, монда кешеләр яшидер дигән уй белән хәзерге Гәрәй авылына килә. Вакытлар узу белән авылда яшәп кала.

Авылдагы Гәрәй байның кызы белән тормыш кора. Гәрәй бай хәзерге Богады урнашкан җирне биләгән була. Бу җирләрне киявенә мирас итеп калдыра. Мөмешмөхәммәт гаиләсе белән Богады җирлегенә күчә һәм авылын, «Каңгы» сүзен төшереп калдырып, Богады гына дип атый. Туган авылымның килеп чыгышы менә шулай.

Богады җирлеге, аның табигате искиткеч гүзәллеккә ия. Шул чорлардан калган чишмәләр, урман-кырлар, болыннар бүгенгә кадәр әби-бабаларыбыздан сакланган исемнәр белән атала. Аларның һәрберсенең үз тарихы бар. Мәсәлән, «Пар чишмә!»... Бу ике сүзне ишетүгә, әлбәттә, һәр кешенең күз алдына парлылар килә. Өлкәннәр әйтүенчә, элегрәк аны «Парлылар чишмәсе» дип йөрткәннәр. Күп еллар бу урынга кешеләр ялгызы гына түгел, ә һәрвакыт парлап килгәннәр. Бу чишмә ачылганнан соң, яшь парлар хөрмәтенә «Пар чишмә» дип атаганнар. «Пар чишмә» Богады авылының иң матур түбәнлегенә урнашкан. Ул урнашкан урамны да Чишмә урамы дип йөртәләр. Югарыда язылган чишмәдән тыш, Богады җирлегендә «Шифа чишмәсе», «Әхмәт чишмәсе» дә бар. Бу чишмәләрнең тарихы да үзенчәлекле.

Тимершәех ага язмышына кире кайтыйк. 1947 елны Тимершәех ага тормыш иптәше белән Богады авылына кайта. Хезмәт юлын туган авылы колхозында хисапчы буларак дәвам итә. Җаваплы эштә эшләвенә карамастан, ул үзенә тормышчан таләп, югары максат куя. Ул чорларда «Коммунизмга» колхозына Югары Богады, Иске Богады, Яңа Богады, Иске Солтангол, Яңа Солтангол, Каенлык, Яңа Җияш авыллары берләшә. Авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү буенча зур уңышларга ирешелә. Халык арасында ихтирамга лаеклы табылып, Тимершәех ага 1967 елда Мәскәүдә үткәрелгән авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә катнаша һәм диплом белән бүләкләнә.

Тормыш юлыннан ныклы адымнар белән атлаган ир-атның гаиләсе дә ныклы, ышанычлы була. Тимершәех ага белән Җансылу ханым өч ул, өч кыз тәрбияләп үстерәләр. Балаларының барысы да белем алып, тормышта үз урыннарын тапканнар. Ир балаларны тәрбияләүдә ата кешенең роле алыштыргысыз булса, кыз баланың әхлагына дөрес юнәлеш салуда исә ана кешенең рухи тәҗрибәсе өстенлек итә. Балаларының язмышыннан гаилә башлыгы бик тә канәгать.




Тимершәех Хөсәеновның нәсел шәҗәрәсе

Кызлары Клара, Рәсимә, улы Рафаэль гомерләрен балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаганнар. Уртанчы улы Риф – туган авылында механизатор, Рәмзия ханым – балалар бакчасында шәфкать туташы, ә төпчек энеләре – Азат Хөсәеновның халык иҗатына, сәнгатькә чын күңелдән гашыйк, көчле, гүзәл тавышлы

булып үсүе табигый хәл. Ул гаиләдәге егетләрнең барысына да этиләреннән күчкән сәләткә – оста гармунчы һәм җырчы сәләтенә ия. Азат Хөсәенов бүгенге көндә танылган җырчы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.



Туган нигезгә һәрвакыт туганнар җыелып тора

Гаиләдә ата-ананың үз бурычларына, үз эшләренә җаваплы каравы – гаиләдә хезмәт тәрбиясе өчен олы бер үрнәк. Нәсел шәҗәрәсенә тап төшермәгән Тимершәех аганың җиденче буын вәкиле, оныгы – Энҗе Богады мәктәбенең өченче сыйныфында белем ала. Бабасының көчле рухына, тормыш тәҗрибәсенә соклана ул, һәм нәселдән килгән җырчы сәләтенә ия.

Гаилә сәләтен халыкка танытучысы, халык мәхәббәтен яулаган Хөсәеновлар нәселе дәвамчысы – Азат Тимершәех улы Хөсәенов 1958 елның 10 апрелендә Актаныш районы Яңа Богады авылында дөньяга аваз сала. Яңа Богады урта мәктәбен тәмамлагач, бер ел район «Сельхозтехника» мәдәният йортында эшли. 1976-1978 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. БАМ төзелешендә катнаша. Кайткач, Богады мәдәният йортында эшли, шул ук



Азат Тимершәех

вакытта комсомол әйдаманы вазыйфасын да башкара. Читтән торып Алабуга мәдәният-агарту училищесын тәмамлый. 1980 елда Яр Чаллы каласына килә һәм «Татэлектромаш» берләшмәсенә эшкә урнаша. Читтән торып Мәскәү электротехниклар техникумын тәмамлый. «Энергетик» мәдәният сарае хоры белән төрле концертларда чыгыш ясый, бәйгеләрдә катнаша. Аны «Чишмә» мәдәният сараена директор итеп билгелиләр. 1993 елда Халыкара «Татар җыры» бәйгесенең беренче бүләген ала. Шушы чорда «Яр Чаллы» концерт төркемен оештыра. Илнең күп төбәкләрендә чыгыш ясый, халкыбызны моңлы татар җырлары белән сөендерә. Аңа 1997 елда Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелә. Яр Чаллы педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлеген читтән торып тәмамлый. Алдагы иҗатында бу аңа бик нык ярдәм итә.

2002 елдан аның иҗат эшчәнлеге Казан белән бәйле. Башкала тамашачысы бик тиз егетне үз итеп өлгерә. Ул Россия шәһәрләрендә гастрольләрдә чыгыш ясавын дәвам итә. Үзе бай күңелле, моңлы җан булганга, аның дуслары-теләктәшләре, тамашачылары артканнан-арта бара.

2008 елда 30 елдан артык җыр сәнгатендә милләтебезгә күрсәткән хезмәте өчен Татарстанның халык артисты дигән мактаулы исем бирелә. Тормыш иптәше белән ул һәм кыз үстерәләр.





Мәктәптә Азат Тимершәех улы Хөсәенов
белән очрашу вакытында

Азат Тимершәех улы белән мәктәбебездә ел саен диярлек очрашулар булып тора. Бу очрашуны мәктәбебез белән көтеп алабыз һәм татар халкының моңлы җырларын сокланып тыңлыйбыз. Татар халкы үзенең бөек шәхесләрен онытмасын, күрә белсен иде. Татар моңы яшәсә, татар халкы яши дигән сүз.

## ГОРДОСТЬ НАШЕГО КРАЯ – АЗАТ ТИМЕРШАЕХ

***Зямилова Розалия Гарифяновна,***
*учитель истории и обществознания*
*Бугадинской основной общеобразовательной*
*школы Актанышского района РТ,*
*Актанышский район РТ, Россия,*
*Zyamilova.1983@mail.ru*

Статья посвящена истории семьи Хусаиновых. Описывается жизненный и творческий путь представителя этой семьи, певца Азата Тимершаеха.

***Ключевые слова:*** Актанышский район Татарстана, Азат Тимершаех, история семьи, искусство, музыка.

## THE PRIDE OF OUR REGION – AZAT TIMERSHAEKH

***Zamilova R.G.,***
*History and Social studies teacher*
*of the Bugadinsky secondary school*
*of the Aktanyshsky district of the Republic of Tatarstan,*
*Aktanyshsky district, Russia,*
*Zyamilova.1983@mail.ru*

The article is devoted to a prominent family of the Aktanysh district – the Khusainov family. The life and artistic career of the representative of this family, singer Azat Timershaekh is described.

***Keywords:*** Aktanyshsky district of the Republic of Tatarstan, Azat Khusainov, family history, art, music.

ISBN 978-5-6045068-3-7

9 785604 506837

Подписано в печать 26.12.2020. Формат 60×84 1/16.
Бумага офсетная. Печать офсетная.
Гарнитура «Times». Усл. печ. л. 15,58.
Тираж 500 экз. Заказ 12-20/11-1.

Логос
ИЗДАТЕЛЬСКИЙ ДОМ
*им. академика В.И. Андреева*

420108, г. Казань, ул. Портовая, 25а.
Тел./факс: (843) 231-05-46, 231-08-71, 231-04-19.
E-mail: citlogos@mail.ru
www.logos-press.ru